# ЦВЕТИ, СВЯЩЕННАЯ ЗЕМЛЯ МОЯ,

Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живёт в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!

# FOREVER FLOURISH YOU, MY NATIVE LAND,

Let skies upon you be forever calm!
My land – my family, my helping hand,
We live in harmony with no harm.
Your wisdom is for people’s good,
Since olden time so much is done,
And all my love will be with you
My trust and hope, my Tatarstan!

# МӘҢГЕ ЯШӘ, ГАЗИЗ ВАТАНЫБЫЗ,

Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!



**Кадерле дуслар!**

1920 елның 27 маенда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешу турындагы Декрет дөнья күрә. Әлеге вакыйга төбәк һәм татар халкы тарихында гаять мөһим роль уйный. Ул милли үзаңны ныгытуга һәм берничә дистә ел дәвамында әһәмиятле үсеш факторына әйләнгән куәтле иҗтимагый күтәрелешне уятуга йогынты ясый.

Узган йөз ел республика һәм аның күпмилләтле халкы өчен эзләнү, аякка басу һәм үсеш чоры була. Бер буын гомере дәверендә хуҗалык итү рәвеше тамырдан үзгәреш кичерә. Республикада күптармаклы икътисад төзелә, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы җитештерүләренең матди-техник базасы оештырыла. Киң таралган грамотасызлык юкка чыгарыла, автономия милли мәдәният, мәгариф һәм фәнне үстерүгә көчле этәргеч бирә, матбугат басмалары зур тиражлар белән дөнья күрә башлый.

Бөек Ватан сугышы чоры республикабыз тарихындагы батырлык һәм фидакярлек сәхифәсе булып тора. Татарстанлылар сугыш кырларында көрәшеп, тылда үз-үзләрен аямыйча хезмәт итеп, дошманны җиңүгә үзләреннән саллы өлеш кертәләр.

Сугыштан соң республиканы Советлар Союзының алдынгы икъдисади төбәкләре исәбенә керткән Татарстан нефтен өйрәнү, сәнәгать тармакларын формалаштыру чоры башлана.

Без үзләренең намуслы һәм фидакяр хезмәтләре белән бүгенге Татарстанның уңыш һәм казанышларының нигезен тәшкил иткән бабаларыбызның җиңүләре һәм хезмәтләре белән горурланабыз.

Күпмилләтле халкыбызның таланты һәм хезмәт сөючәнлеге, шулай ук федераль үзәкнең ярдәме нәтиҗәсендә, Татарстан бүген илнең тотрыклы үсешкә ия төбәкләренең берсе булып тора. Моның белән бергә, тормыш-көнкүрешкә мәгълүмати технологияләр кертелә, масштаблы рәвештә торак төзелеше алып барыла, социаль-мәдәни инфраструктура үсешен дәвам итә. Татарстанлылар тормышының югары сыйфатын тәэмин итүче зур программалар гамәлгә ашырыла, төбәкара һәм тышкы икътисади элемтәләр киңәя бара.

Бай тарихи мирасыбызны, мәдәни һәм рухи кыйммәтләребезне, туган төбәгебездә тынычлык һәм үзара татулык традицияләрен саклап калуыбыз аеруча әһәмиятле.

«Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз!» басмасы киң катлау укучыга адреслана. Китапта Татарстан узган йөз еллык тарихи дәвер тасвирлана, республиканың үсеш перспективасы күрсәтелә, төрле буын вәкилләренең хезмәте һәм казанышлары турында бәян ителә.

*Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,*
*Халкым тели изге теләкләр!*

Татарстан Республикасы Президенты
Р. Н. Миңнеханов

**Дорогие друзья!**

27 мая 1920 года был издан Декрет об образовании Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. Это событие сыграло огромную роль в развитии региона и татарского народа. Оно укрепило национальное самосознание и вызвало мощный общественный подъём, который был важным фактором развития на протяжении нескольких десятилетий.

Прошедшие сто лет для республики и для её многонационального народа были временем поиска, становления и роста. В течение жизни одного поколения радикально изменилось хозяйственное устройство. В республике была создана многоотраслевая экономика, сформирована материально-техническая база промышленного и сельскохозяйственного производства. Была преодолена массовая неграмотность, автономия дала импульс расцвету национальной культуры, образования и науки, огромными тиражами стали издаваться книги и журналы.

Героической страницей в истории республики стала Великая Отечественная война. Татарстанцы внесли существенный вклад в общую победу над врагом – отважно сражались на фронте, трудились, не жалея себя, в тылу.

В послевоенный период началось освоение «большой» нефти Татарстана, были сформированы отрасли промышленности, которые вывели республику в число передовых экономических регионов Советского Союза.

Мы гордимся победами и достижениями предшественников, которые своим самоотверженным и созидательным трудом создали фундамент успехов и достижений современного Татарстана.

Благодаря таланту и трудолюбию нашего многонационального народа, а также системной поддержке федерального центра, Татарстан сегодня является одним из динамично развивающихся регионов страны. Повсеместно в жизнь внедряются информационные технологии, ведётся масштабное строительство жилья, развивается социально-культурная инфраструктура. Реализуются крупные программы, призванные обеспечить высокое качество жизни татарстанцев. Расширяются наши межрегиональные и внешнеэкономические связи.

Особенно ценно, что удаётся сохранить богатое историческое наследие, культурные и духовные ценности, традиции мира и согласия на нашей земле.

Издание «Цвети, священная земля моя!» предназначено для широкого круга читателей. Оно ярко иллюстрирует пройденный Татарстаном столетний исторический путь, показывает перспективы развития республики, повествует о труде и свершениях представителей разных поколений татарстанцев.

*Цвети, священная земля моя,*
*Да будет мирным твой небосвод!*

Президент Республики Татарстан
Р. Н. Минниханов

**Dear friends!**

On 27 May 1920 there was published the Decree on the establishment of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic. This event played a great role for the development of the region and the Tatar people. It consolidated the national consciousness and induced a powerful social rise, which became an important factor of development for several decades.

For the republic and its multi-ethnic population, the hundred years that elapsed since that time was the time of searches, formation, and growth. Within life of one generation, the economic system has changed radically. The republic created a diversified economy and formed a material and technical base for industrial and agricultural production. The large-scale illiteracy was overcome; the autonomy gave impetus to the flourishing of national culture, education, and science; and the press began to be published in huge quantities.

The Great Patriotic War became a heroic page in the history of the republic. Citizens of Tatarstan made a significant contribution to the common victory over the enemy – they fought courageously at the front and worked without sparing themselves in the rear.

In the post-war period, Tatarstan began the large-scale production of crude oil and created the branches of industry that placed the republic among the economic leaders of the Soviet Union.

We are proud of victories and achievements of our predecessors, whose self-defying and creative labour laid the foundation for the success and achievements of the present-day Tatarstan.

The talent and hard-working nature of our multi-ethnic people, as well as the regular support from the federal centre have made Tatarstan one of the fastest developing regions of the country. Everywhere we can see the introduction of information technologies into our everyday life, the large-scale housing construction, and the development of social and cultural infrastructure. We can see the implementation of large-scale programmes intended to ensure the high quality of life to citizens of Tatarstan. We expand our inter-regional and foreign economic relations.

What is especially valuable is that we have managed to preserve the rich historical heritage, cultural and spiritual values, traditions of peace and concord on our land.

The edition titled “Forever Flourish You, My Native Land!” is intended for a broad audience. It gives a bright illustration of the century-old historical road that Tatarstan has covered; shows the prospects for further development of the republic; tells about the labour and the outstanding achievements of representatives of different generations of citizens of Tatarstan..

*Forever flourish you, my native land,*
*Let skies upon you be forever calm!*

President of the Republic of Tatarstan
R. N. Minnikhanov



## 2020 – ТАССРга 100 ел!

Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы төзелүнең йөзьеллыгы безне үткәннәрне искә алырга, бүгенгегә зуррак игътибар бирергә һәм үсеш перспективаларын күзалларга өнди. Үткән тәҗрибә Татарстан халыкларының милли тәңгәллеген формалаштыруда, уртак ватандашлык белән генә түгел, ә республикадагы 170тән артык милләтнең бергә яшәвенең тарихи, мәдәни әһәмиятен һәм рухи бердәмлеген күрсәтә торган уртак тарихи хәтер белән дә үзара бәйләнгән җәмгыять төзүдә үтемле чара булып тора.

Татар халкы тарихы 460 елдан артык Россия составында яшәп килгән һәм юкка чыкмаган, үзенең этник йөзен, телен һәм мәдәниятен саклап калган этнос үсешенең уңай үрнәге булып тора. Алай гына да түгел, татарлар, башка халыклар белән бергә, Россия дәүләтен төзүдә актив катнашкан, аннары берничә йөз еллар дәвамында илне, дәүләтнең бөтенлеген саклаган, аның белән бергә тарихи үсешнең авырлыкларын да, казанышларын да уртаклашкан. Мәшһүр татар шагыйре Габдулла Тукай XX йөз башында татарлар турында болай дигән:

*Рус җирендә без әсәрле, эзле без,*
*Тарихында бер дә тапсыз көзге без.*
*Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
*Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.*
*Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,*
*Без шаярыштык, вакытлар алмашып.*

*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –*
*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.*
*Без сугышта юлбарыстан кочлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез.*
*Шул халыкныңмы хокукка хакки юк? –*
*Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!*

## 2020 – 100 лет ТАССР!

Столетие со дня образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики призывает нас вспомнить о прошлом, пристальнее вглядеться в настоящее и представить перспективы развития. Опыт прошлого выступает действенным инструментом формирования национальной идентичности народов Татарстана, создания общества людей, связанных между собой не только общим гражданством, но и общей исторической памятью, которая подчёркивает историческое и культурное значение совместного проживания и духовной общности более 170 народов, населяющих республику.

История татарского народа является позитивным примером развития этноса, более 460 лет живущего в составе России и не исчезнувшего, не потерявшего свой этнический облик, язык и культуру. Более того, татары вместе с другими народами принимали активное участие в создании Российского государства, затем на протяжении нескольких столетий защищали страну, её государственную целостность, делили с ней и тяготы, и успехи исторического развития. Известный татарский поэт Габдулла Тукай в начале XX в. сказал о татарах так:

*Мы – образ России в зеркальном стекле.*
*В лад жили и пели мы с русскими встарь:*
*свидетельством – нравы, привычки, словарь.*
*Мы с русским народом сроднились давно.*
*Во всех испытаньях стоим заодно.*

*Такого родства временам не избыть!*
*Нас крепко связала истории нить.*
*Как львы, мы отважны в тревогах войны.*
*Как лошади, трудимся в мирные дни.*
*На счастье – с народом любым наравне –*
*имеем мы право в родимой стране!*

## 2020 – 100 Years of the TASSR!

The hundredth anniversary of the establishment of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic calls us to remeber the past, look more attentively into the present, and picture the prospects for development. The past experience acts as an effective instrument for the formation of national identity of the peoples of Tatarstan, for creation of a community of people tied not only by common citizenship, but also by common historical memory, which underlines the historical and cultural significance of co-living and spiritual commonality of over 170 peoples that inhabit the republic.

The history of the Tatar people is a positive example of the development of an ethnos that has been living within Russia for more than 460 years and managed not to disappear, to lose its ethnic image, language and culture. What is more, the Tatars, together with the other peoples, took an active part in the establishment of the Russian State, defended the country for several centuries, its state integrity, sharing with it the hardships and achievements of historical development. The well-known Tatar poet, Gabdullah Tokay, said of the Tatars in the early 20th century as follows:

*We are an image of Russia in the mirror glass.*
*We lived and sang in harmony with Russians*
*from of old:*
*Our customs, habits, and vocabulary*
*is evidence of this.*
*We became relatives with Russians long time ago.*
*In all the trials we stand together.*

*The times will not erase this kinship!*
*The thread of history has tied us tight.*
*We're brave like lions during the dismays of war.*
*We work like horses during the days of peace.*
*Like any other people, we also have the right*
*For happiness in our native country!*



Татарларда милли дәүләтчелекне торгызу процессы катлаулы бара. Бу татар халкының таралып урнашуы һәм тупланып яшәгән территорияләрне билгеләүнең кыенлыгы белән бәйле була. 1920 елның 27 маенда Татарстан АССР төзелү белән татар халкына электән үк үзе яшәгән җирләрнең бер өлеше беркетелә, татар теле дәүләт теле дип игълан ителә, үз Конституциясе һәм символикасы, үз бюджеты, югары хакимият органнарында милли вәкиллеге барлыкка килә. Болар барысы бергә милли һәм төбәк проблемаларын нәтиҗәле хәл итү мөмкинлеген бирә.

Татар милли дәүләтчелегенең яңарышы зур сәяси һәм этномәдәни әһәмияткә ия була. Тизләтелгән индустриальләштерү процесслары белән бергә, Татарстан халыкларының мәдәни тормышы көчле үсеш ала. Казанышлар белән беррәттән, республиканың күпмилләтле халкы авыр икътисади тетрәнүләргә һәм төзәтеп булмаслык иҗтимагый-психологик җәрәхәтләр калдырган көчләп коллективлаштыруны, сәяси репрессияләрне дә кичерә.

XX гасырның икенче яртысы Татарстанда сәнәгатьнең күтәрелеше, индустриаль икътисадка күчеш чоры була. Республика җитештерүнең, социаль-мәдәни инфраструктураның тарихта моңарчы күрелмәгән үсеш темпларын, халыкларның культура һәм белем дәрәҗәсе артуны күрсәтә. Татарстан икътисадының күтәрелеше халыкның тормышы яхшыруга һәм аның социаль мобильлегенә китерә.

Процесс возрождения национальной государственности у татар был сложным. Это обуславливалось дисперсным расселением татарского народа и трудностями выделения территории его компактного проживания. С образованием Татарской АССР 27 мая 1920 г. за татарским народом была закреплена часть исконных этнических земель, татарский язык был объявлен государственным, появились своя Конституция и символика, собственный бюджет, национальное представительство в высших органах власти, что в совокупности позволяло более действенно решать национально-региональные проблемы.

Возрождение татарской национальной государственности имело огромное политическое и этнокультурное значение. Вместе с процессами форсированной индустриализации происходило интенсивное развитие культурной жизни народов Татарстана. Наряду с достижениями многоэтничное население республики пережило и насильственную коллективизацию, политические репрессии, вызвавшие тяжёлые экономические потрясения и нанесшие незаживающие социально-психологические травмы.

Вторая половина XX в. была ознаменована для Татарстана промышленным подъёмом, переходом к индустриальной экономике. Республика показала рекордные для своей истории темпы роста производства, социально-культурной инфраструктуры, повышение культурно-образовательного уровня народов. Подъём экономики Татарстана обусловил улучшение жизни населения, повышение его социальной мобильности.

The process of revival of national statehood of the Tatars was complicated. This can be explained by dispersed settlement of the Tatar people and difficulties related with the selection of territories of their dense concentration. After the establishment, on 27 May of 1920, of the Tatar ASSR the Tatar people were assigned a portion of its original ethnic lands, the Tatar language was declared to be official, there were adopted the Constitution and state symbols, the own budget, the ethnic representation in the supreme bodies of power was secured, which, taken together, made it possible to solve ethnic and regional issues more efficiently.

The revival of the Tatar national statehood had a huge political and ethno-cultural significance. The accelerated industrialisation was accompanied by intensive development of cultural life of the peoples of Tatarstan. Apart from achievements, the multi-ethnic population of the republic lived through the forced collectivisation, political repressions, which entailed the hard economic perturbations and inflicted the non-healing social and psychological traumas.

The second half of the 20th century was marked for Tatarstan by industrial upsurge, transfer towards industrial economy. The republic showed the record-breaking rates of industrial growth in its history, as well as the high rates of building of social and cultural infrastructure, and unprecedented growth of cultural and educational level of its peoples. The rise of the economy of Tatarstan provided the conditions for further improvement of life of the population and acceleration of its social mobility.

XX – XXI гасырлар чигендә СССР таркалу белән бәйле тарихи тәҗрибә күрсәткәнчә, тотрыклы һәм нәтиҗәле үсеш субъектларның федераль үзәк белән конструктив диалог алып баруы юлы белән генә, гомумроссия һәм милли төбәк мәнфәгатьләре арасында мөмкин кадәр тигезлеккә, үзәкнең җаваплы сәясәте һәм субъектларның үз бурычларын үтәвенә ирешкәндә генә булырга мөмкин.

Татарстанда яңа социаль-икътисади һәм этномәдәни өлгене гамәлгә кертү 1990 елларда республиканың беренче Президенты М. Ш. Шәймиев җитәкчелегендә башлана, 2010 елдан аның алмашчысы Р. Н. Миңнеханов тарафыннан дәвам иттерелә. Татарстан моделен эзлекле рәвештә тормышка ашыру, федераль һәм чит ил инвестицияләре килү, шулай ук аеруча мөһим икътисади, социаль-мәдәни һәм спорт объектлары корылу, транспорт һәм мәгълүмат инфраструктурасы үсү, социаль өлкәнең уңышлы эшләве, мәгариф системасын модернизацияләү икътисадның тиз күтәрелешен тәэмин итә. Гомумфедераль «Татулык. Тәртип. Иҗади хезмәт» шигаре нигезендә күпмилләтле җәмгыятьнең берләшүенә корылган республикакүләм иҗтимагый-сәяси стратегия яңа өлгенең табигый бер өлеше булды.

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгы – халыклар үсешендә аларның бердәм булганда, республика һәм тулаем ил икътисады хакына бергәләп эшләгәндә генә уңышка ирешү мөмкин булуын дәлилли. Татарстан җәмгыятендәге иҗтимагый татулык барлык халыклар иминлегенең нигезе булып тора.

Исторический опыт рубежа XX – XXI вв., связанный с распадом СССР, показал, что стабильное и продуктивное развитие возможно только на пути конструктивного диалога субъектов с федеральным центром, достижения оптимального равновесия между общероссийскими и национально-региональными интересами, ответственной политики центра и выполнения обязательств субъектами.

В Республике Татарстан реализация новой социально-экономической и этнокультурной парадигмы началась в 1990-е гг. под руководством её первого Президента М. Ш. Шаймиева, с 2010 г. продолжена его преемником – Р. Н. Миннихановым. Последовательная реализация татарстанской модели обеспечила быстрый подъём экономики за счёт притока федеральных и иностранных инвестиций, а также сооружение важнейших экономических, социально-культурных и спортивных объектов, развитие транспортной и информационной инфраструктуры, успешное функционирование социальной сферы, модернизацию системы образования. Органической составляющей новой парадигмы стала республиканская общественно-политическая стратегия консолидации многоэтничного общества на основе общефедерального лозунга «Согласие. Порядок. Созидание».

100-летие образования Татарской АССР – это свидетельство того, что успехи в развитии народов могут быть достигнуты только при условии их единства и совместной работы на благо экономики республики и страны в целом. Социальный мир в татарстанском обществе является основой благополучия всех народов.

The historical experience of the turn of the 20th and 21st centuries related to collapse of the USSR has shown that stable and productive development is only possible on the way of constructive dialogue of constituent entities and the federal centre, which is aimed at ensuring the optimal balance between the All-Russian and ethnic/regional interests, and given the responsible policy of the centre and implementation of obligations by regions.


In the Republic of Tatarstan, implementation of the new social, economic, and ethno-cultural paradigm began in the 1990s under the leadership of its first President, M. S. Shaimiev, and was continued, starting from year 2010 by his successor – R. N. Minnikhanov. The consistent implementation of the model of Tatarstan facilitated the rapid growth of the economy ensured by inflow of federal and foreign investment, as well as resulted in the implementation of the most important economic, social and cultural, and sports projects, development of transport and information infrastructure, successful functioning of the social sphere, and modernisation of the education system. The republic's social and political strategy of consolidation of multi-ethnic society based on the federal motto – "Concord. Order. Creation" – became an organic part of the new paradigm.

The 100th anniversary of the establishment of the Tatar ASSR is the evidence to the fact that the achievements in the development of peoples can only be attained through their unity and joint work to the good of the republic's economy and the economy of the country in general. The social peace in the society of Tatarstan is the basis for well-being of all peoples.

# ТАТАР ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕ ТАРИХЫННАН

# ИЗ ИСТОРИИ ТАТАРСКОЙ ГОСУДАРСТВЕННОСТИ

# FROM HISTORY OF THE TATAR STATEHOOD





## Гасырлар төпкеленнән

Төбәгебезнең һәм мондагы халыкларның күпгасырлык тарихы бар. Урта Идел буена кешеләр килеп урнашу таш гасырның беренче чорына, ягъни палеолитка карый. Хәзерге Татарстан территориясендә беренче кешеләр якынча 100 мең ел элек яши башлый. Беренче кешелек җәмгыяте чорына караган иң борынгы археологик истәлекләр Идел елгасының уң як ярында, Кама Тамагы һәм Тәтеш районнары җирлегендә табылган. Бронза гасырында борынгы кешеләрнең урнашу ареалы шактый киңәя. Төбәк территориясенә мал асраучы күчмә һәм ярымкүчмә кабиләләр үтеп керә, моны раслаган археологик дәлилләр бөтен Татарстан буенча диярлек теркәлгән. Мерә, муром һ. б. фин-угор кабиләләре – иртә тимер гасыры археологик культурасы вәкилләре. Төбәктә тимер кою үсеше җирле кабиләләрнең хуҗалык тормышында игенчелекнең әһәмияте артуга китерә. Безнең эраның I меңьеллыгында Урта Идел буенда яшәүчеләрнең көндәлек тормышында тимердән ясалган эш коралларын һәм игенчелек кирәк-яракларын киң куллану ашлык чәчү өчен зур урман мәйданнарын чистартырга, туфрак эшкәртүне камилләштерергә, торак төзелеше һәм хәрәкәт итү чаралары ясау өчен агачны файдаланырга мөмкинлек бирә, һөнәрчелек үсешен тизләтә һәм кабиләләр арасында товар әйләнешен киңәйтә.



Шомартылган таш балта. Бронза гасыры

Топор шлифованный. Камень. Эпоха бронзы

Polished axe. Stone. Bronze Age

## Из глубины столетий

История края и его народов имеет многовековую историю. Заселение человеком Среднего Поволжья относится к первому периоду каменного века – палеолиту. Первые люди на территории современного Татарстана появились около 100 тысяч лет назад. Наиболее древние археологические памятники первобытного общества были обнаружены на правом берегу Волги, на территории Камско-Устьинского и Тетюшского районов. В бронзовом веке ареал расселения первобытных людей значительно расширился. На территорию края проникли кочевые и полукочевые скотоводческие племена, археологические свидетельства этого зафиксированы практически по всему Татарстану. Древнейшими носителями археологических культур раннего железного века были финно-угорские племена меря, мурома и др. Развитие в крае металлургии железа привело к возрастанию роли земледелия в хозяйственной жизни местных племён. Широкое внедрение железных орудий труда и земледельческого инвентаря в хозяйственную повседневность населения Среднего Поволжья в I тысячелетии н. э. позволило расчищать под зерновые посевы значительные лесные площади, совершенствовать обработку почвы, использовать дерево для строительства жилья и средств передвижения, ускорило развитие ремёсел и расширило товарообмен между племенами.



В. Л. Лаптев. Бронза гасыры торулыгы (Балым). XX йөз уртасы

В. Л. Лаптев. Поселение эпохи бронзы (Балымская стоянка). Середина XX в.

V. L. Laptev. Bronze Age settlement (Balym settlement site). Mid-20th century

## From the Depths of the Centuries

The history of the region and its peoples is centuries-old. The population of the Middle Volga Region began in the first period of the Stone Age – the Palaeolithic period. The first people in the territory of the present-day Tatarstan appeared here some 100 000 years ago. The most ancient archaeological monuments of the primitive society were found on the right bank of the Volga, in the territory of the Kamsko-Ustyinsky and Tetyushsky Districts. In the Bronze Age, the area of settlement of primitive people became much broader. The nomadic and semi-nomadic pastoralist tribes penetrated the territory of the region. The archaeological evidence of this was found almost all over Tatarstan. The most ancient carriers of the archaeological cultures of the Early Iron Age were the Finno-Ugric tribes of Merya, Muroma, and so on. The development of the iron metallurgy in the region resulted in the growth of the role of farming in the economic life of the local tribes. The vast introduction of the iron instruments of labour and farming equipment into the economic everyday life of the population of the Middle Volga Region during the first millennium AD made it possible to clear large plots of land from woods for grain crops, to further improve the soil cultivation, use wood for construction of housing and means of transport, accelerated the development of crafts, and expanded the commodity turnover among the tribes.



Металл пычаклар, балталар

Металлические ножи и топоры


Metal knives and axes



Тимер һәм бронза йозаклар, ачкычлар. XII – XIII йөзләр

Железные и бронзовые замки, ключи. XII – XIII вв.

Iron and bronze locks and keys. XII – XIII centuries



Б. А. Гыйльванов. Тимерче алачыгы. 2016

Б. А. Гильванов. Кузница. 2016

B. A. Gilvanov. Blacksmithshop. 2016



Ф. Г. Халиков. Биләр реконструкциясе. 2000

Ф. Г. Халиков. Реконструкция Биляра. 2000

F. G. Khalikov. Reconstruction of Bilyar. 2000



Җәмигъ мәчет.
Ак таштан төзелгән өлеше калдыгы.
X – XIII йөзләр. Биләр

Соборная мечеть.
Остатки белокаменной части. X – XIII вв.
Билярск

Cathedral Mosque.
Remains of a white stone mosque.
10th – 13th centuries.
Bilyarsk



Иранда эшләнгән фаянс касә. Биләр.
XII – XIII йөз башы

Фаянсовая чаша из Ирана. Биляр.
XII – начало XIII в.

Faience bowl from Iran. Bilyar.
12th or early 13th century



Кәрвансарай мунчасы хәрабәләре.
X – XIII йөзләр. Биләр

Руины бани караван-сарая. X – XIII вв.
Билярск

Ruins of a steam bath of the caravan-serai.
10th – 13th centuries.
Bilyarsk



А. Н. Хисамов. Алмыш хан. 2017. *Алмыш (IX гасыр ахыры – X йөз башы), Идел буе Болгары илтәбәре*

А. Н. Хисамов. Хан Алмуш. 2017. *Алмуш (конец IX – начало X в.), правитель Волжской Булгарии*

A. N. Khisamov. Almysh Khan. 2017. *Almysh (late 9th – early 10th century), the ruler of the Volga Bulgaria*




Идел буе Болгары картасы (920 еллар – 1236)

Карта Волжской Булгарии (920-е – 1236)

Map of the Volga Bulgaria (920s – 1236)

II – VII гасырларда, Халыкларның бөек күчеше чорында, Урта Идел буе территориясенә төрки-угыр кабиләләре үтеп керә. Төбәктә VI – VIII йөзләрдә сизелерлек арткан төркиләрнең мәдәнияте Төрки каһанлык, Бөек Болгар дәүләте һәм Хәзәр каһанлыгы мәдәниятенә якын була. VII йөз ахырында – VIII гасыр башында Бөек Болгар дәүләтен хәзәрләр яулап алганнан соң, болгар кабиләләренең бер өлеше: болгарлар, суварлар, бәрәнҗәрләр, биләрләр – Урта Идел буена күчә. X гасырда болгарлар Иделнең урта агымында Идел буе Болгар дәүләтен төзи. 922 елда бу дәүләт рәсми дин буларак ислам динен кабул итә, һәм шушы вакыттан болгар кабиләләренең рухи тормышы Шәрык илләренең мөселман цивилизациясе йогынтысында үсеш ала. Алар белән дә, Көнбатыштагы рус кенәзлекләре белән дә тыгыз сәяси, сәүдә-икътисади һәм мәдәни элемтәләр урнаша.

Во II – VII вв., в период Великого переселения народов, на территорию Среднего Поволжья активно проникали тюрко-угорские племена. Культура тюркского населения края, существенно увеличившегося в VI – VIII вв., была близка культуре Тюркского каганата, Великой Болгарии и Хазарского каганата. После завоевания хазарами Великой Болгарии в конце VII – начале VIII в. часть болгарских племён: булгары, сувары, баранджары, биляры – переселилась в Среднее Поволжье. В X в. в среднем течении Волги булгары образовали государство – Волжскую Булгарию. В 922 г. официальной религией в Волжской Булгарии стал ислам, и с этого времени духовная жизнь булгарских племён складывалась под воздействием мусульманской цивилизации стран Востока, с которыми, как и с русскими княжествами на Западе, установились тесные политические, торгово-экономические и культурные связи.

The period from the 2nd to the 7th centuries, the Migration Period, saw the intensive penetration of the Turkic-Ugric tribes to the territory of the Middle Volga Region. The culture of the Turkic population of the region, which increased significantly in the 6th-8th centuries, was close to such of the Turkic Kaghanate, the Great Bulgaria, and the Khazar Kaghanate. Following the conquest of the Great Bulgaria by the Khazars in the late 7th or early 8th centuries, a portion of the Bulgar tribes: the Bulgars, Suvars, Baranjars, and Bilyars moved to the Middle Volga Region. In the 10th century, the Bulgars established their first state, the Volga Bulgaria, in the middle reaches of the Volga. In 922, Islam became official religion of the Volga Bulgaria. Since that time the spiritual life of the Bulgar tribes has become closely related to Muslim civilisation of Oriental countries, with which it established close political, trade, economic, and cultural ties, just like with the Russian principalities in the West.

О. Р. Гасыймов. Болгар ир кешесе. VIII – IX йөзләр. Олы Тархан каберлеге материалларына нигезләнгән реконструкция

О. Р. Гасимов. Булгарин. VIII – IX вв. Реконструкция по материалам Большетарханского могильника

O. R. Gasimov. Bulgar man. 8th – 9th century. Reconstruction based on materials of the Bolshetarkhansky burial ground



О. Р. Гасыймов. Болгар хатын-кызы. VIII – IX йөзләр. Олы Тархан каберлеге материалларына нигезләнгән реконструкция

О. Р. Гасимов. Булгарка. VIII – IX вв. Реконструкция по материалам Большетарханского могильника

O. R. Gasimov. Bulgar woman. 8th – 9th century. Reconstruction based on materials of the Bolshetarkhansky burial ground



Биләр чәчәк ату чорында (XII – XIII йөзләр). А. А. Мазанов реконструкциясе

Биляр в период расцвета (XII – XIII вв.). Реконструкция А. А. Мазанова

Bilyar in the heyday. XII – XIII centuries. Reconstruction of A. A. Mazanov



Р. Ф. Хуҗин. 922 елда болгарларның ислам динен кабул итүе. 2004 – 2006

Р. Ф. Хузин. Принятие булгарами ислама в 922 году. 2004 – 2006

R. F. Khuzin. Adoption of Islam by Bulgars in 922. 2004 – 2006



Р. Ф. Хуҗин.
Х йөздә Ага Базар. 2011

Р. Ф. Хузин.
Ага-Базар X века. 2011


R. F. Khuzin.
Aga-Bazaar of the 10th century. 2011



Көмеш тәңкәләр.
XIII – XIV йөзләр

Серебряные монеты.
XIII – XIV вв.

Silver coins.
13th – 14th centuries



Кәрвансарай ягыннан урта гасырлар Биләре күренеше. А. А. Мазанов реконструкциясе

Панорама средневекового Биляра из района караван-сарая. Реконструкция А. А. Мазанова


Panorama of the medieval district of Bilyar from caravanserai zone. Reconstruction of A. A. Mazanov



Имән чикләвегенә охшаш асылмалар белән бизәлгән муен чылбыры. XIII йөз

Шейная цепочка с желудевидными подвесками. XIII в.

Neck chain with acorn-shaped pendants. 13th century



Чигә алкасы. Көмеш.
XI – XII йөзләр

Височное кольцо.
Серебро. XI – XII вв.

Temple ring. Silver.
11th – 12th centuries



Төсле пыяладан муенса.
XII – XIV йөзләр

Бусы из цветного стекла.
XII – XIV вв.

Beads from stained glass.
12th – 14th centuries

X – XIII гасырларда Идел буе Болгар дәүләте кысаларында бердәм болгар этносы формалаша, дәүләт үзе – югары үсеш алган игенчелек, терлекчелек, шәһәр төзелеше, һөнәрчелек һәм сәүдә иленә, ә Биләр, Болгар, Җүкәтау, Ашлы, Сувар һ. б. шәһәрләр Идел буе Болгарының һәм болгарларның гына түгел, Идел буенда һәм Урал алдында яшәгән башка күп кабиләләрнең (халыкларның) дә матди һәм рухи мәдәният үзәкләренә әверелә.

В X – XIII вв. в границах Волжской Булгарии сформировался единый булгарский этнос, она превратилась в страну высокоразвитого земледелия, скотоводства, градостроительства, ремёсел и торговли. Города Биляр, Болгар, Джукетау, Ошель, Сувар и др. стали ведущими центрами материальной и духовной культуры не только Волжской Булгарии и собственно булгар, но и многих других племён (народов), проживавших в Поволжье и Приуралье.

In the 10th – 13th centuries, the common Bulgar ethnos shaped up within the borders of the Volga Bulgaria, while the state itself turned into the country of the highly developed farming, cattle-breeding, urban development, crafts and trade. The towns of Bilyar, Bolgar, Juketau, Oshel, Suvar, and so on became the leading centres of material and spiritual culture not only of the Volga Bulgaria and Bulgars, but also of many other tribes (peoples) that inhabited the Volga and Cisurals regions.



Тар муенлы балчык чүлмәкләр, җамаяк. XII – XIII йөзләр

Глиняные кувшины и миска. XII – XIII вв.

Pottery jars and bowl. 12th – 13th centuries



Геометрик рәсем төшерелгән бронза көзгеләр.
XIII – IV йөзләр

Бронзовые зеркала с геометрическим орнаментом.
XIII – XIV вв.

Bronze mirrors with geometric ornament.
13th – 14th centuries



Ялтыравык белән капланган кәрәч касә. XIII – XIV йөзләр

Глазурованная керамическая чаша. XIII – XIV вв.

Glazed ceramic bowl. 13th – 14th centuries



Читендә «Ulfberht» язулы кылыч. X йөз

Меч с надписью на клинке «Ulfberht». X в.

Sword with inscription on the blade «Ulfberht». 10th century



Читендә «Ulfberht» язулы кылыч. X – XI йөз башы

Меч с надписью на клинке «Ulfberht». X – начало XI в.

Sword with inscription on the blade «Ulfberht». 10th or early 11th century



Хәрби битлек. XIII в.

Боевая маска-забрало. XIII в.

Visor-mask. 13th century



Уктан атканда кулны саклау өчен сөяк калкан. Биләр. XII – XIII йөзләр

Костяная накладка для защиты руки при стрельбе из лука. Биляр. XII – XIII вв.

Bone plate to protect hand when shooting the bow. 12th – 13th centuries



Кораллы Алтын Урда сугышчысы. XIV йөз. Реконструкция

Реконструкция вооружения золотоордынского воина. XIV в.

Reconstructed armament of the Golden Horde warrior of the 14th century



Сөңге очлыклары. Олы Тархан каберлеге. VIII гасырның икенче яртысы – IX йөзнең беренче яртысы

Наконечники копья. Большетарханский могильник. Вторая половина VIII – первая половина IX в.

Spearheads from the Bolshetarkhansky barrow. 2nd balf of the 8th or 1st balf of the 9th century



Кылыч кынының бронза очлыгы. Болгар. XI йөз

Бронзовый наконечник ножен меча. Булгар. XI в.

Bronze chape of the sword scabbard from Boulgar. 11th century



Р. Ф. Хуҗин. Иман өчен. Болгар өчен. 2008 – 2010

Р. Ф. Хузин. За веру. За Булгарию. 2008 – 2010

R. F. Khuzin. For faith. For Bulgaria. 2008 – 2010



Бизәкле йөзлекле балта. Биләр. X – XI йөзләр

Топор с орнаментированным лезвием. Биляр. X – XI вв.

Axe with ornamented blade. Bilyar. 10th – 11th centuries



Кургаш куелмалы һәм чокылган тамгалы сөяк кистән. X – XIII йөзләр

Костяной кистень со свинцовыми вставками и с выгравированной тамгой. X – XIII вв.

Bone bludgeon with lead inserts and engraved tamga. 10th – 13th centuries



Бронза кистән. Болгар. XIII – XV йөзләр

Бронзовый кистень. Булгар. XIII – XV вв.


Bronze bludgeon. Boulgar. 13th – 14th centuries



Пирамида сыман чыгынтылы һәм томшыклы чукмар. XII – XIV йөзләр

Булава с пирамидальными выступами и клювом. Булгар. XII – XIV вв.

Mace with pyramidal spikes and a beak. Bulgar. 12th – 14th centuries




Алтын Урда (Җүчи Олысы) картасы. 1240 еллар

Карта Золотой Орды (Улус Джучи). 1240-е

Map of the Golden Horde (Ulus Juchi). 1240s



Кызыл пулат. XIV йөз

Красная палата. XIV в.

The Red Chamber. 14th century

## Җүчи Олысы һәм урта гасыр татар ханлыклары барлыкка килү

1236 – 1237 елларда монголларның яулап алуы нәтиҗәсендә Идел буе Болгары яшәүдән туктый, XIII гасырның икенче яртысында аның территориясе Җүчи Олысы (Алтын Урда) составына керә. Алтын Урда чорында (1269 – 1502) чыңгызыйлар-җүчиләр империясендәге төрки телле халыкларның иҗтимагый-сәяси һәм этномәдәни берләшүе һәм урта гасырлар татар этносы формалашу белән бәйле төп процесслар бара. Хәзерге вакытта Алтын Урда цивилизациясенең нык үскән булуын дәлилләгән 150 ләп шәһәр билгеле. Болгар, Җүкәтау, Иске Казан, Казан, Кашан, Кирмәнчек һәм башка шәһәрләр Алтын Урданың Болгар олысында идарә итү, һөнәрчелек һәм җитештерү, сәүдә, мәдәни һәм дини тормыш үзәкләре булып торганнар.

Төрбә. XIV йөз

Мавзолей. XIV в.

Mausoleum. 14th century

## Улус Джучи и формирование средневековых татарских ханств

В 1236 – 1237 гг. в результате монгольского завоевания Волжская Булгария прекратила своё существование, её территория во второй половине XIII в. вошла в состав Улуса Джучи (Золотой Орды). В золотоордынский период (1269 – 1502 гг.) произошли основные процессы общественно-политической и этнокультурной консолидации тюркоязычных народов империи Чингизидов – Джучидов и формирования средневекового татарского этноса. В наши дни известно около 150 золотоордынских городов, свидетельствовавших о развитости золотоордынской цивилизации. Болгар, Джукетау, Иски-Казань, Казань, Кашан, Керменчук и другие города были средоточием административной власти, ремесленных производств, торговли, культурной и конфессиональной жизни Булгарского улуса Золотой Орды.

## Ulus Juchi and Formation of Mediaeval Tatar Khanates

In 1236 – 1237, the Volga Bulgaria ceased to exist as a result of the Mongol conquest, and its territory – in the second half of the 13th century – became part of Ulus Juchi (the Golden Horde). During the Golden Horde period (1269 – 1502) there have occurred the main processes of social-political and ethno-cultural consolidation of the Turkic-speaking peoples of the Empire of the Chingisids – Juchids and of the formation of the mediaeval Tatar ethnos. At present, some 150 Golden Horde towns are known, which testifies to the developed nature of the Golden Horde civilisation. Bolgar, Juketau, Iski-Kazan, Kazan, Kashan, Kermenchuk, and other towns were the centres of administrative power, handicraft industry, trade, cultural and religious life of the Bulgar Ulus of the Golden Horde.

Кече манараның тәрәзә уемы. Болгар. XIV йөз


Оконный проём Малого минарета. Болгар. XIV в.

Window aperture of the Smaller Minaret. Bolgar. 14th century





Тарихи чыганаклар Казан ханлыгы оешканчы ук Урта Идел буенда мәркәзе Казан саналган ниндидер бер дәүләт булуы турында сөйли. Батый ханның улы Сартак тарафыннан XIII гасыр уртасында «Казан Урдасы» оештырылуы турында дәлилләр бар. XIV гасырда Болгар, Җүкәтау, Кирмәнчек шәһәрләре белән беррәттән, Казан җирле әмирлекләрдән («кенәзлекләрдән») берсенең нәкъ менә сәяси үзәге буларак телгә алына.





Ф. Г. Халиков. Казанның башлангычы. 1997

Ф. Г. Халиков. Начало Казани. 1997

F. G. Khalikov. The beginning of Kazan. 1997




Майолика. Кисәкләр. XIV йөз

Майоликовые плитки. Фрагменты. XIV в.

Majolica tiles. Fragments. 14th century

Исторические источники свидетельствуют о наличии в Среднем Поволжье некоего государственного образования с центром в Казани ещё до возникновения Казанского ханства. Имеются свидетельства о том, что «Казанская Орда» была образована сыном хана Бату Сартаком в середине XIII в. В XIV в. Казань, наряду с городами Болгар, Джукетау и Керменчук, упомянута именно как политический центр одного из местных эмиратов («княжеств»).

Historical sources testify to the existence in the Middle Volga Region of some state formation with its centre in Kazan well before the establishment of the Kazan Khanate. There is evidence that the “Kazan Horde” was established by Sartaq, son of Batu Khan, as early as in the mid-13th century. In the 14th century, Kazan, along with the towns of Bolgar, Juketau, and Kermenchuk, was mentioned exactly as a political centre of one of the local emirates (principalities).





Ялтыравык белән капланган плиткәләр һәм мозаика. XIV йөз

Глазурованные плитки и мозаика. XIV в.

Glazed tiles and mosaic. 14th century



Ф. Г. Халиков. Борынгы Казанга сәүдәгәрләр килү. 2003

Ф. Г. Халиков. Прибытие торговцев в древнюю Казань. 2003

F. G. Khalikov. Arrival of merchants in ancient Kazan. 2003



Аждаһа тоткалы алтын савыт. XIII йөз

Золотая чаша с ручкой в виде дракона. XIII в.

Golden bowl with a dragon-shaped handle. 13th century



Касә. Иран. XIV йөз башы

Кубок. Иран. Начало XIV в.

Cup. Iran. Early 14th century



Ялтыравык белән капланган савыт. XIV йөз

Блюдо, покрытое глазурью. XIV в.

Glazed dish. 14th century



«Казан таҗы». XVI йөз. Мәскәү Кремленең Корал палатасы

«Казанская шапка». XVI в. Оружейная палата Московского Кремля

"The Kazan Cap". 16th century. Armoury of the Moscow Kremlin




Казан ханлыгы картасы (1438 – 1552)

Карта Казанского ханства (1438 – 1552)

Map of the Kazan Khanate (1438 – 1552)

Җүчи Олысының таркалуы нәтиҗәсендә Алтын Урда цивилизациясе традицияләрен дәвам иткән һәм бердәм Урта гасыр конфедерациясе тәшкил иткән яңа дәүләтләр «йолдызлыгы» барлыкка килгән. 1438 елда башкаласы Казан булган Казан ханлыгы оешa, ул Идел буе Болгар дәүләтенең һәм Алтын Урданың этномәдәни һәм социаль-икътисади традицияләрен мирас итеп ала. Дәүләтнең территориясе 5 өлкәгә: Алат, Арча, Гәреч, Җөри һәм Нугай «даруга»ларына (өлкәләренә) бүленә. Казан ханлыгында IX – XIV гасырларда корылган 700 дән артык кальга, шәһәр һәм авыл булган. Казан, Алабуга, Арча, Болгар, Җөри, Иске Казан, Кашан, Тәтеш, Чаллы һәм башка шәһәрләр ханлыкның алга киткән хәрби-сәяси һәм мәдәни-икътисади үзәкләре саналган.

Распад Улуса Джучи привёл к появлению целого «созвездия» новых государств, продолживших традиции золотоордынской цивилизации и представлявших собой целостную средневековую конфедерацию. В 1438 г. образовалось Казанское ханство со столицей в Казани, унаследовавшее этнокультурные и социально-экономические традиции Волжской Булгарии и Золотой Орды. Территория государства делилась на 5 «даруг» (областей): Алатскую, Арскую, Галицкую, Зюрейскую и Ногайскую. В Казанском ханстве было более 700 крепостей, городов и поселений, возникших в IX – XIV вв. Казань, Алабуга, Арча, Болгар, Жэри, Иски-Казань, Кашан, Тятеш, Чаллы и другие города представляли собой развитые военно-политические и культурно-экономические центры ханства.

The collapse of Ulus Juchi resulted in the emergence of a "constellation" of new states that continued the traditions of the Golden Horde civilisation and represented an integrated mediaeval confederation. In 1438, the Kazan Khanate was formed with its capital in Kazan. The Khanate inherited the ethno-cultural and social and economic traditions of the Volga Bulgaria and the Golden Horde. The territory of the state was divided into 5 darugas (regions): the Alat, Arsk, Gali, Zyuri, and the Nogai ones. The Kazan Khanate had over 700 fortresses, towns, and settlements that emerged in the 9th – 14th centuries. Kazan, Alabuga, Archa, Bolgar, Jeri, Iski-Kazan, Kashan, Tyatesh, Chally and other towns were the developed military, political, cultural and economic centres of the khanate.







А. Н. Хисамов. Ибраһим хан. 2016.
*Ибраһим (1467 – 1479), Казан ханы*

А. Н. Хисамов. Хан Ибрагим. 2016.
*Ибрагим (1467 – 1479), казанский хан*

A. N. Khisamov. Ibrahim Khan. 2016.
*Ibrahim (1467 – 1479), the Kazan khan*



А. Н. Хисамов. Сәхибгәрәй. 2017.
*Сәхибгәрәй (1500 – 1551), Казан һәм Кырым ханы*

А. Н. Хисамов. Сахиб-Гирей. 2017.
*Сахиб-Гирей (1500 – 1551), казанский и крымский хан*

A. N. Khisamov. Sahib-Giray. 2017.
Sahib Giray (1500 – 1551), the Kazan and the Crimean khan

А. Н. Хисамов. Олуг Мөхәммәд хан. 2018.
*Олуг Мөхәммәд (1405 – 1445), Казан ханлыгына нигез салучы һәм аның беренче ханы*

А. Н. Хисамов. Хан Улуг-Мухаммад. 2018.
*Улуг-Мухаммад (1405 – 1445), основатель и первый хан Казанского ханства*

A. N. Khisamov. Ulugh-Muhammad Khan. 2018.
*Ulugh-Muhammad (1405 – 1445), founder and the first khan of the Kazan Khanate*

Рус кенәзлекләре, төньяк халыклары, шулай ук Үзәк Азия һәм Кавказ илләре белән сәүдә-икътисад элемтәләре ханлык тормышында әһәмиятле роль уйнаган. Дәүләтнең халкын 450 меңгә якын кеше – хәзерге Казан татарларының, башкорт, мари, мордва, чуваш һәм удмуртларның ханга ирекле рәвештә буйсынган бабалары тәшкил иткән.

Важную роль в жизни ханства играли торгово-экономические связи с русскими княжествами, северными народами, а также со странами Центральной Азии и Кавказа. Население государства составляли добровольно подчинившиеся ханской власти предки современных казанских татар, башкир, марийцев, мордвы, чувашей и удмуртов общей численностью около 450 тысяч человек.

An important role in life of the khanate was played by trade and economic links with Russian principalities, northern peoples, as well as with the countries of central Asia and the Caucasus. The population of the state consisted of ancestors of the present-day Kazan Tatars, Bashkirs, Mari, Mordvinians, Chuvashes, and Udmurts who resigned themselves voluntarily to khan's power. The total population was about 450 000.



Казан Кремлендә казу эшләре вакытында табылган күн ук савыты. XVI йөз

Кожаный колчан из раскопок Казанского Кремля. XVI в.

Leather quiver from excavations in the Kazan Kremlin. 16th century



Сәхибгәрәй хан ярлыгы. 1523

Ярлык хана Сахиб-Гирея. 1523

Yarlyk of Sahib Giray Khan. 1523



Сөңге очы. XV – XVI йөзләр

Наконечник копья. XV – XVI вв.

Spearhead. 15th – 16th centuries



Кылыч. XV – XVI йөзләр

Сабля. XV – XVI вв.

Sabre. 15th – 16th centuries



А. Н. Хисамов. Мөхәммәдъяр. 2005.
*Мөхәммәдъяр (1496 яки 1497 – 1549), шагыйрь*

А. Н. Хисамов. Мухаммадьяр. 2005.
*Мухаммадьяр (1496 или 1497 – 1549), поэт*

A. N. Khisamov. Muhammadyar. 2005.
*Muhammadyar (1496 or 1497 – 1549), poet*



Р. Г. Заһидуллин.
Казан XVI йөздә. 1993

Р. Г. Загидуллин.
Казань в XVI в. 1993


R. G. Zagidullin. Kazan
in the 16th century. 1993



Тар муенлы чүлмәк. Җиз. XVI йөзнең беренче яртысы

Кувшин. Латунь. Первая половина XVI в.

Jug. Brass. First half of the 16th century



Казан Кремлендә казу эшләре вакытында табылган ярымкыйммәтле ташлардан эшләнгән муенса калдыклары

Бусины из полудрагоценных камней из раскопок Казанского Кремля

Beads from semi-precious stones from excavations in the Kazan Kremlin



Казан Кремлендә казу эшләре вакытында табылган сөяктән ясалган әйберләр

Костяные изделия из раскопок Казанского Кремля

Ivorywork from excavations in the Kazan Kremlin





Ф. Г. Халиков
Сөембикәнең хушлашуы.
2001

Ф. Г. Халиков. Прощание
Сююмбики. 2001

F. G. Khalikov. Farewell
of Syuyumbike. 2001

Алтын Урда җирләренең варисы булу, Идел-Урал төбәгендә хакимлек итү өчен Мәскәү һәм Казан арасында барган озын-озак һәм кискен көрәш 1552 елның 2 октябрендә Казанның алынуы белән тәмамлана. Казан өчен барган аяусыз һәм каты сугышлардан соң, 1556 елда ханлык территориясе тулысынча Мәскәү дәүләте составына кертелә.

Длительная и упорная борьба между Москвой и Казанью за золотоордынское территориальное наследство, за господство в Волго-Уральском регионе завершилась падением Казани 2 октября 1552 г. В 1556 г. в процессе ожесточённых казанских войн территория ханства окончательно вошла в состав Московского государства.

The long and persistent struggle between Moscow and Kazan for the territorial heritage of the Golden Horde and for the rule in the Volga-Urals Region ended with the fall of Kazan on 2 October 1552. In 1556, the territory of the khanate was completely annexed by the Moscow State as a result of fierce wars for Kazan.




Г. Меркатор – Ю. Хондиусның «Атлас»ыннан алынган «Тартария» картасы. Амстердам, 1607

Карта «Тартарии» из «Атласа» Г. Меркатора – Ю. Хондиуса. Амстердам, 1607

The map of "Tartaria" from the Atlas by G. Mercator and J. Hondius. Amsterdam, 1607



Казанны тупка тоту. XVI йөз елъязмалар тупланмасы. Патшалык китабы

Обстрел Казани из пушек. Летописный свод XVI в. Царственная книга

The gunning of Kazan. Chronicle of the 16th century. Regal Book



Татарлар русларны чокырга якын китермәскә тырышып көрәшәләр. XVI йөз елъязмалары тупланмасы. Патшалык китабы

Татары бьются, не желая допустить русских до рва. Летописный свод XVI в. Царственная книга

The Tatars are fighting to prevent the Russians reach the moat. Chronicle of the 16th century. Regal Book



## Россия империясе шартларында татар милләтенең формалашуы

Рәсми рәвештә Казан патшалыгы дип аталган Казан төбәге «болгавыр дәвер» (XVI йөз ахыры – XVII гасыр башы) вакытында, асылда, Мәскәүдән аерымланган була. Казандагы югары феодаль катлауның башлыгы Никонор Шульгин булган бер өлешендә аерым дәүләт төзү идеясе туа, анда җитәкче рольне җирле рус аксөякләре төркеме уйнарга тиеш дип уйланыла. Казанда бу сәяси фетнә Михаил Романовның 1613 елда патша итеп сайлануына кадәр дәвам итә.

## Татарское нациестроительство в условиях Российской империи

[illegible] указываютъ, что Володарскій въ данномъ случаѣ говорилъ отъ своего личнаго имени, отнюдь не отражая настроеній и взглядовъ не только правой части большевиковъ, но и лѣвыхъ группъ. Совѣтъ нар. комиссаровъ [illegible] отнюдь не является учрежденіемъ, власть котораго перманентна. Не только Учр. Собраніе, но и Ц. И. К. можетъ въ любой моментъ цѣликомъ перемѣнить и обновить составъ совѣта нар. комиссаровъ, равно какъ и законно замѣнить права и функціи совѣта. Но, конечно у представителей совѣтской власти существуетъ твердое убѣжденіе, что большинство членовъ Учр. Собранія одобритъ тактику и линію поведенія совѣта нар. комиссаровъ, какъ органа отражающаго интересы рабочихъ и крестьянъ, т. е. фактическаго большинства населенія Россіи.

*Н. Ж.*

«Бөтенроссия меселманнары хәрби шурасы хәбәрләре» газетасы. 1917. № 1

Газета «Известия Всероссийского мусульманского военного совета». 1917. № 1

The Izvestiya Vserossiyskogo Musulmanskogo Voyennogo Shuro (News of the All-Russian Muslim Military Committee newspaper. 1917. No. 1

## Татар милли дәүләтчелеге формаларын эзләү


1917 елның 3 ноябрендә большевиклар Россия халыкларының хокуклары Декларациясен бастырып чыгара. Ул Россия халыкларына иң зур хокуклар вәгъдә итә. Ноябрь ахырында И. В. Сталин җитәкчелегендә РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты оештырыла, 1918 елның гыйнварында әлеге наркомат составында Эчке Россия мөселманнарны эшләре буенча комиссариат формалаша, җитәкчесе итеп М. Вахитов куела. Ноябрь аенда Эчке Россия һәм Себер төрки-татарлары мәдәни-милли мохтариятенең 22 июльдә игълан ителгән Декларациясен тормышка ашыру процессы дәвам итә. 22 ноябрьдә Уфада Милли

## Поиск форм татарской национальной государственности

3 ноября 1917 г. большевики опубликовали Декларацию прав народов России, которая обещала народам России самые широкие права. В конце ноября был создан Народный комиссариат по делам национальностей РСФСР во главе с И. В. Сталиным, в январе 1918 г. в составе Наркомата формируется Комиссариат по делам мусульман Внутренней России во главе с М. Вахитовым. В ноябре продолжается процесс по реализации провозглашённой 22 июля Декларации культурно-национальной автономии тюрко-татар Внутренней России и Сибири. С 22 ноября в Уфе начало работу Национальное собрание (около 100 депутатов). 29 ноября на собрании было принято

## Seeking the Forms of the Tatar National Statehood

On 3 November 1917, the Bolsheviks published a Declaration of Rights of Peoples of Russia, which promised broad rights and freedoms to the peoples of Russia. The People's Commissariat for Nationalities of the RSFSR was established at the end of November with Joseph Stalin being its head. In January 1918, the Commissariat for Muslim Affairs of the Inner Russia was created within the People's Commissariat headed by M. Vakhitov. The process of implementation of the Declaration of national cultural autonomy of the Turkic Tatars of the Inner Russia and Siberia that was aired on 22 July continued in November.




Урта Идел һәм Көньяк Урал Штатының схематик сызымы. Казан, 1918

Схематический чертёж Средне-Волжского и Южно-Уральского Штата. Казань, 1918

Sketch drawing of the Middle-Volga and South-Ural State. Kazan, 1918





«Чыңгыз баласы» газетасы, Казан мөселман хәрби гарнизоны органы. Казан, 1918. № 3

Газета «Чыңгыз баласы» («Дитя Чингиза»), орган Казанского мусульманского военно-гарнизонного комитета. Казань, 1918. № 3

The Chyngyz Balasy (The Child of Genghis), an organ of the Kazan Muslim Military Garrison Committee. Kazan, 1918. No. 3




Идел-Урал Республикасы автономиясен игълан итү. Белдеру. Казан, 1918

Торжественное провозглашение автономии Идель-Уральской республики. Афиша. Казань, 1918

Billboard. Official proclamation of autonomy of the Idel-Ural Republic. Kazan, 1918.

Мәҗлес үз эшен башлый (якынча 100 депутат). 29 ноябрь көнне мәҗлес Идел-Урал Штаты формасында татар һәм башкорт халыкларының милли дәүләтчелеген төзү турында карар кабул итә. Штат территориясенә Казан һәм Уфа губерналары, Вятка, Оренбург, Пермь, Самара, Сембер губерналарындагы кайбер өязләр, шул исәптән чуваш һәм мари җирләре дә керергә тиеш була (барлык халкы – 7 миллионнан артык кеше, шуның 51 % ы – татарлар һәм башкортлар). Өч министрлыктан (финанслар – Малия нәзарәте, белем бирү – Мәгариф нәзарәте, дини идарә – Дияния нәзарәте) һәм ике комитеттан (хәрби һәм тышкы эшләр) торган Милли Идарә иң югары башкарма орган дип билгеләнә. 1918 елның 5 гыйнварында Милли Идарә рәисе итеп С. Максуди сайлана. Штатны төзү буенча әзерлек эшләре Идел-Урал Штатын гамәлгә ашыру коллегиясенә йөкләнә.

решение о создании национальной государственности татарского и башкирского народов в форме Урало-Волжского Штата. В территорию Штата должны были войти Казанская и Уфимская губернии, часть уездов Вятской, Оренбургской, Пермской, Самарской, Симбирской губерний, включая чувашские и марийские земли (с населением свыше 7 млн человек, из них свыше 51 % – татары и башкиры). Высшим исполнительным органом был определён Милли Идаре, состоявший из трёх министерств (финансов – Малия назарате, просвещения – Магариф назарате, Духовного управления – Диния назарате ) и двух комитетов (военного и иностранных дел). 5 января 1918 г. председателем Милли Идаре был избран С. Максудов. Подготовительная работа по учреждению Штата была возложена на Коллегию по осуществлению Урало-Волжского Штата.

Starting from 22 November the National Assembly (consisting of some 100 deputies) began working in Ufa. On 29 November, the meeting of the Assembly made a decision to establish the national statehood of the Tatar and Bashkir peoples in the form of the Urals-Volga State. The territory of the State should have included the Kazan and Ufa Provinces, a number of districts of the Vyatka, Orenburg, Perm, Samara, and Simbirsk provinces, including the Chuvash and Mari lands (with the population exceeding 7 million, of which over 51 % were the Tatars and Bashkirs). Milli Idare was declared to be the supreme body of executive power, consisting of three Ministries (of Finance: Maliya Nazarate, of Education: Magarif Nazarate, and the Spiritual Board: Diniya Nazarate) and two Committees (for Military and for Foreign Affairs). On 5 January 1918, S. Maksudov was elected chairman of Milli Idare. The preliminary work for the establishment of the State was entrusted to the Board for Fulfilment of the Urals-Volga State.

1918 елның 5 гыйнварында Учредительное собраниедә «Россиянең дәүләт төзелеше турындагы карар» кабул ителү һәм Россия Демократик Федерациясе игълан ителү белән, демократик көчләрнең татар-башкорт берләшмәсендә үзәктән китү хәрәкәте арта. Башкорт Шурасы һәм Башкорт корылтае делегатлары мөстәкыйль Башкорт мохтарияте төзү идеясе белән чыгыш ясый. Әмма, шуңа да карамастан, Идел-Урал Штатын булдыру эшләре тукталмый: 1918 елның 16 гыйнварында «Эчке Россия һәм Себер мөселман төрки-татарлары милли мохтариятенең төп нигезләмәләре» Конституциясенең проекты басылып чыга, Штатны төзү турында универсал эшләнә, 1918 елның 1 марты Штатны игълан итү датасы итеп билгеләнә.

Бу рәсми чара Казанның Театр мәйданында узарга тиеш була. Әмма Идел-Урал Штатын гамәлгә ашыру большевиклар хөкүмәтенең планнарыннан кискен аерыла. Идел-Урал Штаты оешуга каршы килү максаты белән Казан Советы, башбаштакланып, 26 февральдә Казан Совет Эшче-Крестьян Республикасы төзи, аның Я. С. Шейнкман җитәкчелегендәге хөкүмәтен булдыра, Казанда хәрби хәл кертә һәм Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең II корылтаеның Төрки-татар Штаты игълан итәргә җыенган җитәкчеләрен 27 февральдән 28 февральгә каршы төндә кулга ала. Аларны кулга алуга җавап итеп, 1918 елның 1 мартында татар халкының (якынча 10 мең кеше) демонстрациясе була. Анда катнашучылар хакимият алдына кулга алынганнарны азат итү һәм милли дәүләтчелек игълан итү таләпләрен куя.

Җитәкчеләре кулга алынганнан соң, хәрби корылтай делегатлары 57 мең солдат-мөселман исеменнән Милләт Мәҗлесенә тугрылыклары турында ант бирәләр. Делегатлар Болак аръягына, ягъни Казанның Татар бистәсенә күчә һәм хәрби корылтайның эшен яңарта. Большевикларның революцион штабы әлеге территорияне «Болак

С принятием 5 января 1918 г. на Учредительном собрании «Постановления о государственном устройстве России» и провозглашением Российской Демократической Федерации в татаро-башкирской коалиции демократических сил усилились центробежные силы. Делегаты Башкирского Шуро и Башкирского курултая выступили с идеей о создании самостоятельной Башкирской автономии. Несмотря на это работа по созданию Урало-Волжского Штата не прекращалась: 16 января 1918 г. был опубликован проект Конституции «Основные положения национальной автономии мусульман тюрко-татар Внутренней России и Сибири», составлен универсал об образовании Штата, на 1 марта 1918 г. назначена дата его провозглашения.

Это официальное мероприятие должно было состояться на Театральной площади в Казани. Однако учреждение Урало-Волжского Штата в корне расходилось с планами большевистского правительства. С целью противодействия образованию Урало-Волжского Штата Казанский Совет 26 февраля создал самочинную Казанскую Советскую Рабоче-Крестьянскую Республику, сформировал её правительство во главе с Я. С. Шейнкманом, ввёл в Казани военное положение и в ночь с 27 на 28 февраля арестовал руководителей 2-го Всероссийского мусульманского военного съезда, попытавшихся провозгласить тюрко-татарский Штат. 1 марта 1918 г. в ответ на их арест в Казани состоялась многотысячная демонстрация татарского населения (около 10 тысяч человек), участники которой требовали от властей освобождения арестованных и провозглашения национальной государственности.

После ареста руководителей делегаты военного съезда от имени 57 тысяч солдат-мусульман принесли клятву верности Миллэт Меджлиси. Делегаты военного съезда перешли в Татарскую слободу Казани, за протоку

Following the adoption, on 5 January 1918, of the Resolution on the State Structure of Russia by the Constituent Assembly and the declaring of the Russian Democratic Federation, the Tatar-Bashkir coalition of democratic forces faced the enhancement of the centrifugal forces. The delegates of the Bashkir Shura and the Bashkir Kurultai proposed an idea to establish an independent Bashkir autonomy. However, despite all this, the work aimed at the establishment of the Urals-Volga State did not stop: on 16 January 1918, the draft Constitution was published under the title “Fundamental Provisions of National Autonomy of the Turkic-Tatar Muslims of the Inner Russia and Siberia, and a Proclamation on the establishment of the State was prepared. The date of its declaration was set for 1 March 1918.

This official event was to be held on the Theatre Square in Kazan. However, the establishment of the Urals-Volga State completely did not match the plans of the Bolshevik government. To oppose the establishment of the Urals-Volga State, the Kazan Council established, on 26 February, the self-constituted Kazan Soviet Workers' and Peasants' Republic, formed its government headed by Y. S. Sheinkman, introduced martial law in Kazan, and, on the night of 27 and 28 February, arrested the leaders of the Second All-Russian Muslim Military Congress, which attempted to proclaim the Turkic-Tatar State. On 1 March 1918, a demonstration of the Tatar population took place in Kazan bringing together thousands of people (some 10 000 participants) in response for their arrest, which demanded from the authorities to release the arrested leaders and to declare national statehood.

After the arrest of the leaders, the delegates of the military congress swore an oath of loyalty to Millet Mejlisi on behalf of 57 000 Muslim soldiers. The delegates of the military congress moved to the Tatar Settlement of Kazan having crossed the Bulak Channel and resumed the work of the Congress. The Bolshevik




Идел-Урал Штаты картасы

Карта Урало-Волжского Штата

Map of the Urals-Volga State



Бөтенроссия мөселман коммунистларының I корылтае делегатлары. 1918 елның 4 – 12 ноябре

Делегаты I Всероссийского съезда мусульманских коммунистов. 4 – 12 ноября 1918

Delegates of the I All-Russian Congress of Muslim Communists. 4 – 12 November 1918



Г. Шәрәф, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, тел белгече. Милләт Мәҗлесе депутаты, Идел-Урал Штатын, Татар-Башкорт СРын һәм ТАССРны оештыру буенча Коллегия рәисе

Г. Шараф, общественный и политический деятель, языковед. Депутат Национального собрания, председатель Коллегии по осуществлению Урало-Волжского Штата, Татаро-Башкирской СР и ТАССР

G. Sharaf, social and political activist, linguist. Deputy of the National Assembly, chairman of the Board for Implementation of the Ural-Volga State, of the Tatar-Bashkir SR and TASSR



Ә. Максуди, сәясәт эшлеклесе, журналист, нәшир, педагог, тел белгече. Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының Милләт Мәҗлесе депутаты (1917 – 1918)

А. Максуди, политический деятель, журналист, издатель, педагог, языковед. Депутат Национального собрания тюрко-татар Внутренней России и Сибири (1917 – 1918)

A. Maksudi, political leader, journalist, publisher, pedagogue, linguist. Deputy of the National Assembly of the Turkic-Tatars of the Inner Russia and Siberia (1917 – 1918)

аръягы республикасы» дип игълан итә. Бу чорда Эчке Россия мөселманнары эшләре буенча комиссариат, Идел буе һәм Урал яны советлары корылтаеның «Идел-Урал Республикасы» турындагы һәм Милләт Мәҗлесенең Идел-Урал Штаты турындагы резолюцияләре эчтәлеген исәпкә алып, Татар-Башкорт Совет Республикасы турында нигезләмә эшли һәм аны 1918 елның 22 мартында игълан итә. Совет җитәкчелеге Идел-Урал Штатына альтернатива буларак Татар-Башкорт Республикасы турындагы нигезләмәне тәкъдим итеп, шул рәвешле татар һәм башкорт милли дәүләтләрен төзүне үз контроленә кертә. 1918 елның 28 мартында җирле большевиклар Петроградтан килгән матрослар белән шәһәрнең Болак аръягы районын яулап ала һәм барысын да коралларын тапшырырга мәҗбүр итә. Февраль инкыйлабы демократиясе дулкынында төзелгән барлык мөселман милли оешмалары (Эчке Россия һәм Себер мөселманнары диния нәзарәтеннән тыш) апрель-май айлары дәвамында таратыла. Совет хакимияте белән хезмәттәшлек итәргә теләмәгән татар милли-демократик хәрәкәте эшлеклеләре (С. Максуди, Г. Исхакый, Ф. Туктаров һ. б.) эмиграциягә китәргә яки иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән баш тартырга мәҗбүр була. Ватанында калганнарның күпчелеге тиздән совет репрессиясе тегермәненә эләгә.

Булак, и возобновили работу съезда. Большевистский революционный штаб объявил эту территорию «Забулачной республикой». В этот период Комиссариат по делам мусульман Внутренней России с учётом содержания резолюции Съезда Советов Поволжья и Приуралья о «Волжско-Уральской Республике» и резолюции Миллэт Меджлиси об Урало-Волжском Штате разработал положение о Татаро-Башкирской Советской Республике и обнародовал его 22 марта 1918 г. Советское руководство, предложив положение о Татаро-Башкирской Республике в качестве альтернативы Урало-Волжскому Штату, смогло взять под свой контроль татарское и башкирское национально-государственное строительство. 28 марта 1918 г. местные большевики с прибывшими из Петрограда матросами заняли забулачный район города и обязали всех сдать оружие. В течение апреля – мая были ликвидированы все мусульманские национальные организации (кроме Духовного управления мусульман Внутренней России и Сибири), созданные на волне февральской революционной демократии. Отказавшиеся от сотрудничества с Советской властью деятели татарского национально-демократического движения были вынуждены эмигрировать (С. Максудов, Г. Исхаки, Ф. Туктаров и др.) или отказаться от общественно-политической деятельности; многие из которых на Родине вскоре попали под жернова советских репрессий.

Revolutionary Headquarters declared that territory the “Trans-Bulak Republic”. At that period the Commissariat for Muslim Affairs of the Inner Russia developed the Regulations for the Tatar-Bashkir Soviet Republic with account for resolutions of the Congress of the Councils of the Volga and Cis-Urals Regions on the “Volga-Urals Republic” and Millet Mejlisi on the Urals-Volga State and published such Regulations on 22 March 1918. The Soviet leadership, having proposed the Regulations for the Tatar-Bashkir Republic as an alternative to the Urals-Volga State, managed to take under its control the Tatar and Bashkir national state-building. On 28 March 1918, the local Bolsheviks, together with sailors from Petrograd, conquered the Trans-Bulak district of the city and made all to lay down the weapons. During the months of April and May all Muslim national organisations, which were created riding on the wave of the February revolutionary democracy, were liquidated (except for the Spiritual Board of Muslims of the Inner Russia and Siberia). Having refused from cooperation with the Soviet power, the leaders of the Tatar national democratic movement had to leave the country (S. Maksudov, G. Iskhaki, F. Tuktarov, and so on) or quitted the social and political activity. The large portion of those who stayed in the country soon fell under the wheels of the Soviet repressions.





Ю. Вәлидов, ТАССРның беренче җир эшләре буенча халык комиссары

Ю. Валидов, первый народный комиссар земледелия Татарской АССР

Y. Validov, first People’s Commissar for Agriculture of the Tatar ASSR



М. Солтангалиев (уртада) Бөтенроссия Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының II корылтае делегатлары арасында. Мәскәү, 1919 елның 15 декабре

М. Султан-Галиев (в центре) среди делегатов II Всероссийского съезда коммунистических организаций народов Востока. Москва, 15 декабря 1919

M. Sultan-Galiev (in the centre) among delegates of the II All-Russian Congress of Communist Organisations of Peoples of the East. Moscow, 15 December 1919

Идел-Урал Штаты, Казан ханлыгы 1552 елда җимерелгәннән соң, татар халкының үз милли дәүләтчелеген торгызу юлында беренче тәҗрибә була. Дәүләтчелекнең бу формасы татарлар тупланып яшәгән урыннарның зур өлешен колачлаган һәм татар милләтенең дә, ул чакта Идел буе һәм Урал яны территориясендә элек-электән гомер иткән күп халыкларның да милли һәм мәдәни мәнфәгатьләренә туры килгән булыр иде.

Урало-Волжский Штат был первым опытом татарского народа на пути возрождения своей национальной государственности после падения Казанского ханства в 1552 г. Эта форма государственности охватывала бы большую часть мест компактного проживания татар и отвечала национальным и культурным интересам как татарского этноса, так и многих народов, локально проживавших тогда на территории Поволжья и Приуралья.

The Urals-Volga State was the first experience of the Tatar people on its way towards revival of its national statehood after the fall of the Kazan Khanate in 1552. This form of statehood would embrace the major portion of locations with the Tatar communities and met the national and cultural interests of both the Tatar ethnos and many other peoples who lived at that time in the territory of the Volga and Cis-Urals regions.



Татар язучылары партия һәм совет эшчеләре арасында. Икенче рәттә (сулдан уңга): 2. Г. Ибраһимов, 3. Ш. Сүнчәләй, 4. Г. Ильясов. Уфа, 1920

Татарские писатели среди партийных и советских работников. Во втором ряду (слева направо): 2. Г. Ибрагимов, 3. Ш. Сунчелей, 4. Г. Ильясов. Уфа, 1920

Tatar writers among Party and Soviet workers. Second row (from left to right): 2. G. Ibraghimov, 3. S. Suncheley, 4. G. Ilyasov. Ufa, 1920


## Казан губернасы территориясендә Гражданнар сугышы

1918 елның уртасыннан илдә зур масштаблы һәм аяусыз Гражданнар сугышы җәелеп китә. Җәен Казан губернасы территориясенең күп өлешен Комуч халык армиясе һәм Чехословак корпусы частьлары яулап ала. 5 августта Казан пристаньнары районына чехословакларның Идел буе төркеме һәм акгвардиячеләр десанты төшә. Казанда һәм аның тирәсендәге бистәләрдә камалыш хәле кертелә һәм гадәттән тыш комендант итеп М. И. Межлаук билгеләнә. Казанны 5 нче Земгаль латыш полкының ике ротасы, Мөселман коммунистлар отряды, 1 нче мөселман социалистик полкы, 1 нче татар-башкорт пехота батальоны, К. Маркс исемендәге Интернациональ батальон һәм эшчеләрдән тупланган ополчение отрядлары яклый. 7 августка каршы төндә Кызыл Армия частьлары зур югалтулар белән Казанны калдыра. Казан басып алынганнан соң, шәһәрдә ак террор башлана: партия һәм совет эшлеклеләре (М. Вахитов, С. Гассар, А. П. Комлев, М. И. Межлаук, Я. С. Шейнкман h. б.), шулай ук совет хакимиятенең башка тарафдарлары кулга алына һәм атып үтерелә. РСФСР алтын запасының Казан банкында саклаган төп өлеше чехословак легионерлары кулына төшә.

Казанны алу чехословак легионерларының һәм Комуч халык армиясенең соңгы уңышы була. 2 нче һәм 5 нче армия гаскәрләре аларны туктатуга һәм камап алуга ирешә. Көнчыгыш фронт гаскәрләре хәрбиләр белән тулыландырылгач һәм корал алгач, Идел хәрби флотилиясе һәм авиация белән үзара бәйләнештә хәрәкәт итеп, канкойгыч сугышлар барышында 1918 елның 5 – 10 сентябрь көннәрендә Казан азат ителә. Көнчыгыш фронт, һөҗүмен көчәйтә барып, 5 нче армия һәм 2 нче армиянең Арча төркеме

## Гражданская война на территории Казанской губернии

С середины 1918 г. в стране развернулась крупномасштабная и ожесточённая Гражданская война. Летом 1918 г. большую часть территории Казанской губернии захватили части Народной армии Комуча и Чехословацкого корпуса. 5 августа в районе казанских пристаней высадился десант Поволжской группы чехословаков и белогвардейцев. В Казани и её пригородах было введено осадное положение, чрезвычайным комендантом назначен М. И. Межлаук. Казань защищали две роты 5-го Земгальского латышского полка, Мусульманский коммунистический отряд, 1-й мусульманский социалистический полк, 1-й пехотный татаро-башкирский батальон, Интернациональный батальон имени К. Маркса, отряды ополченцев из рабочих. Неся большие потери, части Красной Армии в ночь на 7 августа оставили Казань. После захвата Казани в городе был устроен белый террор: арестованы и расстреляны партийные и советские работники (М. Вахитов, С. Гассар, А. П. Комлев, М. И. Межлаук, Я. С. Шейнкман и др.), а также другие сторонники Советской власти. В руках чехословацких легионеров оказалась основная часть Золотого запаса РСФСР, хранившаяся в Казанском банке.



ОБЪЯВЛЕНІЕ.

РЕВОЛЮЦІОННЫЙ ШТАБЪ СИМЪ ОБЪЯВЛЯЕТЪ ГОР. КАЗАНЬ И ГУБЕРНІЮ НА ВОЕННОМЪ ПОЛОЖЕНІИ И БУДЕТЪ ПРЕСѢКАТЬ ВСЯКІЯ ВЫСТУПЛЕНІЯ НАРУШАЮЩІЯ ПОРЯДОКЪ ВЪ ГОРОДѢ И ГУБЕРНІИ БЕЗЪ ВСЯКАГО ПРЕДУПРЕЖДЕНІЯ

Председатель Революціоннаго Штаба Грассисъ

Члены революціоннаго штаба: Ал. Гинцбургъ. Ефремовъ. Дмитріевъ. Якубовъ.

Председатель Совѣта Народныхъ Комиссаровъ Казанской республики Шейнкманъ

Комиссары: Александръ Карповъ. Всеволодъ Скачковъ. С. Брауде. С. Ганшцевъ. Фроловъ. Котляровъ. Моховъ. Шнуровскій.

Инкыйлаб штабының Казанда һәм губернада хәрби хәл кертелү турында хәбәр итүче игъланы

Объявление революционного штаба о введении в Казани и губернии военного положения

Notice from the Revolutionary Headquarters of introduction of martial law in Kazan and Kazan Province



Кызыл Армия частьлары Казан шәһәрендә. 1918 елның 10 сентябре


Части Красной Армии в Казани. 10 сентября 1918

The units of the Red Army in Kazan. 10 September 1918

## Civil War in the Territory of the Kazan Province

Starting from mid-1918, the country plunged into the large-scale violent civil war. In summer 1918, the major portion of the territory of the Kazan Province was captured by troops of the People's Army of KOMUCH (Committee of Members of Constituent Assembly) and of the Czechoslovakian Corpse. On 5 August, the assault forces of the Volga group of the Czechoslovaks and the White Guards landed in the area near the Kazan quays. The state of siege was imposed in Kazan and its suburbs; M. I. Mezhlauk was appointed the Extraordinary Commandant. Kazan was defended by two companies of the 5th Zemgale Latvian Riflemen Regiment, the Muslim Communist Brigade, the 1st Muslim Socialist Regiment, the 1st Rifle Tatar-Bashkir Battalion, the International Battalion named after K. Marx, and the brigades of militiamen composed of workers. Suffering great losses, the units of the Red Army left Kazan in the night of 7 August. After the conquest of Kazan the city was exposed to terror of the Whites: arrested and executed were many Party and Soviet officials (M. Vakhitov, S. Gassar, A. P. Komlev, M. I. Mezhlauk, Y. S. Sheinkman, and so on), as well as other supporters of the Soviet power. The Czechoslovakian legionaries got the major portion of the gold reserve of the RSFSR that was kept in the Kazan Bank.

However, the conquest of Kazan proved to be the last success for the Czechoslovakian legionaries and the People's Army of KOMUCH. The troops of the 2nd and the 5th armies managed to stop and block them. Following the personnel and ammunition replacement, the troops of the Eastern Front have liberated Kazan in coordination with the Volga naval flotilla and the aviation in the course of sanguinary battles on 5 – 10 September 1918. Developing the advance of the Eastern Front, the 5th Army and the Arsk Group of the 2nd Army liberated, by 19 September, the right bank of the Volga as far as to Buinsk, as well as the estuary of the Kama as far as to Laishevo, the 2nd Army liberated, by 8 October, the territory from Chistopol to Agryz, and the 5th Army liberated Bugulma



ПРИКАЗ

по Восточному фронту.

№ 47.

В согласии с решением Революціоннаго Военнаго Совета об'являю гор. Казань с пригородами на ОСАДНОМ ПОЛОЖЕНИИ с момента опубликования сего приказа.

Чрезвычайным Комендантом города с пригородами, назначается т. Иван Межлаук, с подчинением ему всей военной комендатуры.

За распространений ложных слухов и порчу проводов виновные предаются суду военного полевого трибунала.

Вацетис.

Данишевский. Раскольников.

Көнчыгыш фронтның Казанның камалыш хәлендә калуы турындагы 47 нче боерыгы

Приказ по Восточному фронту № 47 об объявлении Казани на осадном положении

The Order No 47 to the Oriental Front declaring Kazan at the stage of siege

19 сентябрьдә – Буага кадәр Иделнең уң як ярын һәм Лаешка кадәр Чулман тамагын, 2 нче армия 8 октябрьгә кадәр – Чистайдан Әгерҗегә кадәрге җирләрне, 5 нче армия ноябрь уртасына Бөгелмәне азат итә. 1918 елның ахырына Казан губернасы территориясендә Комуч халык армиясе һәм Чехословак корпусы частьлары тулысынча җиңелә.

1919 елның язында Казан губернасы территориясенең бер өлешен адмирал А. В. Колчакның акгвардия гаскәрләре яулап ала, ул Иделгә чыгарга, анда генерал А. И. Деникинның ак армиясе белән кушылырга һәм Мәскәү юнәлешендә бергә һөҗүм итәргә ашкына. 1919 елның 4 мартында колчакчылар һөҗүмгә күчә. Колчак ак армиясенең нык басымы белән Көнчыгыш фронт частьлары Алабуга, Минзәлә, Бөгелмә һәм башка торак пунктлардан кысрыклап чыгарыла. 1919 елның апрель уртасына, Казан губернасының көнчыгыш өлешен яулап алып, колчакчылар Нократ елгасында, Казаннан 85 км ераклыкта туктала. Көнчыгыш фронт командованиесе һәм РСФСР җитәкчелеге тарафыннан Иделдә оборона полосасы төзү турында карар кабул ителә. Казанда, Сембер, Самара һәм Саратовта ныгытылган районнар булдырыла. Казанның ныгытылган районына Казанны һәм Кама Тамагыннан Зөягә кадәрге яр буен саклау бурычы йөкләнә. Чистай – Лаеш – Казан һәм Әгерҗе – Мамадыш – Казан юнәлешләрендә оборона корылмалары төзелә; Кама Тамагы, Зөя, Ослан массивы районнары ныгытыла. Көнчыгыш фронтның Көньяк төркемә гаскәрләре 1919 елның 28 апрелендә Богырыслан районында контрһөҗүм башлый. 1919 елның 1 маенда 2 нче армия һәм Идел хәрби флотилиясе Казан губернасы территориясендә актив һөҗүм хәрәкәтләренә күчә. 4 майда – Чистай, 13 майда – Бөгелмә, 29 майда – Алабуга, 1 июньдә Әгерҗе шәһәрләре азат ителә. 1919 елның ахырына колчакчылар тулысынча тар-мар ителә.

Взятие Казани явилось последним успехом чехословацких легионеров и Народной армии Комуча. Войскам 2-й и 5-й армий удалось остановить и заблокировать их. Получив военное пополнение и вооружение, войска Восточного фронта во взаимодействии с Волжской военной флотилией и авиацией в ходе кровопролитных боёв 5 – 10 сентября 1918 г. освободили Казань. Развивая наступление Восточного фронта, 5-я армия и Арская группа 2-й армии к 19 сентября освободили правый берег Волги до Буинска и устье Камы до Лаишева, 2-я армия к 8 октября – территорию от Чистополя до Агрыза, 5-я армия к середине ноября – Бугульму. К концу 1918 г. территория Казанской губернии была полностью освобождена от частей Народной армии Комуча и Чехословацкого корпуса.

Весной 1919 г. часть территории Казанской губернии захватили белогвардейские войска адмирала А. В. Колчака, который стремился выйти к Волге, соединиться там с белой армией генерала А. И. Деникина и вместе наступать в московском направлении. 4 марта 1919 г. колчаковцы перешли в наступление. Части Восточного фронта под натиском белой армии адмирала Колчака были вытеснены из Елабуги, Мензелинска, Бугульмы и других населённых пунктов. К середине апреля 1919 г., захватив восточную часть Казанской губернии, колчаковцы остановились на реке Вятка в 85 км от Казани. Командованием Восточного фронта и руководством РСФСР было принято решение о создании на Волге оборонительной полосы. В Казани, Симбирске, Самаре и Саратове создавались укреплённые районы. На Казанский укреплённый район возлагалась задача обороны Казани и побережья от Камского Устья до Свияжска. Строились оборонительные сооружения на направлениях Чистополь – Лаишево – Казань и Агрыз – Мамадыш – Казань; укреплялись районы: Камское Устье, Свияжск, Услонский массив. 28 апреля 1919 г. в районе Бугуруслана началось контрнаступление войск Южной группы Восточного фронта. 1 мая 1919 г. 2-я армия и Волжская военная флотилия перешли к активным наступательным действиям на территории Казанской губернии. 4 мая был освобождён Чистополь, 13 мая – Бугульма, 29 мая – Елабуга, 1 июня – Агрыз. К концу 1919 г. колчаковцы были полностью разгромлены.

by mid-November. By the end of 1918, the territory of the Kazan Province was fully liberated from the troops of the People's Army of KOMUCH and the Czechoslovakian Corpse.

In spring of 1919, a portion of the Kazan Province was captured by the White Guard troops of Admiral A. V. Kolchak, who wanted to get access to the Volga to be able to tie in with the White Army of A. I. Denikin for further joint advance on the Moscow direction. On 4 March 1919, the Kolchak's troops went onto the offensive. The troops of the Eastern Front lost Yelabuga, Menzelinsk, Bugulma, and other settlements to the White Army of Admiral Kolchak. By mid-April 1919, having conquered the eastern part of the Kazan Province, the Kolchak's troops stopped on the River Vyatka, 85 km from Kazan. The command of the Eastern Front and the leadership of the RSFSR made a decision to create a defence zone on the Volga. The fortified areas were organised in Kazan, Simbirsk, Samara, and Saratov. The task set for the Kazan fortified area was to defend Kazan and the riverside from Kamskoye Ustye to Sviyazhsk. Defensive fortifications were erected on the following directions: Chistopol – Laishevo – Kazan and Agryz – Mamadysh – Kazan; the following areas were fortified: Kamskoye Ustye, Sviyazhsk, and the Uslon land. On 28 April 1919, the counter-attack of the troops of the Southern Group of the Eastern Front began near Buguruslan. On 1 May 1919, the 2nd Army and the Volga naval flotilla moved onto the intensive offensive actions in the territory of the Kazan Province. Chistopol was liberated on 4 May, Bugulma – on 13 May, Yelabuga – on 29 May, and Agryz – on 1 June. By the end of 1919, the Kolchak's troops were completely destroyed.



Кызылгвардиячеләрнең фронтка китүе алдыннан. Шәһәр идарәсе каршында

Перед отправкой на фронт красногвардейцев у городской управы


By the City Council, before dispatching Red Army men to the front



А. Гинцбург исем. 3 нче Казан җыелма полкының хәрбиләр һәм командирлар төркеме

Группа бойцов и командиров 3-го Казанского сводного им. А. Гинцбурга полка

A group of soldiers and commanders of the Third Kazan Mixed Regiment n. a. A. Ginzburg




Казан губернасы территориясендә 1918 – 1919 елларда барган Гражданнар сугышы картасы

Карта Гражданской войны на территории Казанской губернии в 1918 – 1919 гг.

Map of the Civil War in the territory of the Kazan Province in 1918 – 1919



Чехославакия фронтындагы Кызыл бронепоезд. Бронь мәйданчыгында – пехота десанты

Красный бронепоезд на чехословацком фронте. На бронеплощадке – пехотный десант


The Red Armoured Train on the Czechoslovakian front. On a railway armoured truck: infantry assault personnel



Кызыл артиллериянең Казанга керүе. Казан йортларының берсендә калган снаряд шартлау эзе

Вступление Красной артиллерии в Казань. Пробоина от снаряда на одном из домов Казани

The Red artillery entering Kazan. A shot hole in a house in Kazan



Приказъ № 5.

Коменданта г. Казани

на 1-е августа 1918 года.

Казан шәһәре комендантының 1918 елның 1 августында дөнья күргән 5 нче боерыгы

Приказ № 5 коменданта г. Казани от 1 августа 1918

Order No. 5 of the Commandant of Kazan of 1 August 1918

Казан губернасында Гражданнар сугышы кайтавазының соңгы чагылышы 1920 елда Идел буе һәм Урал янының өч губернасын колачлаган «Сәнәкчеләр» фетнәсе була. Кузгалыш Минзәлә өязенең Яңа Ялан авылында 1920 елның февраль аенда башлана. Крестьяннар азык-төлек һәм чимал развёрсткасы җыючы продотрядны үтерел бетерә. Март уртасына фетнә бастырыла. Әлеге чуалыш вакытында якынча 3 мең фетнәче-крестьян һәм 800дән артык кызыларміяче, партия һәм совет хезмәткәре һәлак була.

Последним проявлением рецидивов Гражданской войны на территории Казанской губернии стал «Вилочный» мятеж 1920 г., охвативший территории трёх губерний Поволжья и Приуралья. Восстание началось в д. Новая Елань Мензелинского уезда в феврале 1920 г., когда крестьяне перебили продотряд, собиравший продовольственную и сырьевую развёрстку. К середине марта мятеж был подавлен. Во время мятежа погибло около 3 тысяч мятежников-крестьян и более 800 красноармейцев, партийных и советских работников.

The last relapse of the Civil War in the territory of the Kazan Province was the “Pitchfork revolt” of 1920, which took place in the territory of three provinces of the Volga and Cis-Urals regions. The revolt began in the village of Novaya Yelan in the Menzelinsky District in February 1920, when peasants killed the members of the food-requisition detachment, which was collecting food and raw materials. By mid-March, the revolt was repressed. Some 3 000 rebel peasants and over 800 Red Army men, Party and Soviet officials were killed during the revolt.

## «Хәрби коммунизм» сәясәте һәм аның нәтиҗәләре

«Хәрби коммунизм» вакытында сәнәгать белән идарә итүне катгый үзәкләштерү, сәнәгать һәм азык-төлек товарларын дәүләт тарафыннан бүлү шартлары урнаша; банклар, казна һәм шәхси сәнәгать предприятиеләре, хәтта элек хосусый яки җәмгыятьләр милкендә торган һәм механик двигательдә эшләгән 5 тән артык эшчесе яки двигателе булмаган, әмма эшчеләре 10 нан артык исәпләнгән вак һөнәрчелек йортлары да национальләштерелә. Төп азык-төлек һәм сәнәгать товарлары белән сәүдә итүгә тулысынча монополия кертелә. Халыкны һәм армияне азык-төлек белән тәэмин итү РСФСР Азык-төлек наркоматына һәм аның җирле органнарына йөкләнә. Алар сәнәгать һәм азык-төлек товарларын әзерләүне һәм аларны, карточка системасы кертеп, сыйнфый билгеләргә карап, паёклар рәвешендә бүлүне гамәлгә ашыра. «Кем эшләми, шул ашамый» принцибы үтәлә.

Дәүләтнең тарифлар сәясәтендә тигезләү хакимлек итә. Квалификацияле һәм квалификациясез хезмәткә түләү аермасы зур булмый. «Хәрби коммунизм» чорының ахырына таба хезмәт хакын натуралата түләү арта бара: эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә азык-төлек паёклары, бушлай фатирлар бирелә, коммуналь, транспорт һәм башка хезмәтләр күрсәтелә. Халыкка азык-төлек продуктларын, киң куллану әйберләрен бушлай җибәрү, эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә бирелә торган һәртөрле ягулыкка түләүне бетерү; яшәү урынынан, сууткәргечләрдән,канализациядән, газдан, электрдан файдаланган өчен эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән, хезмәт һәм сугыш инвалидларыннан һәм алар карамагында булган затлардан түләү алуны туктату турындагы совет декретлары товар-акча мөнәсәбәтләренең югала баруына китерә.

## Политика «военного коммунизма» и её последствия

В период «военного коммунизма» установились строжайшая централизация управления промышленностью, государственное распределение промышленных и продовольственных товаров; были национализированы банки, казённые и частные промышленные предприятия, даже мелкие кустарно-промысловые заведения, находившиеся во владении частных лиц или обществ, имевшие свыше 5 рабочих при механическом двигателе или свыше 10 – без двигателя. Полностью была монополизирована торговля основными продовольственными и промышленными товарами. Снабжение населения и армии продуктами возлагалось на Наркомат продовольствия РСФСР и его местные органы, которые осуществляли заготовку и распределение промышленных и продовольственных товаров по карточной системе в виде пайков по классовому признаку. Осуществлялся принцип: «кто не работает, тот не ест».

В тарифной политике государства господствовала уравниловка. Разница в оплате квалифицированного и неквалифицированного труда была незначительной. К концу периода «военного коммунизма» заработная плата принимала всё более натуральный характер: рабочим и служащим выдавался продуктовый паёк, бесплатно предоставлялись квартиры, оказывались коммунальные, транспортные и другие услуги. Советские декреты о бесплатном отпуске населению продовольственных продуктов, предметов широкого потребления, об отмене платы за всякого вида топливо, предоставляемое рабочим и служащим; об отмене взимания платы за жильё, за пользование водопроводом, канализацией, газом, электричеством с рабочих и служащих, инвалидов труда и войны и лиц, находящихся на их иждивении, привели к свёртыванию товарно-денежных отношений.

## Policy of “Military Communism” and Its Consequences

During the period of “Military Communism” there existed the most severe centralisation of administration of the industrial sector, the state-administered distribution of industrial and food products. Nationalised were banks, public and private enterprises, even the small-scale artisan ones, which were owned by individuals or partnerships that had more than 5 workers and a mechanical engine or more than 10 workers and had no mechanical engine. Trade in basic foodstuffs and industrial goods was completely monopolised. Supplying the population and the army with foodstuffs was entrusted to the People’s Commissariat for Food Supplies of the RSFSR and its territorial bodies, which were engaged in procurement and distribution of industrial goods and foodstuffs based on the rationing system in the form of the class-based rations. The governing principle was: “those who do not work do not eat”.

The tariff policy of the state was dominated by wage levelling. The difference in remuneration of skilled and unskilled labour was insignificant. By the end of the “Military Communism” the wages were getting more and more of in-kind nature: the workers and public servants were issued food rations, provided with flats for free, and were rendered the utility, transport, and other services on free of charge basis. The Soviet decrees on the free provision of the population with foodstuffs, consumer goods, on the abolishment of payments for all kinds of fuel for workers and public servants, on the abolishment of payments for housing, for use of water and sewage system, gas, electric power for workers and public servants, as well as for labour and war disabled veterans and for dependent individuals led to the scaling down of commodity/money relations.



Хезмәткә яраклы бөтен халык мәҗбүри хезмәткә тартыла, Казанда һәм башка шәһәрләрдә яшәүчеләрне совхозларда һәм башка халык хуҗалыгы объектларында эшләүгә көчләп мобилизацияләү үткәрелә. Моннан качучылар административ һәм җинаять җаваплылыгына тартыла, Казандагы, Зөядәге һ. б. урыннардагы хезмәт белән төзәтү лагерьларына җибәрелә. Тоткыннар хезмәте халык хуҗалыгы объектларында файдаланыла. Әлеге чаралар элеккеге җитештерү мөнәсәбәтләрен «коммунистик мөнәсәбәтләр»гә алмаштыруны күздә тота.

Хәрби-коммунистик аграр революция чорында барлык җир милке национальләштерелә һәм җиргә хосусый милек хокукы бетерелә, авыл хуҗалыгы җирләренең күп өлеше авыл халкына тапшырыла, бөтен җирдә хуҗалык итүнең яңа формалары – совхозлар,

Всё трудоспособное население было привлечено к обязательному труду, проводились принудительные трудовые мобилизации среди жителей Казани и других городов для работы в совхозах и на других объектах народного хозяйства. Уклонявшихся привлекали к административной и уголовной ответственности, отправляли в исправительно-трудовые лагеря Казани, Свияжска и др. Труд заключённых использовался на объектах народного хозяйства. Эти мероприятия были направлены на замену прежних производственных отношений «коммунистическими».

В период военно-коммунистической аграрной революции была национализирована вся земельная собственность и ликвидировано частное землевладение, большая часть сельскохозяйственных угодий передана сельским

The entire able-bodied population was involved in compulsory labour. Citizens of Kazan and other towns were forced to work at the Soviet farms and at other national economic projects. Those who attempted to refrain from work were held administratively and criminally liable or sent to corrective labour camps in Kazan, Sviyazhsk, and other towns. The labour of convicts was widely used at various projects of the national economy. These actions were aimed at substitution of the old industrial relations with the “communist” ones.

Nationalised during the period of the military-communist agrarian revolution was the entire land property. Private land property was liquidated. A large portion of agricultural land was handed over to village communities. The new forms

Чистай шәһәрендә Бөек Октябрьнең беренче еллыгын бәйрәм итү. 1918

Празднование первой годовщины великого Октября в Чистополе. 1918

Celebration of the first anniversary of the Great October in the town of Chistopol. 1918

авыл хуҗалыгы коммуналары кертелә. Илдә игълан ителгән азык-төлек диктатурасы РСФСР Азык-төлек халык комиссариатының губерналардагы органнарына «үзләреннән арткан икмәк»не яшергән һәм «күләгәле» базарда икмәк саткан крестьяннар («мешочники») белән көрәштә гадәттән тыш вәкаләтләр бирә. Совет азык-төлек органнарына ярдәм күрсәтү өчен авылларда ярлылар комитетлары булдырыла. Әлеге чаралар икмәк һәм чимал җыюны көчәйтә, әмма шәһәр халкын һәм Казанда, башка торак пунктларда урнашкан Кызыл Армия частьларын азык-төлек белән тәэмин итү мәсәләсен тулысынча хәл итә алмый. 1919 елның гыйнварында гомуми продразвёрстка кертелә, икмәк, азык-төлекның иң кирәкле төрләре һәм чимал белән сәүдә итү тыела. Продразвёрстка планын үтәүне тәэмин итү өчен, Казан губернасы авылларына нигездә күрше губерналарның эшче сыйныф вәкилләреннән торган продотрядлар җибәрелә. 1919 – 1920 елларда крестьяннардан 20 миллион поттан артык икмәк җыеп алына. Моннан тыш, крестьяннар мәҗбүри тәртиптә ит, йомырка, май, бал, печән һәм терлек чималы тапшырырга тиеш була. Тартып алынган азык-төлек һәм чималның зур өлеше губернадан читкә чыгарыла.

Авыл халкының хуҗалык итүдә массакүләм төстә кулланучылык нормасына күчүе белән бәйле рәвештә, дәүләт тарафыннан һәрбер крестьян хуҗалыгына чәчүлек мәйданнарының мәҗбүри күләме һәм авыл хуҗалыгы культураларының мәҗбүри исемлеге җиткерелә. План үтәүне тәэмин итү максатларында чәчүчелек комитетлары һәм орлык тутыру-бушату пунктлары оештырыла. Авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерүне үзәкләштерүне көчәйтә торган бу чаралар аграр тармак мәсьәләләрен хәл итә алмый һәм 1920 еллар башында халык кичергән массакүләм ачлык сәбәпләреннән берсе була.

общинам, повсеместно насаждались новые формы хозяйствования – совхозы, сельскохозяйственные коммуны. Продовольственная диктатура, объявленная в стране, предоставила губернским органам Наркомата продовольствия РСФСР чрезвычайные полномочия по борьбе с крестьянством, укрывавшим так называемые «хлебные излишки» и продававшим хлеб на «теневом» рынке («мешочниками»). Для оказания помощи советским продовольственным органам в деревне были созданы комитеты бедноты. Эти мероприятия усилили поступление хлеба и сырья, но не смогли полностью решить задачу продовольственного обеспечения городского населения и частей Красной Армии, расквартированных в Казани и других населённых пунктах. В январе 1919 г. была введена тотальная продразвёрстка, торговля хлебом и важнейшими видами продовольствия и сырья была запрещена. Для обеспечения выполнения продразвёрстки в сёла Казанской губернии были отправлены продотряды, состоявшие главным образом из представителей рабочего класса соседних губерний. В 1919 – 1920 гг. у крестьян было изъято свыше 20 млн пудов хлеба. Кроме того, в обязательном порядке у крестьян изымались мясо, яйца, масло, мёд, сено и животное сырьё. Большая часть изъятого продовольствия и сырья была вывезена за пределы губернии.

В связи с массовым переходом сельских жителей на потребительскую норму хозяйствования государством до каждого крестьянского хозяйства были доведены обязательные размеры посевных площадей и перечень сельскохозяйственных культур. С целью обеспечения выполнения планов создавались посевкомы и ссыпные пункты семенного материала. Эти мероприятия, усилившие централизацию сельскохозяйственного производства, не смогли решить проблем аграрного сектора и послужили одной из причин массового голода населения в начале 1920-х гг.

of economic activity were broadly forced into application: Soviet farms and agricultural communities. The food dictatorship, which was proclaimed in the country, provided to the provincial bodies of the People's Commissariat for Food Supplies of the RSFSR with special powers for fighting with peasants (the so-called profiteers) who used to conceal the "grain surpluses" and sold grain in the "shadow" market. To render support to the Soviet food-collecting bodies, the councils of the poor were established in villages. These actions improved the situation with the procurement of grain and raw materials, but they could not solve in full the task of provision of food to urban population and the troops of the Red Army that were stationed in Kazan and in other settlements. In January 1919, the total food rationing was introduced, and trade in grain and other most important kinds of foodstuffs and raw materials was prohibited. To ensure that all tasks set for the food rationing system are solved, the food-requisition detachments were sent to villages of the Kazan Province, which were mainly composed of representatives of the working class from the neighbouring provinces. In 1919 – 1920, confiscated from peasants were over 20 million poods of grain. In addition to that, subject to obligatory confiscation from peasants were also meat, eggs, butter, honey, hay, and raw animal material. A large portion of the confiscated food and raw materials was taken out of the province.

Considering the large-scale transfer of rural citizens to the consumer-based system of land-use, the state informed every peasant household of the mandatory dimensions of land under cultivation and issued a list of agricultural crops to be planted. To secure the implementation of the plans, the sowing committees were being established and the seed material collecting stations were being organised. However, these actions, while they have enhanced the centralisation of agricultural production, could not solve the problems in the agrarian sector and served as one of the reasons of the large-scale famine in the early 1920s.

«Хәрби коммунизм» сәясәте сәнәгатьнең түбән тәгәрәвенә, транспорт параличына, финанс упкынына, товарлар һәм азык-төлек дефицитына, авылның ярлылануына, халыкның тәртипсез күченүенә, җинаятьчелек үсүгә китерә – болар исә халыкның, бигрәк тә крестьяннарның, гомуми канәгатьсезлегенә, шулай ук Татарстандагы коточкыч ачлыкка сәбәп булып тора. 30 га якын эре крестьян күтәрелеше килеп чыга. 1921 елның март аенда ил хөкүмәте «хәрби коммунизм»ның нәтиҗәсезлеген танырга һәм яңа икътисади сәясәткә күчәргә мәҗбүр була.

Политика «военного коммунизма» привела к упадку промышленности, транспортному параличу, финансовому коллапсу, товарному и продовольственному дефициту, разорению деревни, стихийной миграции населения и росту преступности, что стало причиной массового недовольства населения, особенно крестьянства, а также голодомора в Татарстане. Произошло около 30 крупных крестьянских выступлений. В марте 1921 г. правительство страны было вынуждено признать несостоятельность «военного коммунизма» и перейти к новой экономической политике.

The policy of the "Military Communism" led to recession in the industrial sector, to the transport paralysis, financial collapse, commodity and food deficit, impoverishment of villages, spontaneous migration of the population, and a rise in crime, which provided the ground for large-scale popular discontent, especially among peasants, and for the forced famine in Tatarstan. Some 30 large peasant insurgencies have occurred in this connection. In March 1921, the government of the country was forced to admit the failure of the "Military Communism" and switched to the new economic policy.

С. Сәетгалиев,ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе; Н. Алимов (башлыктан), мөселман социалистик полкы командиры; Г. Касыймов, Россия коммунистлар партиясенең Татарстан өлкә комитеты бюросы әгъзасы

С. Саид-Галиев, председатель СНК ТАССР; Н. Алимов (в шапке), командир мусульманского социалистического полка, Г. Касимов, член бюро Татарского обкома РКП(б)

S. Said-Galiev, chairman of the Council of the People's Commissars of the Tatar ASSR; N. Alimov (in a hat), commander of the Muslim Socialist Regiment, G. Kasimov, member of the Bureau of the Tatar Regional Committee of RKP(b)



1920 елда Казан губернасында булган «Сәнәк фетнәсе» картасы

Карта Вилочного мятежа 1920 г. в Казанской губернии

Map of the Pitchfork Revolt of 1920 in the Kazan Province






М. Солтангалиев, сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе; И. Фирдәвес, РКП(б) Казан губерна комитеты әгъзасы. 1919
Tatar alphabet based on Cyrillic script. 1939



«Кызыл Татарстан» газетасы

Газета «Красная Татария»

The Krasnaya Tataria Newspaper



JANALIF

«Яңалиф» журналы. 1930, июль, № 1

Журнал «Яналиф». 1930, июль, № 1

Yanalif Magazine. No 1. July 1930



Грамотный, прочитай и расскажи неграмотному.

Uqi əlyce iptəş! Uqь həm uqi əlməycelərgə anlat!

Грамотасызлык белән көрәш турында плакат. 1926

Плакат о борьбе с безграмотностью. 1926

Poster dedicated to struggleagainst illiteracy. 1926

инде сирәк кулланыла. Дәүләт, җәмәгать һәм мәдәният-агарту оешмаларында хезмәткәрләрнең татар телен өйрәнүе бөтенләй диярлек туктала. 1939 елда татар алфавиты кабат үзгәртелә, бу юлы инде латин графикасы рус кириллицасына алмаштырыла. Бу татар халкының алга таба тиз ассимиляциялəшүенә юл ача.

1920 елларда вакытлы матбугат аеруча үсеш ала: төрле журнал-газета басмалары чыга, аларның тиражы сизелерлек арта. Республика матбугаты үсеше өчен нәкъ менә бу чорда нигез салына, вакытлы матбугат басмалары ТАССРның ике дәүләт телендә – рус һәм татар телләрендә нәшер ителә («Красная Татария», «Кызыл Татарстан», «Татарстан» һ. б.). Казаннан тыш, газеталар кайбер кантон үзәкләрендә дә басыла: «Кама буе газетасы» (Чистай), «Кызыл юл» (Алабуга), «Социализмга юл» (Буа). Югары уку йортларының һәм төрле җәмгыятьләрнең периодик фәнни басмалары («Казан университеты гыйльми язмалары», «Татарны өйрәнү фәнни җәмгыяте хәбәрчесе», «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» һ. б.) белән бер үк вакытта Татарстанда «ТССР мәгарифе хәбәрчесе», «Казан музей хәбәрчесе», «Татарстанның авыл һәм урман хуҗалыгы», «Хезмәт һәм хуҗалык» кебек ведомство журналлары да нәшер ителә башлый. Бу елларда газета-журналларның ассортименты артып кына калмый, аларның халыкка барып җитүмөмкинлеге дә үсә. Вакытлы матбугат ТАССРдагы социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үзгәрешләрне чагылдырган үзенчәлекле рупорга әверелә, шулай ук белем тарата, фәнни һәм житештерү эшендәге төрле тармаклар тәҗрибәсен җиткерә торган иҗтимагый орган булып җитешә.

в державно-интернационалистическом духе. В 1930-е гг. татарский язык в административных и судебных учреждениях применялся уже редко. Изучение татарского языка служащими в государственных, общественных и культурно-просветительских учреждениях почти полностью прекратилось. В 1939 г. татарский алфавит был вновь преобразован, на этот раз с латиницы на русскую кириллицу. Это открыло дорогу для дальнейшей ускоренной ассимиляции татарского народа.

Особое развитие в 1920-е гг. получила периодическая печать: выходили различные журнально-газетные издания, заметно выросли тиражи газет и журналов. В этот период была заложена основа для развития республиканской печати, периодические издания выходили на двух государственных языках ТАССР – русском и татарском («Красная Татария», «Кызыл Татарстан», «Татарстан» и др.). Кроме Казани газеты печатались в ряде кантональных центров: «Прикамская газета» (Чистополь), «Красный путь» (Елабуга), «Путь к социализму» (Буинск). Одновременно с периодическими научными изданиями вузов и обществ («Учёные записки Казанского университета», «Вестник Научного общества татароведения», «Известия Общества археологии, истории и этнографии и др.) в Татарстане начали издаваться ведомственные журналы, такие как «Вестник просвещения ТССР», «Казанский музейный вестник», «Сельское и лесное хозяйство Татарстана», «Труд и хозяйство». В эти годы значительно не только увеличился ассортимент журнально-газетной периодики, но и повысилась их доступность для населения. Периодическая печать стала своеобразным рупором, отражавшим социально-экономические, общественно-политические и культурные изменения в ТАССР, а также общественным органом, распространявшим знания и опыт из различных отраслей научной и производственной практики.

was but seldom used at administrative and judicial institutions. The study of the Tatar language by public servants of the state, public, and cultural-enlightenment institutions was almost completely stopped. In 1939, the Tatar alphabet was once again transformed: this time, it switched from Roman to Cyrillic script. This opened the way for further accelerated assimilation of the Tatar people.

Especially rapidly developing in the 1920s was the periodical press: published were various magazines and newspapers, their circulation growing significantly. The basis for the development of the republic's press was laid down at that period, periodicals being published in two official languages of the TASSR: Russian and Tatar (Krasnaya Tataria, Kyzyl Tatarstan, Tatarstan, and so on). Apart from Kazan, newspapers were issued in a number of cantonal centres: Prikamskaya Gazeta (The Kama Region Newspaper) (Chistopol), Krasny Put (The Red Path) (Yelabuga), Put k Sotsializmu (The Road to Socialism) (Buinsk). Along with the periodical scientific editions published by institutions of higher education and scientific societies (Bulletin of Kazan University, Herald of Scientific Society of the Tatar Studies, News of the Society of Archaeology, History, and Ethnography, and so on), published in Tatarstan were also the departmental magazines, such as Herald of Enlightenment of TSSR, The Kazan Museum Herald, Agriculture and Forestry of Tatarstan, Labour and Husbandry. Not only the range of newspapers and magazines was increased considerably at that period, but also their accessibility for population was improved. Periodical press became a kind of a loudspeaker, which reflected the social and economic, social and political, and cultural changes in the TASSR, as well as served as a public organ that was spreading knowledge and experience accumulated by different branches of scientific and industrial practice.

## Иҗтимагый-сәяси үсештәге каршылыклар

Татарстан АССР яшәешенең беренче унъеллыгындагы катлаулы социаль-икътисади шартлар һәм күп кенә милли-мәдәни проблемаларның хәл ителмәве республикада тотрыклылыкка янаган вазгыять тудыра. Өстәвенә җитәкче милли кадрларны даими рәвештә «болгатып торган» совет системасы буталчыклар тудыра, дәүләт статусын, республиканың сәяси һәм икътисади хәлен ныгытуга, шулай ук мәдәниятне һәм төп халыкларның традицияләрен үстерүгә комачаулый. Партиячел-сыйнфый принциплардан аерылып торган милли сәясәт үткәрергә омтылучы мөстәкыйль җитәкчеләр еш кына Үзәкнең тәкъдиме белән эш урыннарыннан азат ителә, илнең башка төбәкләренә түбәнрәк вазифаларга җибәрелә. Татар сәяси һәм милли элитасының күренекле вәкилләре дә шушындый язмышка дучар ителә (М. Борындыков, М. Бөдәйли, Ю. Вәлидов, Х. Габидуллин, Г. Гобәйдуллин, Г. Янбаев, И. Казаков, Б. Мансуров, Г. Мансуров, К. Мохтаров, Р. Сабиров, Ш. Усманов һ. б.).

Татарстан җитәкчелегендәге иҗтимагый-сәяси вазгыять татар коммунистлары лидеры М. Солтангалиевнең И. В. Сталин белән каршылыкта җиңелүеннән соң кискен үзгәрә. Төзелә торган СССРда РСФСР составындагы автономияле республикаларның бертигез дәрәҗәдә катнашу хокукын яклаган М. Солтангалиев РКП(б) ҮКның милли республикалардан һәм өлкәләрдән килгән җаваплы хезмәткәрләр белән Мәскәүдә үткәрелгән (1923 елның 9 – 12 июне) 4 нче киңәшмәсе нәтиҗәләре буенча партиядән чыгарыла һәм барлык вазифаларыннан азат ителә. Аңа теләктәшлек күрсәткән Татарстан җитәкчеләре (К. Мохтаров, Г. Мансуров, Г. Янбаев һ. б.) 1924 елда шулай ук үз постларыннан алына һәм Мәскәүгә мөһим булмаган эш урыннарына күчерелә. Совет автономияләренең сәяси һәм икътисади статусын киңәйтү буенча алар алып барган көрәшне совет җитәкчелеге партия юлыннан тайпылу дип бәяли. Соңрак, репрессияләр чорында, «троцкийчы» атамасы кебек үк «солтангалиевче» сәяси ярлыгы да татар җитәкчеләрен, өлешчә СССРның башка төрки телле республикаларындагы җитәкчеләрне дә гаепләү һәм хөкем итү өчен стандарт сылтау була.

Сталин җитәкчелегенең мондый сәясәте Татарстанда милли сәяси һәм интеллектуаль элитаның зур бер катлавының югалуына, республикада милли дәүләт төзү темпларының акрынаюына һәм милләтара мөнәсәбәтләрнең кискенләшүенә китерә. Нәтиҗәдә Татарстан Республикасы 1937 елга кадәр үз конституциясен һәм геральдик символларын булдыра алмый. Бу эштә 1925 елның 25 июнендә ТАССР ҮБКның 2 нче сессиясендә кабул ителгән беренче ТАССР Конституциясе проектын, шулай ук татар милли җәмәгатьчелеге тарафыннан (Б. Урманче җитәкчелегендә) эшләнгән Татарстан АССР дәүләт гербы һәм флагы проектларын формаль сәбәпләр табып 1926 елда кире каккан БҮБК һәм Бөтенроссия Советларының корылтае да үзләренең тискәре ролен уйный.

1920 елларның икенче яртысында тоталитар тенденцияләрнең көчәюе һәм моннан соң ил җитәкчелегенең индустриальләштерүгә һәм коллективлаштыруга йөз тотуы Татарстан Республикасының автоном хокукларын алга таба чикләүгә, милли юнәлешле сәясәтнең нигездә бетерелүенә, җитәкче кадрларны, зыялыларны һәм мөселман дин әһелләрен репрессияләүләргә китерә.

## Противоречия общественно-политического развития

Сложные социально-экономические условия первого десятилетия существования Татарской АССР и нерешённость многих национально-культурных проблем создавали дестабилизирующую обстановку в республике. К тому же советская система постоянного «перетряхивания» руководящих национальных кадров порождала хаос, мешала укреплению государственного статуса, политического и экономического положения республики, а также развитию культуры и традиций коренных народов. Руководители, попытавшиеся самостоятельно провести национальную политику, отличавшуюся от партийно-классовых принципов, часто по рекомендации Центра освобождались от занимаемых постов, отправлялись в другие регионы страны на незначительные должности. Такая участь постигла видных представителей татарской политической и национальной элиты (М. Брундукова, М. Будайли, Ю. Валидова, Х. Габидуллина, Г. Губайдуллина, А. Енбаева, И. Казакова, Б. Мансурова, Г. Мансурова, К. Мухтарова, Р. Сабирова, Ш. Усманова и др.).

Общественно-политическая ситуация в татарстанском руководстве резко изменилась после поражения лидера татарских коммунистов М. Султан-Галиева в противостоянии со И. В. Сталиным. М. Султан-Галиев, отстаивавший право автономных республик РСФСР на равноправное участие в создаваемом СССР, по итогам 4-го совещания ЦК РКП(б) с ответственными работниками национальных республик и областей в Москве (9 – 12 июня 1923 г.) был исключён из партии и освобождён от всех занимаемых должностей. Поддерживавшие его руководители Татарстана (К. Мухтаров, Г. Мансуров, А. Енбаев и др.) в 1924 г. были также сняты со своих постов и переведены на работу в Москву на незначительные должности. Их борьба за расширение политического и экономического статуса советских автономий была охарактеризована советским руководством как уклон от партийной линии. Позднее, в период репрессий, политический ярлык «султангалиевец», как и «троцкист», стал стандартным поводом для обвинения и осуждения татарских руководителей, и отчасти в других тюркоязычных республиках СССР.

Такая политика сталинского руководства привела к потере огромного пласта национальной политической и интеллектуальной элиты Татарстана, замедлению темпов национально-государственного строительства и обострению межнациональных отношений в республике. В результате Татарская республика вплоть до 1937 г. не имела своей конституции и геральдических символов. Свою негативную роль в этом сыграли ВЦИК и Всероссийский съезд Советов, отклонившие в 1926 г., по формальным обстоятельствам, проект первой Конституции ТАССР, принятый 25 июня 1925 г. на 2-й сессии ЦИК ТАССР, а также проекты государственного герба и флага Татарской АССР, разработанные татарской национальной общественностью (во главе с Б. Урманче).

Усиление тоталитарных тенденций во второй половине 1920-х гг. и последовавший за ним курс руководства страны на индустриализацию и коллективизацию привели к дальнейшему ограничению автономных прав Татарской республики, к фактическому сворачиванию национально ориентированной политики, к репрессиям в отношении руководящих кадров, интеллигенции и мусульманского духовенства.



Россия коммунистлар партиясенең Татарстан өлкә комитетындагы хатын-кызлар бүлеге хезмәткәрләре. 1921

Работницы областного женского отдела Татарского обкома РКП(б). 1921

Women-workers of Regional Women's Department of the Tatar Regional Committee of RKP(b). 1921

## Controversies of Social and Political Development

The complex social and economic conditions of the first decade of existence of the Tatar ASSR and uncertainty about many national-cultural issues created a destabilising environment in the republic. Besides, the Soviet system of constant "reshuffling" of local administrative personnel caused chaos, hampered the consolidation of the state status, political and economic standing of the republic, as well as the development of culture and traditions of indigenous peoples. The leaders who tried to pursue an independent ethnic policy, which differed from Party- and class-based principles, were removed from their posts, often by recommendation of the Centre, and sent to other regions of the country to occupy insignificant positions. Such were the fates of many outstanding representatives of the Tatar political and ethnic elite (M. Brundukov, M. Budaili, Y. Validov, K. Gabidullin, G. Gubaidullin, A. Yenbayev, I. Kazakov, B. Mansurov, G. Mansurov, K. Mukhtarov, R. Sabirov, S. Usmanov, and so on).

The social and political situation in the leadership of Tatarstan changed drastically after the defeat of M. Sultan-Galiev as the leader of the Tatar communists in his opposition to Joseph Stalin. M. Sultan-Galiev, who stood for the right of the autonomous republics of the RSFSR for equal participation in the then-established USSR, was expelled from the Party and released from all his posts after the 4th meeting of the Central Committee of RCP(b) that was held in Moscow (9 – 12 June 1923) with participation of officials representing the ethnic republics and regions. The other leaders of Tatarstan, who were supporting him (K. Mukhtarov, G. Mansurov, A. Yenbayev, and so on) were also released from their positions in 1924 and were taken to Moscow to occupy insignificant posts. Their struggle for expansion of the political and economic status of the Soviet autonomies was labelled by the Soviet leadership as deviation from the Party's line. Later, in the period of repressions, the political label of "Sultan-Galiev's supporter", just like "Trotskyist", became a standard ground for accusing and condemning the Tatar leaders in Tatarstan and, to some extent, in the other Turkic-speaking republics of the USSR.

Such policy of Stalin's leadership resulted in a loss of a huge layer of ethnic political and intellectual elite of Tatarstan, slowed down the pace of national state-building and aggravated the inter-ethnic relations in the republic. As a result, the Tatar Republic did not have, up to 1937, its Constitution and heraldic symbols. A negative role in this was played by the All-Union Central Executive Committee and the All-Russian Congress of Councils, which rejected, in 1926, the draft first Constitution of the TASSR, on formal grounds, which had been adopted on 25 June 1925 at the Second Session of the Central Executive Committee of the TASSR, as well as the drafts of the coat of arms and the flag of the Tatar ASSR that were developed by the Tatar public representatives (led by B. Urmanche).


The aggravation of totalitarian tendencies in the second half of the 1920s and the subsequent course of the leadership of the country at industrialisation and collectivisation have led to further restriction of autonomous rights of the Tatar Republic, to actual rollback of the ethnic-oriented policy, and to repressions against its leaders, intelligentsia, and the Muslim clergy.

# ТАТАРСТАНДА ЯҢА ИКЪТИСАДИ СӘЯСӘТНЕҢ УҢЫШЛАРЫ ҺӘМ КАРШЫЛЫКЛЫ ЯКЛАРЫ (1921 – 1928)

# УСПЕХИ И ПРОТИВОРЕЧИЯ НОВОЙ ЭКОНОМИЧЕСКОЙ ПОЛИТИКИ В ТАТАРСТАНЕ (1921 – 1928)

# ACHIEVEMENTS AND CONTROVERSIES OF THE NEW ECONOMIC POLICY IN TATARSTAN (1921 – 1928)






## Икътисад торышы

1920 еллар башында ТАССРда сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы житештерүенең, сәүдәнең бик нык кимүе, транспорт параличы, гиперинфляция, товар кытлыгы һәм аларның кыйммәт булуы күзәтелә. Шушы ук чорда Татарстан Республикасы тагын да фаҗигалерәк бәлагә тарый – 1920 – 1923 елларда иген уңмый, һәм бу халык арасында бик зур ачлык китереп чыгара. Моның төп сәбәбе республика территориясен чолгап алган Гражданнар сугышы гына түгел, авылның талануына, халыкның ярлылануына һәм социаль деградациясенә китергән «хәрби коммунизм» сәясәте дә була. 1922 елның февралендә ТАССРда – 2 миллионнан артык кеше, 1923 елның март аенда – якынча 1 млн, 1924 елның маенда якынча 0,5 млн кеше ачлыктан интегә. Иген уңмауның

## Состояние экономики

В начале 1920-х гг. для ТАССР были характерны существенный спад промышленного и сельскохозяйственного производства, торговли, транспортный паралич, гиперинфляция, дефицит и дороговизна товаров. В этот же период Татарская республика столкнулась с ещё более ужасающим бедствием – неурожаем хлебов в 1920 – 1923 гг., приведшим к массовому голоду среди населения. Причиной этого была не столько Гражданская война, охватившая территорию республики, сколько политика «военного коммунизма», обусловившая разорение деревни, обнищание и социальную деградацию населения. В феврале 1922 г. в ТАССР голодало свыше 2 млн человек, в марте 1923 г. – около 1 млн человек, в мае 1924 г. – около 0,5 млн человек.

## State of the Economy

In the early 1920s, typical for the TASSR were a significant decline in industrial and agricultural production and in trade, the transport paralysis, hyperinflation, deficit, and skyrocketing prices for commodities. At the same period, the Tatar Republic faced even more horrifying disaster – failure of crops in 1920 – 1923, which led to the large-scale famine. The reason for it was not only the Civil War that embraced the territory of the republic, but rather the policy of the “Military Communism”, which led to impoverishment of villages, as well as impoverishment and social degradation of the population. In February 1922, suffering from famine in the TASSR were over 2 million people; in March 1923 – some 1 million; in May 1924 – nearly 0.5 million. The adverse consequences of the failure

Ачлыктан интегүче балалар

Истощённые от голода дети

Children pinched with hunger



Караучысыз калган бала

Беспризорник

Homeless boy



Балаларны саклау хакына. Ачлык-Патша кочагында. Үткен тырнакларыннан азат ителүгә таба!!... 1921 елның 18 апреленнән 1922 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Үзәк башкарма комитеты каршында эшләгән «Балалар тормышын яхшырту комиссиясе»нең балалар тормышына багышланган, саннар һәм башка күрсәткечләр кертелгән очеркы. Казан, 1922

Во имя спасения детворы. В объятиях Царя-Голода. К освобождению из цепких лап!!!... Очерк, посвящённый жизни детворы, с цифровыми и другими данными «Комиссии улучшения жизни детей» при ТатЦИКе, работавшей с 18 апреля 1921 г. по 1 февраля 1922 г. Казань, 1922

For the sake of saving children. In the arms of the Hunger the Tsar. To release from the robbing hands!!!... An essay on the life of children, with digital and other data of the "Improvement of children's lives commission" under TatCEC, working from April 18, 1921 to February 1, 1922. Kazan, 1922


По Татреспублике.
ВО ИМЯ СПАСЕНИЯ ДЕТВОРЫ.
В об'ятиях Царя-Голода.
К освобождению из цепких лап!!!...
ОЧЕРК С ИЛЛЮСТРАЦИЯМИ
КАЗАНЬ
1922

тискәре нәтиҗәсе республикада икътисади вазгыятьнең кискен начарлануы белән генә чикләнми, ачлыктан, начар тукланудан, төрле эпидемия һәм авырулардан күпләп үлү, күчеп китәргә мәҗбүр булу белән бәйле рәвештә халык санының кимүе күзәтелә. Татарстан 600 меңнән артык кешесен югалта. Ачлыктан кырылу сынавы күбрәк татар крестьяннары өстенә төшә, чөнки алар җир һәм төп җитештерү чаралары белән иң аз тәэмин ителгән, «хәрби коммунизм» чорында азык-төлек салымнарыннан җитди зыян күргән була. 1920 ел белән чагыштырганда, ТАССРда яшәүчеләр арасында татар халкының өлеше 1926 елга 4 процентка диярлек (300 – 400 мең кешегә) кими. Халыкара оешмаларның киңкүләмле азык-төлек һәм медицина ярдәме белән республика халкының төп өлешен коткарып калу мөмкин була.

Казанга ачлыктан интегүчеләр өчен җибәрелгән ашлыкны бушату

Разгрузка зерна, присланного в Казань для помощи голодающим

Unloading grain that was sent to Kazan to help the starving citizens





Негативными последствиями неурожая хлебов стали резкое ухудшение экономической ситуации в республике и значительное сокращение численности её населения вследствие массовой смертности от голода, недоедания и различных эпидемий и болезней, а также вынужденной миграции. Татарстан потерял более 600 тыс. человек. Наибольшее влияние голодомора испытало татарское крестьянство, как менее обеспеченное землёй и основными средствами производства и особо пострадавшее от военно-коммунистических продовольственных реквизиций. Доля татар в составе населения ТАССР к 1926 г. уменьшилась почти на 4 % (на 300 – 400 тыс. человек) по сравнению с 1920 г. Благодаря масштабной продовольственной и медицинской помощи международных организаций удалось спасти жизнь значительной части населения республики.

of crops was not only the drastic deterioration of the economic situation in the republic, but also the considerable reduction of the population as a result of the mass mortality caused by famine, malnutrition, and various epidemics and illnesses, as well as of the forced migration. Tatarstan lost over 600 000 people. The forced famine struck the heaviest blow on the Tatar peasants because they had lesser plots of land and not enough durable equipment at their disposal, since they suffered most from food requisitions at the time of "Military Communism". The portion of the Tatars in the population of the TASSR decreased by 1926 by almost 4 % (by 300 – 400 thousand people) compared to 1920. It was only due to the large-scale food and medical aid provided by international organisations that it became possible to save lives of a considerable part of the republic's population.




«Ачлык белән көрәшүчегә» бүләк билгесе

Знак наградной «Борцу с голодом»

A badge "To Famine Fighter"




ТАССРның «Ачлык фронты» (Ачлыктан интегүчеләргә ярдәм буенча Үзәк комиссия Президиумы, ачлыктан интегүчеләргә кантон ярдәме рәисе һәм Ачлыктан интегүчеләргә эшчеләрдән ярдәм Халыкара комитеты, Америка ярдәм администрациясе вәкилләре)

«Голодный фронт» ТАССР (Президиум Центральной комиссии Помгола, председатель Кантпомгола, представители Межрабпомгола и АРА)

"Famine Front" of the TASSR (Presidium of the Central Commission for Famine Relief, Chairman of Canton Famine Relief Council, representatives of International Workers Famine Relief and American Relief Administration)

## Сәнәгатьтә, кредит-банк системасында һәм сәүдәдә үзгәртеп кору

Совет Россиясендә эчке икътисад курсының алмашынуы, шулай ук яңа икътисади сәясәткә күчү белән бәйле рәвештә өлешчә иҗтимагый-сәяси курсның да яңаруы ТАССРда базар һәм товар-акча мөнәсәбәтләрен торгызырга ярдәм итә. Эшчеләр яллау, җитештерү чараларын арендаларга рөхсәт ителү, сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында, сәүдәдә хуҗалык исәбен һәм матди стимуллауның яңа формаларын кертү республика халкының хуҗалык тормышын җанландырып җибәрә. Акча-эмиссия сәясәтен тормышка ашыруда вәкаләтле төбәк банкы буларак СССР Дәүләт банкының Казан конторасы оештырыла. ТАССРның банклар тармагында барлыкка килгән әлеге үзгәрешләр яңа икътисади сәясәткә хас товар-акча реформаларының башлануын аңлата. 1924 елның башына Татар республикасының гомуми акча массасында яңа акча билгеләре – червонецлар (берсе 6 АКШ долларына тигез) 79,9 %ны тәшкил итә. 1922 – 1923 елларда сәүдә-сәнәгать, авыл хуҗалыгы, кооперация һәм башка коммерция банкларының филиалларын (контораларын) ачу түбәнге дәрәҗә кредит учреждениеләре челтәрен киңәйтүгә, предприятиеләр, кооперативлар һәм физик затлар белән кредит-финанс операцияләрен активлаштыруга этәргеч була. Шул ук вакытта СССР Дәүләт банкының Казан конторасы ТАССРда яңа икътисади сәясәт елларында җирле сәнәгатькә, авыл хуҗалыгына һәм сәүдәгә кредитлар бирүдә алдынгы урынны тота. Товарга булган ихтыяҗ белән тәкъдим нисбәтен җайга салу, вексель, акция һәм пай операцияләре белән эшләү өчен 1922 елда ачылган Казан товар биржасы шулай ук базар мөнәсәбәтләре үсешенә булышлык итә.



Сәүдәгәрләр биржасы бинасы

Здание Купеческой биржи

The building of the Merchant Exchange

## Преобразования в промышленности, кредитно-банковской системе и торговле

Смена внутреннего экономического курса в Советской России, отчасти и общественно-политического, связанная с переходом к новой экономической политике (нэп), способствовала восстановлению рыночных и товарно-денежных отношений в ТАССР. Разрешение на найм рабочей силы и аренду средств производства, введение хозрасчёта и новых форм материального стимулирования в промышленности, сельском хозяйстве и торговле оживили хозяйственную жизнь населения республики. Началом нэповских товарно-денежных реформаций стали изменения в банковской сфере ТАССР, связанные с образованием Казанской конторы Государственного банка СССР в качестве регионального уполномоченного банка по осуществлению денежно-эмиссионной политики. К началу 1924 г. в общей денежной массе Татарской республики новые денежные знаки – червонцы (равные 6 долларам США) составляли 79,9 %. Открытие в 1922 – 1923 гг. филиалов (контор) торгово-промышленного, сельскохозяйственного, кооперативного и других коммерческих банков способствовало расширению сети низовых кредитных учреждений и активизации кредитно-финансовых операций с предприятиями, кооперативами и частными лицами. При этом Казанская контора Госбанка СССР в ТАССР в годы нэпа занимала лидирующую позицию в кредитовании местной промышленности, сельского хозяйства и торговли. Развитию рыночных отношений способствовало также открытие в 1922 г. Казанской товарной биржи для регулирования спроса и предложения товаров, операций с векселями, акциями и паями.







1923 елгы дәүләт акча билгесе

Государственный денежный знак 1923 года

The state currency note of 1923

СССРның дәүләт билгесе билеты

Билет государственного знака СССР

The note of the State Bank of the USSR

## Transformations in Industry, Banking System, and in Commerce

The change in the economic course of the Soviet Russia, as well as, partially, in the social and political course, which was connected with the transfer towards the new economic policy (NEP), encouraged the restoration of the market and commodity/money relations in the TASSR. Permission to hire labour force and lease the means of production, introduction of cost accounting and the new forms of material stimulation in industry, agriculture, and in commerce revitalised the economic life of the republic's population. The commodity/money reforms as part of NEP began in the banking sector of the TASSR, when the Kazan Office of the State Bank of the USSR was established as a regional bank that was authorised to pursue the money emission policy. By the beginning of 1924, the new currency – chervonets (that was equal to 6 US dollars) – comprised 79.9 % of the total stock of money in the Tatar Republic. The opening in 1922 – 1923 of branches (offices) of the trade and industrial, agricultural, cooperative, and other commercial banks contributed to the expansion of a network of the grassroots credit institutions and to the intensification of the credit and financial operations with enterprises, cooperatives, and individuals. At the same time, during the years of the new economic policy, the Kazan Office of the State Bank of the USSR in the TASSR was the leader in the provision of loans to local industry, agriculture, and commerce. Development of market relations also owed much to the opening, in 1922, of the Kazan Commodity Exchange to regulate the demand and supply of commodities, as well as the operations with promissory notes, shares, and equities.



Казандагы Беренче дәүләт банкы идарәсенең утырышы

Заседание правления первого государственного банка в Казани

A meeting of the Board of the First State Bank in Kazan



Дәүләт банкы

Государственный банк

The State Bank




Индустриальләштерү һәм кооперацияләшү аша социализмга әйдәүче плакат

Плакат, призывающий к социализму через индустриализацию и кооперирование

Poster calling for Socialism through industrialisation and cooperation



1923 елда төзелгән ТАССРның 3 еллыгы исем. электр станциясе

Электростанция им. 3-й годовщины ТАССР, построенная в 1923 г.

Power plant n.a. the Third Anniversary of the TASSR that was built in 1923



М. Вахитов исем. 1 нче дәүләт сабын кайнату, шәм һәм химия заводы эшчеләре Казан шәһәрендә демонстрациядә

Рабочие государственного мыловаренного, свечного и химического завода № 1 им. М. Вахитова на демонстрации. Казань

Workers of the state soap, candle, and chemical plant No 1 n. a. M. Vakhitov at a demonstration. Kazan

Яңа икътисади сәясәткә күчү белән, ТАССРда җирле дәүләт сәнәгатен системалы рәвештә яңартып оештыру һәм структур үзгәртеп кору башлана. 1923 елга предприятиеләрне трестларга берләштерү, аларны хуҗалык исәбенә күчерү нигездә тәгәлләнә. Трестлар, синдикатлар, кантонкүләм сәнәгать берләшмәләре системасы сәнәгатьне базар белән бәйли. 1923 елның башына ТАССР Совнархозы карамагында унлап трест (якынча 74 завод һәм фабрика) саналган. Алардан тыш, 1922 елда республикада Электротрестның 11 электростанциясе эшли. ГОЭЛРО планы буенча җылылык электр станцияләре һәм гидроэлектростанцияләр төзү башлана. Яңа икътисади сәясәтнең базар механизмнары, эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең энтузиазмы бик кыска вакыт (өч-дүрт ел) эчендә сәнәгать җитештерүен торгызырга мөмкинлек бирә. Ул 1920 еллар уртасына үзенең төп күрсәткечләре буенча сугышка кадәрге (1913 ел) тулаем продукция күләменә якынлаша. 1925 / 1926 хуҗалык елында эре сәнәгатьнең тулаем продукциясе сугышка кадәрге дәрәҗәнең 90%ын тәшкил итә. 1927 елның октябрендә ул сугыш алды дәрәҗәсенә җитә. Шул ук вакытта сәнәгатьтә тулаем продукция күләме 2 тапкырдан күбрәккә арта. 1928 елда сәнәгатьтә тулаем продукциянең еллык үсеше 15 %ны тәшкил итә, эшчеләр саны 5 %ка арта, хезмәт җитештерүчәнлеге 9 % ка үсә – болар җирле индустрияне алга таба техник һәм технологик үзгәртеп кору өчен, шулай ук киләчәктә сәнәгать эшчеләре һәм хезмәткәрләре санын торгызу һәм аларның хезмәт хакларын арттыру өчен уңай шартлар тудыра. 1920 еллар ахырына сәнәгать эшчеләре һәм хезмәткәрләре, һөнәрчеләр һәм кустарьлар арасында эшсезлек бөтенләй диярлек бетерелә.

Базарга хас товар-акча мөнәсәбәтләре кертелү белән, дәүләт, кооператив һәм хосусый сәүдә бик көчле үсә башлый. 1925 елда ТАССРда 106 ярминкә һәм 190 базар эшли, аларда, җирле җитештерүчеләр белән бергә, килгән җитештерүчеләрнең продукциясе дә сатыла. Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималын сату җирле базарларның үзенчәлеге булып тора. Сәүдә операцияләрендә төп рольне продукцияне спекулятив бәяләргә алып-сату белән шөгыльләнүче арадашчылар уйный.

С переходом к нэпу в ТАССР начались системная реорганизация и структурная перестройка местной государственной промышленности. К 1923 г. в основном было завершено трестирование предприятий, перевод их на хозяйственный расчёт. Система трестов, синдикатов, кантональных промышленных объединений связала промышленность с рынком. К началу 1923 г. в ведении Совнархоза ТАССР находилось свыше 10 трестов (около 74 заводов и фабрик). Кроме них, в 1922 г. в республике действовали 11 электростанций Электротреста. По плану ГОЭЛРО началось строительство тепловых и гидроэлектростанций. Рыночные механизмы нэпа и трудовой энтузиазм рабочих и служащих позволили в сжатые сроки (за три-четыре года) восстановить промышленное производство, которое по своим основным показателям к середине 1920-х гг. приблизилось к довоенному объёму валовой продукции (1913 г.). В 1925 / 1926 хозяйственном году валовая продукция крупной промышленности составила 90% довоенного уровня. К октябрю 1927 г. она достигла довоенного уровня. При этом объём валовой продукции промышленности вырос более чем в 2 раза. В 1928 г. годовой прирост валовой продукции промышленности составил 15 %, количество рабочих увеличилось на 5 %, производительность труда возросла на 9 %, что создавало благоприятные условия для дальнейшей технической и технологической реконструкции местной индустрии, а также для восстановления численного состава промышленных рабочих и служащих и повышения их заработной платы. К концу 1920-х гг. в основном была ликвидирована безработица среди промышленных рабочих и служащих, отчасти – среди ремесленников и кустарей.

С введением рыночных товарно-денежных отношений интенсивно начала развиваться государственная, кооперативная и частная торговля. В 1925 г. в ТАССР действовало 106 ярмарок и 190 базаров, на которых реализовывалась продукция как местных, так и приезжих производителей. Особенностью местного рынка стал его сельскохозяйственно-сырьевой характер, главную роль в торговых операциях играли посредники, занимавшиеся перепродажей продукции по спекулятивным ценам.

The transfer to NEP in the TASSR started the systemic reorganisation and the structural reform of the local state-run industrial sector. By 1923, almost all enterprises were transformed into trusts, which switched to profit and loss accounting. The system of trusts, syndicates, and cantonal industrial unions tied the industrial sector to the market. By the beginning of 1923, the Council of National Economy of the TASSR had under its authority over 10 trusts (some 74 plants and factories). In addition to them, operating in the republic in 1922 were 11 power stations of Electrotrest (Electric Power Trust). Under the GOELRO Plan, there began the construction of heat- and hydro-power plants. The market mechanisms of the new economic policy and the labour enthusiasm of the workers and public servants made it possible to restore, in a very short time (in three/four years), the industrial production, which approached in its basic figures the pre-war (1913) volume of gross output by mid-1920s. In 1925/1926 business year, the gross output of the large-scale industry reached the level of 90% of the pre-war level. By October 1927, it reached the pre-war level. At the same time, the volume of the gross industrial output grew more than two-fold. In 1928, the annual growth of the gross industrial output totalled 15 %, the number of workers increased by 5 %, the labour efficiency grew by 9 %, which created favourable conditions for further technical and technological reconstruction of the local industry, as well as for the restoration of the number of industrial workers and public servants and growth of their wages. By the end of the 1920s, unemployment among industrial workers and public servants was essentially liquidated, and partially liquidated among tradesmen and artisans.

The introduction of market driven commodity/money relations gave rise to the rapid development of the state, cooperative, and private trade. In 1925, TASSR had 106 fairs and 190 bazaars, which were used to sell the products of both local and visiting producers. The peculiar feature of the local market was the fact that it was dominated by agricultural goods and raw materials, the major role if trade operations being played by mediators engaged in re-sale of commodities at speculative prices.

## Авыл икътисадын торгызу

Авылда яңа икътисади сәясәт мәҗбүри азык-төлек һәм чимал развёрсткасын юкка чыгарудан һәм азык-төлек салымы кертүдән башлана. Крестьянга җитештергән продукциясенең артыгын ирекле базарда сатарга, җирне һәм башка җитештерү чараларын арендаларга, эшчеләр ялларга рөхсәт бирелә. Болар барысы да ТАССРның күпмилләтле авылларында социаль-икътисади үсеш өчен файдалы була. 1923 елдан авыл хуҗалыгының төп тармакларын торгызуга керешәләр. 1925 елда чәчүлекләрнең мәйданы сугышка кадәрге мәйданнарның 92,5 % ына тигез була. Шул ук вакытта 1926 елда игеннәрнең тулем уңышы, 1923 ел белән чагыштырганда, 3 тапкырдан күбрәккә арта. Чәчүлек мәйданнары тоташ коллективлаштыру алдыннан сугышка кадәрге (1913 елгы) күләмнең 114 % ын тәшкил итә.



Татар хатыннары бөртекләр җыюда

Женщины-татарки в поле на уборке урожая зерна

Tatar women during grain harvesting in the field



Арча районының Тельман исем. колхозында уҗымнарны аммонийлы селитра белән ашлау

Подкормка озимых аммониевой селитрой в колхозе им. Тельмана Арского района

Feeding the winter crops with ammonium nitrate at the Collective Farm n. a. Taelmann in the Arsky District

## Восстановление сельской экономики

Нэп в деревне начался с отмены принудительной продовольственной и сырьевой развёрстки и введения продовольственного налога, были разрешены продажа на свободном рынке излишков крестьянской продукции, аренда земли и других средств производства, найм рабочей силы. Всё это благоприятно сказалось на социально-экономическом развитии многонациональной деревни ТАССР. С 1923 г. началось восстановление основных отраслей сельского хозяйства. В 1925 г. площадь посевов хлебов составила 92,5 % от довоенных площадей. При этом валовой сбор хлебов в 1926 г. увеличился более чем в 3 раза по сравнению с 1923 г. Посевные площади к началу сплошной коллективизации деревни составили 114 % к довоенному уровню (1913 г.).

## Restoration of Rural Economy

The new economic policy in village began with the abolishment of forced food and raw material appropriation system and with the introduction of agricultural tax in-kind, with the permission for peasants to sell food surpluses in the free market, to lease land and other means of production, and to hire labour force. All this had a positive impact on the social and economic development of multi-ethnic village of the TASSR. Starting from 1923, there began the restoration of the fundamental sectors of agriculture. In 1925, the area planted with grain crops accounted for 92.5 % of the pre-war level. At the same time, the gross crop in 1926 grew more than three-fold compared to 1923. By the time the total collectivisation began in villages, the areas under crops totalled 114 % of the pre-war level of 1913.

Терлекчелек, барыннан да бигрәк продукция бирә торган терлекнең баш саны, тиз арада торгызыла. 1926 елның ахырында мөгезле эре терлекнең баш саны, 1917 ел белән чагыштырганда, 97,5 % ны, дуңгызларныкы – 91,8 % ны, сарык һәм кәҗәләрнеке 76,7 % ны тәшкил итә. Атларның баш саны исә шактый сүлпән арта (бары тик 68,6%). Яңа икътисади сәясәт чорында республика икътисадының аграр секторына терлекчелекнең көчле үсеше хас була, авыл хуҗалыгы җитештергән тулай продукциядә аның чагыштырма күләме шактый арта. Шул ук вакытта терлекчелек продукциясенең авыл хуҗалыгының гомуми товар күләмендәге өлеше 60 % ка җитә.


Быстро восстанавливалось животноводство, прежде всего поголовье продуктивного скота. Поголовье крупного рогатого скота в конце 1926 г., по сравнению с 1917 г., составило 97,5%, свиней – 91,8 %, овец и коз – 76,7 %. Более медленными темпами восстанавливалось поголовье лошадей (всего 68,6 %). Для нэповского периода развития аграрного сектора экономики республики был характерен опережающий рост животноводства, удельный объем которого в валовой продукции сельскохозяйственного производства значительно увеличился. При этом доля продукции животноводства в общей товарной массе сельского хозяйства достигла 60 %.

Rapidly restoring was cattle-breeding, first of all, the number of productive livestock. The cattle stock at the end of 1926 totalled, compared to 1917, 97.5 %, the pig stock – 91.8 %, sheep and goats – 76.7%. Quite slow was the pace of restoration of the horse stock (just 68.6 %). Typical for development of the agrarian sector of the republic's economy during the period of the new economic policy was the outstripping growth of cattle-breeding, its portion in the gross agricultural output having increased significantly. The portion of animal production in the total mass of agricultural commodities reached 60 %.

ТАССРның Халык комиссарлары советы рәисе Яһүдин һәм игенчелек халык комиссары Искәндәров колхозчылар белән авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә әңгәмә кора

Председатель СНК ТАССР Ягудин и нарком земледелия Искандеров беседуют с колхозниками на сельскохозяйственной выставке

Chairman of the Council of People's Commissars of the TASSR Yagudin and People's Commissar for Farming Iskanderov talking to collective farmers at an agricultural exhibition






Чистай районының «Уңыш» колхозында печән җыю

Уборка сена в колхозе «Урожай» Чистопольского района

Hay harvesting in the field of “Urozhay” Collective Farm in the Chistopolsky District

Аграр-сыйнфый экспериментларның кыенлыгын, большевиклар һәм акгвардиячеләр тарафыннан талану, ачлык һәм эпидемияләр авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән республика крестьяннары киеренке хезмәтләре белән хуҗалыкны, шул исәптән чәчүлек мәйданнарын, продукциягә бирә торган һәм эш терлегенең баш санын, җир эшкәртү коралларын торгызуга ирешә.

Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы товарларына туры килә торган бәяләр кую нэпның барлык елларында да иң кискен мәсьәлә булып кала. Ашлык базарында бәяләр кую мәсьәләсе аеруча кискен тора. Икмәккә дәүләт куйган сатып алу бәяләре түбән була, бу крестьян хуҗалыклары үсешенә үтә тискәре йогынты ясый. Товар базарының төшенкелектә булуы, инфляция, бәя куюны өстән торып планлаштыру сәясәте ахыр чиктә 1927 – 1928, 1928 – 1929 елларда «икмәк әзерләү кризислары» дип аталган хәлләргә һәм нэпның төп принцибыннан – базар икътисадыннан баш тартуга китерә.

1920 елларда ТАССРның сәнәгать үсешендәге уңышлары аның аграр юнәлешен үзгәртә алмый, ул элеккечә үк аграр-индустриаль республика булып кала. 80% тан артык халкы авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә, автономия үз тулай продукциясенең 57 % ын нәкъ менә аграр сектордан ала.

Крестьянство республики, испытавшее на себе все крайности аграрно-классовых экспериментов, большевистских и белогвардейских реквизиций, ужасы голодомора и эпидемий, в результате напряжённого труда смогло восстановить своё хозяйство, в том числе площади посевных угодий, поголовье продуктивного и рабочего скота, земледельческий инвентарь.

За все годы нэпа самой острой оставалась проблема паритетного ценообразования на промышленные и сельскохозяйственные товары. Особенно остро стоял вопрос с ценообразованием на зерновом рынке. Государственные заготовительные цены на хлеба были низкими, что негативно сказывалось на развитии крестьянского хозяйства. Депрессивное развитие товарного рынка, инфляция, политика директивного планирования ценообразования привели, в конечном итоге, к так называемым «хлебозаготовительным кризисам» 1927 – 1928, 1928 – 1929 гг. и к отказу от основного принципа нэпа – рыночной экономики.

Успехи в развитии промышленности ТАССР в 1920-е гг. не изменили её аграрной направленности, она по-прежнему оставалась аграрно-индустриальной республикой. Свыше 80 % её населения занималось сельским хозяйством, 57 % всей валовой продукции автономия получала от аграрного сектора.

Peasants of the republic, having experienced all the extremes of agrarian-class experiments, Bolshevik and White Guards requisitions, atrocities of the forced famine and epidemics, managed to restore, with their hard labour, their households, including the areas under crops, the stock of productive and work cattle, and the farming equipment.

The issue of establishing parity prices for industrial and agricultural goods remained pressing all the years of the new economic policy. Especially topical was the issue of price formation in the grain market. The state procurement prices for grain were low, which has an adverse impact on the development of peasant households. The depressive development of the commodity market, inflation, and the policy of directive planning have led, in the end, to the so called “grain procurement crises” of 1927 – 1928 and 1928 – 1929 and to the refusal from the main principle of the new economic policy – the market economy.

The achievements in the development of industry of the TASSR in the 1920s did not change its agrarian vector. As before, it remained an agrarian-industrial republic. Over 80% of its population were engaged in agriculture, 57 % of the gross output of the republic came from the agrarian sector.

Калинин исем. колхозында (Кара Күл авылы) катлаулы ашлык сугу машинасында ашлык суктыру

Молотьба на сложной молотилке в колхозе им. Калинина в деревне Чёрное озеро

Thrashing ata separator at the Collective Farm n. a. Kalinin in the village of Chernoye Ozero




# СОЦИАЛИСТИК ҖӘМГЫЯТЬ НИГЕЗЛӘРЕН ТӨЗҮНЕ ТИЗЛӘТЕЛГӘН ТЕМПЛАРДА АЛЫП БАРУ (1929 – 1940)

## ФОРСИРОВАННОЕ СТРОИТЕЛЬСТВО ОСНОВ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО ОБЩЕСТВА (1929 – 1940)

## ACCELERATED BUILDING OF FUNDAMENTALS OF SOCIALIST SOCIETY (1929 – 1940)





8 нче кинотасма фабрикасы сәнәгать мәйданы төзелешенең гомуми күренеше

Общий вид строительства промплощадки фабрики киноплёнки № 8.

General view of construction of the industrial site of the cine-film factory No 8

### Индустриальләштерү

Яңа икътисади сәясәт чорында Татарстан икътисадының индустриаль өлешен интенсив торгызу авыр сәнәгатьнең төп тармакларын тизләтелгән рәвештә яңартырга мөмкинлек бирә. 1920 елларның икенче яртысынан республикада, бөтен илдәге кебек үк, сәнәгать предприятиеләрен, аларның да хәрби-оборона юнәлешле авыр индустриягә караганнарын, тизләтергән темпларда төзү башлана. Татар республикасында индустриальләштерү барышында (1941 елга кадәр) чоры өчен алдынгы техника һәм технологияләр белән җиһазландырылган 70 тән артык эре, 300 урта һәм вак предприятие төзелә. Казан белән бер үк вакытта, республиканың башка шәһәрләре дә максатчан рәвештә индустриальләштерүгә җәлеп ителә, нәтиҗәдә Яшел Үзән, Чистай, Бөгелмә кебек яңа шәһәр сәнәгать үзәкләре барлыкка килә.

### Индустриализация

Интенсивное восстановление индустриального сектора экономики Татарстана в период нэпа сделало возможным форсированное обновление основных отраслей тяжёлой промышленности. Со второй половины 1920-х гг. в республике, как и по всей стране, началось ускоренное строительство промышленных предприятий, преимущественно тяжёлой индустрии с военно-оборонной направленностью. В ходе индустриализации в Татарской республике (до 1941 г.) было построено свыше 70 крупных, 300 средних и мелких предприятий, оснащённых современной для того периода техникой и технологиями. Одновременно с Казанью направленной индустриализации подверглись и другие города республики, в результате появились новые городские промышленные центры, такие как Зеленодольск, Чистополь, Бугульма.

### Industrialisation

The intensive restoration of the industrial sector of the economy of Tatarstan in the period of the new economic policy made it possible to restore the basic sectors of the heavy industry. Starting from the second half of the 1920s, there began in the republic, just like in the whole country, the accelerated construction of industrial enterprises, mainly such in the heavy industry with focus on the military/defensive sector. In the course of industrialisation, over 70 large, 300 medium and small enterprises with modern, for that time, equipment and advanced technologies were built in the Tatar Republic. Along with Kazan, the other towns of the republic were also exposed to targeted industrialisation. As a result, the new urban industrial centres have appeared, such as Zelenodoslk, Chistopol, Bugulma.

Индустриальләштерү чорында авыр сәнәгатьнең яңа тармаклары булдырыла, шундыйлардан: очкычлар төзү, суднолар төзү, приборлар төзү, синтетик каучук, кинофотоплёнка, фотожелатин, ясалма күн җитештерү. Җиңел сәнәгатьнең яңа предприятиеләреннән консерв, фетр, галантерея, кетгут фабрикалары аеруча әһәмиятле була. Шул ук вакытта күп кенә мех, күн аяк киеме, тегү, туку, киез итек-киез сәнәгате, азык-төлек предприятиеләре техник яктан үзгәртеп корыла. Югары темплар белән электр энергетикасы үсә, ул сәнәгать предприятиеләрен, дәүләт һәм җәмәгать биналарын электрлаштыруны тәмамларга мөмкинлек бирә.

В период индустриализации были созданы новые отрасли тяжёлой промышленности: самолётостроение, судостроение, приборостроение, производство синтетического каучука, кинофотоплёнки, фотожелатина, искусственной кожи. Из новых предприятий лёгкой промышленности особую значимость имели консервная, фетровая, галантерейная, кетгутная фабрики. В то же время технической реконструкции подверглись многие предприятия меховой, кожевенно-обувной, швейной, текстильной, валяльно-войлочной, пищевой промышленности. Быстрыми темпами развивалась электроэнергетика, что позволило завершить электрификацию промышленных предприятий, государственных и общественных зданий.

The new branches of heavy industry were created at the period of industrialisation: aircraft-building, ship-building, instrument-making, production of synthetic rubber, motion picture and photographic film, photo-gelatine, synthetic leather. Of special importance among enterprises of the light industry were the food canning, felt, fancy goods, and catgut factories. At the same time, many enterprises of the fur, leather and footwear, clothing, textile, felt-making, and food industries underwent technical reconstruction. Rapidly developing were the power-generating industry, which made it possible to complete the electrification of industrial enterprises, state and public buildings.



Казмашстрой районы. 1933

Район Казмашстроя. 1933

Area of Kazmashstroy. 1933



Казмашстрой. М. И. Калинин төзелеш мәйданында

Казмашстрой. М. И. Калинин на строительной площадке

Kazmashstroy. M. I. Kalinin at the construction site



Кинофабрика төзелешендә. Ташчыларның алдынгы бригадасы

На постройке кинофабрики. Ударная бригада каменщиков

At the construction of a film studios. Shock working brick-laying crew





Киез-фетр фабрикасы. Цех

Валяльно-фетровая фабрика. Цех

Milling and felt-wear factory. Workshop



Казан кетгут заводы. Кетгут цехының җебетү һәм тәртипләп җыю бүлеге

Казанский кетгутный завод. Отделение размочки и разборки кетгутного цеха

The Kazan catgut plant. Wetting and sorting department of the catgut workshop



8 нче кинотасма фабрикасының перфораторчы-стахановчылары бригадасы

Бригада стахановок-перфораторщиц фабрики киноплёнки № 8

Crew of Stakhanov's female punch workers of cine-film factory No 8

Тизләтелгән индустриальләштерү юлы белән Татарстан кыска вакыт эчендә Идел буенда машина төзелеше, металл эшкәртү, химия һәм агач эшкәртү сәнәгатьләренең иң эре үзәкләреннән берсенә әйләнә. 1926 – 1940 елларда ТАССРның тулаем сәнәгать продукциясе – 20,6 тапкырга (59,1 млн сумнан 1 219 млн сумга кадәр), төп җитештерү фондлары 31,6 тапкырга (32,6 млн сумнан 1 032 млн сумга кадәр) үсә. Сәнәгать продукциясенең чагыштырма күләме 86 %ны тәшкил итә (1941 ел). 1930 елларда Татарстан сәнәгатьнең кайбер тармакларында (синтетик каучук, ясалма күн, фотожелатин җитештерү) фәнни-техник яңалыкларны куллануда СССРда алдынгы урыннарга чыга.

Индустриальләштерү нәтиҗәсендә Татарстан куәтле җитештерү-техник һәм инженер-техник потенциалы, нык үскән шәһәр социомәдәни инфраструктурасы булган индустриаль-аграр республикага әйләнә.

Татарстан за короткий срок форсированной индустриализации стал одним из крупных центров машиностроительной, металлообрабатывающей, химической и деревообрабатывающей промышленности Поволжья. В 1926 – 1940 гг. валовая промышленная продукция в ТАССР выросла в 20,6 раза (с 59,1 до 1 219 млн рублей), основные производственные фонды – в 31,6 раза (с 32,6 до 1 032 млн рублей). Удельный вес промышленной продукции составил 86 % (1941 г.). В 1930-е гг. промышленность Татарстана по ряду отраслей (производство синтетического каучука, искусственной кожи, фотожелатина) вышла на лидирующие позиции в СССР в применении научно-технических новаций в производстве.

В результате индустриализации Татарстан превратился в индустриально-аграрную республику с мощным производственно-техническим и инженерно-техническим потенциалом, развитой городской социокультурной инфраструктурой.



Мех комбинаты төзелеше. Казан, 1932

Строительство мехового комбината. Казань, 1932

Construction of the fur production combine. Kazan, 1932



Казмашстройның нигез ташларын салганда. Уңда икенче – ТАССРның Социалистик Хезмәт Герое Г. Ганиев. 1930

На закладке Казмашстроя. Второй справа – Герой Социалистического Труда ТАССР Г. Ганеев. 1930

At the Kazmashstroy ground-breaking ceremony. Second right: G. Ganeyev, Hero of the Socialist Labour of the TASSR. 1930

Over a short period of the accelerated industrialisation Tatarstan became one of the large centres of mechanical engineering, metal-working, chemical, and wood-working industries of the Volga Region. In 1926 – 1940, the gross industrial output grew in the TASSR 20.6 times (from 59.1 to 1 219 million roubles), the fixed production assets – 31.6 times (from 32.6 to 1 032 million roubles). The portion of industrial products totalled 86 % (1941). In the 1930s, the industrial sector of Tatarstan was occupying the leading positions in the USSR in a number of industries (production of synthetic rubber, synthetic leather, photo-gelatine) in what referred to the application of scientific and technological novelties in production.


As a result of industrialisation, Tatarstan turned into an industrial-agrarian republic with a powerful production and technical, and engineering and technological potential and with the developed urban social and cultural infrastructure.



«Красный путь» станоклар төзү заводы стахановчысы И. М. Анисимов станок җыю эшендә

И. М. Анисимов, стахановец станкостроительного завода «Красный путь» за сборкой станка

I. M. Anisimov, Stakhanov's follower from the "Krasny Put" machine tool factory, assembling the machine tool



КазГРЭС (КТЭЦ-1), республиканың тәүге энергетика чыганагы

КазГРЭС (КТЭЦ-1), первенец республиканской энергетики

The Kazan Hydro Power Plant (Kazan thermal power plant No 1), the first power plant of the republic's power engineering sector

## Авыл хуҗалыгын коллективлаштыру

Крестьян хуҗалыкларын тоташ коллективлаштыру башланганчы, ТАССРның авыл хуҗалыгында җир эшкәртү культурасы һәм матди-техник үсеш бик түбән дәрәҗәдә була. ТАССРда 1920 еллар ахырына бары тик 154 трактор исәпләнә. 40 % крестьян хуҗалыгы үз җирләрен сука белән эшкәртә. Керем алу җәһәтеннән республиканың аграр тармагы РСФСРның уртача күрсәткечләреннән шактый калыша. 1929 елгы мәгълүматлар буенча, ТАССРда авыл хуҗалыгының 1 гектар чәчүлек җиренә туры килгән тулай продукция 52,8 – 72,8 сумга бәяләнә, РСФСРда исә – 136,6 сум. Үсемлекчелек продукциясенең тулай

## Коллективизация в сельском хозяйстве

К началу сплошной коллективизации крестьянских хозяйств сельское хозяйство ТАССР характеризовалось низким уровнем агрикультурного и материально-технического развития. В ТАССР к концу 1920-х гг. насчитывалось всего 154 трактора. Около 40 % крестьянских хозяйств обрабатывали свои наделы сохой. По доходности аграрный сектор республики значительно отставал от средних показателей РСФСР. По данным за 1929 г., валовая продукция сельского хозяйства в ТАССР в расчете на 1 га посева составляла 52,8 – 72,8 рубля, в РСФСР – 136,6 рубля. Валовые сборы растениеводческой

## Collectivisation of Agriculture

By the time when the total collectivisation of peasant households began, the agricultural sector of the TASSR was characterised by the low level of agricultural and material and technical development. By the end of the 1920s, TASSR had only 154 tractors. Up to 40 % of peasant households used wooden plough to till their plots of land. In terms of profitability, the agrarian sector of the republic was lagging behind significantly compared to average figures for the RSFSR. According to data for 1929, the gross agricultural output in the TASSR, on a 1 hectare

Лаеш районында урнашкан Татарстандагы беренче «Заветы Ильича» авыл хуҗалыгы комсомол коммунасы әгъзалары төркеме.1926

Группа членов первой в Татарии сельскохозяйственной комсомольской коммуны «Заветы Ильича» Лаишевского района.1926

A group of members of “ZavetyIlyicha” agricultural commune in Laishevsky District, the first such commune in Tataria. 1926









Арча районының «Авангард» колхозында бәрәңге игү

Посадка картофеля в колхозе «Авангард» Арского района

Planting potatoes at “Avangard” Collective farm in the Arsky District

Арча районының Сталин исем. колхозында чәчү

Сев в колхозе им. Сталина Арского района

Sowing works at the Collective farm n. a. Stalin in the Arsky District

күләме, циклы характерда булып, табигый-климатик шартларның уңайлылыгына карап, кисәк артулар һәм кимүләр кичерә. Коллективлаштыру башланыр алдыннан Татарстан аграр эшкуарлыкның күбесенчә индивидуаль формасы белән шөгыльләнүче 520 меңнән артык аерым крестьян хуҗалыгы исәпләнгән аграр республика иде. Хуҗалык итүнең күмәк формалары милкендә авыл хуҗалыгы җирләренең бары тик 5 % ы була.

1920 еллар ахырындагы икмәк әзерләү кризислары, сәнәгать өчен авыл хуҗалыгы чималына шул кризислар белән бәйле кытлык, тиз артып баручы шәһәр халкы өчен икмәк һәм ит-сөт ризыкларын җиткерә алмау СССРда аерым хуҗалыклы крестьян игенчелегенең традицион формаларын көчләп җимерүгә сәбәп була. Сәнәгатьне техник һәм технологик яктан тиз арада яңадан җиһазландыру өчен кирәкле капиталны авылдан шәһәргә суыру сәясәтенең дә монда роле аз булмый. Татарстанда крестьян хуҗалыкларын тоташ коллективлаштыру 1929 елда башлана.

продукции имели циклический характер, испытывали резкие подъёмы и спады в зависимости от благоприятствования природно-климатических факторов. Татарстан к началу коллективизации был аграрной республикой, в которой насчитывалось свыше 520 тысяч единоличных крестьянских хозяйств, занятых преимущественно индивидуальной формой аграрного предпринимательства. Коллективные формы хозяйствования, которым принадлежало менее 5 % сельскохозяйственных угодий, не получили широкого распространения.

Хлебозаготовительные кризисы конца 1920-х гг., связанный с ними острый дефицит сельскохозяйственного сырья для промышленности, для производства хлебной и мясо-молочной продукции для быстро растущего городского населения стали причиной насильственной ломки традиционных форм единоличного крестьянского земледелия в СССР. Немалую роль в этом сыграла и политика перекачки из деревни в город капитала, необходимого для форсированного технического и технологического

basis, totalled 52.8 – 72.8 roubles, while in the RSFSR it totalled 136.6 roubles. The gross collections of crop products had a cyclical pattern, experiencing drastic ups and downs depending on the favourable natural and climatic factors. By the beginning of collectivisation, Tatarstan was an agrarian republic, which had over 520 000 individual farms engaged mainly in individual agricultural business activity. Collective forms of economic activity, which accounted for less than 5 % of the total agricultural lands, did not become a frequent practice.

The grain collecting crises of the late 1920s and the related acute deficit of agricultural raw materials for the industry, for the production of bread and dairy-and-meat products for the rapidly growing urban population became the reason for the forced change in traditional forms of individual peasant farming in the USSR. An important role in this respect was played, inter alia, by the policy of pumping

1930 елның март аена коллективлаштыру темплары буенча республика СССРда өченче урынга чыга. 1937 елның җәенә бу эш нигездә тәмамлана: Татарстанда 417,8 мең крестьян хуҗалыгы (91,4 %) кергән 3 847 күмәк хуҗалык (колхоз) оештырыла. 1940 ел башына республикада колхозга кермәгән 60 меңгә якын аерым крестьян хуҗалыгы исәпләнә.

Коллективлаштыру барышында җир һәм барлык төп җитештерү чаралары гомумиләштерелә. Күмәк хуҗалык крестьянының яшәгән өе һәм зур булмаган хуҗалык каралтылары, вак инвентаре, чикләнгән сандагы терлек-туары, шулай ук йорт янында зур булмаган яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы, ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сирәгрәк очракта кырда җир участогы (0,5 гектарга кадәр) үз милкендә кала. Татарстанның колхоз крестьяннары өчен шәхси ярдәмче хуҗалыкларыннан алынган керемнәр күп дистә еллар

перевооружения промышленности. Сплошная коллективизация крестьянских хозяйств в Татарстане началась в 1929 г. К марту 1930 г. по темпам коллективизации республика вышла на 3-е место в СССР и в основном завершилась к лету 1937 г.: в Татарстане было организовано 3 847 колхозов, в которые вошли 417,8 тыс. крестьянских хозяйств (91,4 %). К началу 1940 г. в республике насчитывалось около 60 тыс. единоличных крестьянских хозяйств.

В ходе коллективизации были обобществлены земля и все основные средства производства. В личной собственности колхозного крестьянства оставались жилые и небольшие хозяйственные постройки, мелкий инвентарь, продуктивный скот в ограниченном количестве, а также небольшой приусадебный, реже полевой, участок земли (до 0,5 га) для ведения подсобного хозяйства. Доходы, получаемые от личных подсобных хозяйств, в течение многих десятилетий для колхозного крестьянства Татарстана

capital from village to town, which was required for the accelerated technical and technological upgrading of industry. The total collectivisation of peasant households began in Tatarstan in 1929. By March of 1930, the republic rated third in the USSR in terms of the pace of collectivisation, which was finished in principle by summer of 1937: established in Tatarstan were 3 847 collective farms, which included 417 800 peasant households (91.4 %). By the beginning of 1940, the republic had some 60 000 individual peasant households.

Collectivised in the course of collectivisation were land and all fixed production assets. Remaining as personal property of the collective farmers were housing



Колхоз ындырында

На колхозном току

At the barn floor in the collective farm

Лаеш районының «Путь Ленина» колхозында утырту алдыннан бәрәңгене эретмәгә салу

Замачивание картофеля перед яровизацией в колхозе «Путь Ленина» Лаишевского района

Wetting of potato before vernalisation at “Put Lenina” Collective farm in the Laishevsky district





Ындыр каравылчысы Алабуга районы Калинин исем. колхозның орлык фонды янында

Охранник амбаров с семенными фондами колхоза им. Калинина Елабужского района

Watchman guarding the granaries with seed stocks of the Collective Farm n. a. Kalinin in the Yelabuzhsky District



Сыер савучылар бигадиры Т. Авдеева савымчы П. Кондратьевадан сөт кабул итә. Питрәч районының «Кулаевский» совхозы

Бригадир доярок Т. Авдеева принимает молоко от доярки П. Кондратьевой. Совхоз «Кулаевский» Пестречинского района

T. Avdeyeva, a foreman of dairy women accepting milk from dairymaid P. Kondratyeva. “Kulayevsky” Soviet Farm in the Pestrechinsky District



Башак җыю. Минзәлә районы, «Круч» колхозы.

Сбор колосков Мензелинский район, колхоз «Круч»

Collecting the ears. Menzelinsky District, “Kruch” Collective farm

буена яшәү формасы һәм дәүләт салымнарын, натураль җыемнарны түләү чыганагы булып тора. 1932 елгы бердәм паспорт системасы авыл хезмәт иясен чынлыкта колхозларга беркетеп куя.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: көчләп коллективлаштыру төп авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерерүне шактый киметә, 1930 – 1940 елларда Татарстандагы авыл халкының зур өлешен ачлы-туклы яшәргә мәҗбүр итә, шулай ук кыен тормыш шартлары, ачлык, авыр хезмәт, тискәре демографик һәм миграцион процесслар аркасында кешеләрнең күпләп үлүенә, югалуына китерә. Крестьян терлекчелеге җитди зыян күрә: 1932 ел ахырына атларның баш саны, 1928 ел белән чагыштырганда, 39 % ка, мөгезле эре терлекнеке – 38 % ка, сарык һәм кәҗәләрнеке – 65 % ка, дуңгызларныкы 64 % ка кими. Колхозларда бөртекле культураларның уңдырышлылыгы 1 гектардан якынча 5 – 6 центнерны тәшкил итә. Коллективлаштыру ТАССР

были основной формой существования и оплаты государственных налогов и натуральных сборов. Фактически единой паспортной системой 1932 г. трудовое крестьянство было прикреплено к колхозам.

Насильственная коллективизация привела к значительному сокращению производства основных сельскохозяйственных продуктов, полуголодному существованию большей части сельского населения Татарстана в 1930 – 1940-е гг., а также к большим людским потерям из-за тяжёлых условий жизни, недоедания, непосильного труда, негативных демографических и миграционных процессов. Серьёзный урон претерпело крестьянское животноводство: поголовье лошадей к концу 1932 г., по сравнению с 1928 г., сократилось на 39 %, крупного рогатого скота – на 38 %, овец и коз – на 65 %, свиней – на 64 %. Урожайность зерновых культур в колхозах составляла примерно 5 – 6 ц с 1 га. Коллективизация не привела к значительному росту доходности аграрного сектора ТАССР: почти 70 – 80 % колхозов в 1930-е гг. были нерентабельными и работали в убыток.

and small household buildings, small equipment, productive stock in limited quantities, and a small subsidiary homestead, or less frequently, field plot of land (up to 0.5 hectares) for part-time farming. The incomes derived from private subsidiary farming were for many decades the main source of funds for existence of collective farmers of Tatarstan and for payment of state taxes and duties payable in kind. Actually, the passport reform of 1932 fixed peasants to collective farms.

It should be noted that the forced collectivisation led to a significant reduction of production of the basic agricultural products, half-starved existence of a major portion of the rural population of Tatarstan in the 1930s and 1940s, as well as to large human losses caused by hard living conditions, malnutrition, back-breaking labour, negative demographic and migration processes. A serious blow was struck on the peasant livestock breeding: the stock of horses decreased by the end of 1932 by 39 % compared to 1928, the stock of cattle – by 38 %, sheep and goats – by 65 %, pigs – by 64 %. The yield of grain crops in collective farms was roughly 5 – 6 centners per 1 hectare. Collectivisation did not ensure any significant growth of profitability of the agrarian sector of



Ат караучы Балдин аты янәшәсендә. Югары Ослан районының «Новый Путь» авыл хуҗалыгы артеле

Конюх Балдин со своим питомцем. Сельхозартель «Новый Путь» Верхне-Услонского района

Horseman Baldin with his nursling. “Novy Put” Agricultural Artel in the Verkhne-Uslonsky District



В. Гусев, орденлы тракторчы

В. Гусев, тракторист-орденоносец

V. Gusev, tractor driver, an order bearer






Иң яхшы комбайнчыны тәбрикләү

Поздравление лучшего комбайнёра

Celebrating the best combiner

аграр тармагында керемнәрнең үсешен тәэмин итми диярлек: 1930 нчы елларда колхозларның 70 – 80 % ы рентабельле булмый һәм зыянга эшли.

Коллективлаштыру нәтиҗәсендә сәнәгать – яңа предприятиеләр төзү, булганнарын техник реконструкцияләү һәм чимал белән тәэмин итү өчен кирәкле матди мөмкинлекләр һәм авыл хуҗалыгы чималы, ә шәһәр халкы һәм армия азык-төлек ала. Шул рәвешле аның төп максатына ирешелә. Моннан тыш, индустриальләштерү һәм коллективлаштыру нәтиҗәсендә күмәк хуҗалыкларның һәм совхозларның техник тәэмин ителешендә сан һәм сыйфат ягыннан бик мөһим үзгәрешләр була: авыл хуҗалыгы эшләрендә тракторлар, тагылма комбайннар, йөк автомобильләре, ашлык суктыргыч, чапкыч, җилгәргеч, сортларга аеру һәм башка катлаулы машиналар киң кулланыла. Болар колхозчылар хезмәтен шактый җиңеләйтә.

Тизләтелгән индустриальләштерү һәм коллективлаштыру Татарстанда киңкүләмле социаль-икътисади үзгәрешләр тудыра. Алар илнең оборона куәтен ныгытып кына калмый, алга таба республиканың икътисади, фәнни һәм социомәдәни үсеше өчен ныклы нигезләр сала.

В результате коллективизации промышленность получила материальные средства и сельскохозяйственное сырьё, столь необходимые для строительства, технической реконструкции и материально-сырьевого функционирования предприятий, а городское население и армия – продовольствие. Таким образом, её основная цель была достигнута. Кроме того, благодаря индустриализации и коллективизации произошли количественные и качественные изменения в техническом оснащении колхозов и совхозов: в сельскохозяйственных работах стали широко применяться тракторы, прицепные комбайны, грузовые автомобили, молотилки, косилки, веялки, сортировки и другие сложные машины, что значительно облегчило труд колхозников.

В процессе форсированной индустриализации и коллективизации в Татарстане произошли масштабные социально-экономические преобразования, которые не только способствовали укреплению обороноспособности страны, но и заложили прочные основы для дальнейшего экономического, научного и социокультурного развития республики.

the TASSR: almost 70 – 80 % collective farms in the 1930s were unprofitable and operated at a loss.

As a result of collectivisation, the industry got the material resources and agricultural raw materials that were very important for the construction, technical reconstruction and uninterrupted functioning of enterprises, while urban population and army got the necessary food supplies. This means that its main goal was achieved. In addition to that, industrialisation and collectivisation brought with them the quantitative and qualitative changes in the technological infrastructure of collective and Soviet farms: broadly used in agricultural works were tractors, tractor-driven combine harvesters, load-carrying vehicles, thrashing, mowing, fanning, picking, and other complex machines, which made labour of collective farmers much easier.

Large-scale social and economic transformations took place in Tatarstan in the course of the forced industrialisation and collectivisation, which contributed not only to the strengthening of defence capabilities of the country, but also provided a solid ground for further economic, scientific, social, and cultural development of the republic.

## Мәгърифәт һәм агарту эшләре

Индустриальләштерү һәм коллективлаштыру чорында гамәлгә ашырылган социаль-мәдәни революция Татарстанның халык мәгарифе системасын тамырдан үзгәртеп коруга китерә. Халыкның мәдәни һәм аң-белем дәрәҗәсен күтәрүгә республикада 1930 / 31 уку елында – гомуми башлангыч белем, 1936 / 37 уку елында мәҗбүри җидееллык белем кертү ярдәм итә. Тизләтелгән тәртиптә югары һәм урта һөнәри-техник белем бирү челтәре төзелә. 1930 еллар башында Татарстанда 5 яңа институт (авиация, химия технологиясе, финанс-икътисад, коммуналь төзелеш инженерлары, медицина), техник юнәлештәге 17 һәм авыл хуҗалыгы юнәлешле 6 урта махсус уку йорты, шулай ук фабрика-завод өйрәнчекләренең күпсанлы курслары оештырыла. 1930 еллар уртасына республикада татар телендә гомуми һәм педагогик белем бирүнең бердәм системасы барлыкка килә.

## Культурное строительство

Социально-культурная революция, реализованная в период индустриализации и коллективизации, привела к коренной перестройке системы народного образования Татарстана. Подъёму культурно-образовательного уровня населения способствовали введение в республике в 1930 / 31 учебном году всеобщего начального образования, в 1936 / 37 – обязательного семилетнего образования. В ускоренном порядке создавалась сеть высшего и среднего профессионально-технического образования. В начале 1930-х гг. в Татарстане были образованы 5 новых институтов (авиационный, химико-технологический, финансово-экономический, инженеров коммунального строительства, медицинский), 17 средних специальных учебных заведений технического и 6 сельскохозяйственного направления, а также многочисленные курсы фабрично-заводского обучения. К середине 1930-х гг. в республике сложилась целостная система общего и педагогического образования на татарском языке.

## Cultural Building

The social and cultural revolution that took place in the period of industrialisation and collectivisation led to the drastic change in the system of public education of Tatarstan. The growth of the cultural and educational level of the population owes much to the introduction in the republic of the universal primary education in the school year 1930/31 and of the compulsory seven-year education in the school year 1936/37. Created at an accelerated pace was the network of higher and secondary vocational technical education. In the early 1930s, 5 new institutes of higher education were established in Tatarstan (aviation, of chemical technology, of finance and economics, for training of engineers for communal construction, and the medical ones), as well as 17 secondary educational institutions with focus on technical and 6 on agricultural subjects, as well as numerous courses of education at plants and factories. By mid-1930s, the republic has developed an integrated system of general and pedagogical education in the Tatar language.



Мәктәп укучылары яшь натуралистлар түгәрәгендә. Әгерҗе районының Иж-Буби авылы

Учащиеся школы на кружке юннатов. Деревня Иж-Бобья Агрызского района

School children in the circle of young naturalists. Village of Izh-Bobya of the Agryzsky District





Татар педагогия техникумы

Татарский педагогический техникум

The Tatar Pedagogical Training College



Медицина техникумы

Медтехникум

Medical Training College

8 нче һөнәр училищесы – хәреф бастыручылар текст җыюда

Ремесленное училище № 8 – печатники за набором


Vocational school No 8: print workers typesetting



3 нче һөнәр училищесында слесарьлык эшенә өйрәнү дәресе

Урок производственного обучения слесарному делу в ремесленном училище № 3

A practical lesson in metalworking at the vocational school No 3


ПОЛОЖЕНИЕ
о Татарском научно-исследовательском экономическом институте
в гор. Казани.



Казан авыл хуҗалыгы институты

Казанский сельскохозяйственный институт

The Kazan Agricultural Institute

Казан шәһәрендә ачылган Татар фәнни-тикшеренү икътисад институты турындагы Нигезләмә. 1930 елның 18 марты

Положение о Татарском научно-исследовательском экономическом институте в г. Казани. 18 марта 1930

Regulations on the Tatar research economic Institute in Kazan. March 18, 1930

Дәүләт мәгариф системасы формалашу белән бер үк вакытта яңа фәнни оешмалар да ачыла: Татар фәнни-тикшеренү икътисад институты (1930), Татарстан АССР Совнаркомы каршында Татар тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты (1939 ел) һ. б. Фәнни хезмәткәрләр саны 2 тапкырга (1926 елдагы 650 кешедән 1940 елда 1300 кешегә кадәр) арта. Әмма фәнни тикшеренүләрнең, бигрәк тә гуманитар фәннәр өлкәсендә, тулы канлы үсешенә партия-идеология чикләүләре комачаулый. 1930 елларда туган якны һәм татарны өйрәнүгә караган тикшеренүләр ябыла; Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Татар мәдәнияте йорты, Татарстанны өйрәнү җәмгыяте һ. б. яшәүдән туктый; 50 дән артык галим сәяси репрессияләргә дучар була.

Одновременно с формированием государственной системы образования были открыты новые научные учреждения: Татарский научно-исследовательский экономический институт (1930 г.), Татарский научно-исследовательский институт языка, литературы и истории при Совнаркоме Татарской АССР (1939 г.) и др. Численность научных работников увеличилась в 2 раза (с 650 в 1926 г. до 1300 человек в 1940 г.). Однако полноценному развитию научных исследований, особенно в области гуманитарных наук, мешали партийно-идеологические ограничения. В 1930-е гг. были свёрнуты краеведческие и татароведческие исследования, прекратили своё существование Общество археологии, истории и этнографии, Дом татарской культуры, Общество изучения Татарстана и др.; более 50 учёных подверглись политическим репрессиям.

Simultaneously with the formation of the state system of education, the new scientific institutions were opened: the Tatar Research and Development Institute for Economics (1930), the Tatar Research and Development Institute for Language, Literature, and History under Council of Peoples' Commissars of the Tatar ASSR (1939), and so on. The number of scientific workers increased 2-fold (from 650 in 1926 up to 1 300 in 1940). However, the adequate development of scientific research, especially in the field of humanities, was hampered by Party/ideological restrictions. In the 1930s, scaled down were research works related to regional history and the Tatar studies. Closed were the Society for Archaeology, History, and Ethnography, the House of the Tatar Culture, the Society for the Study of Tatarstan, and so on; over 50 scientists were politically repressed.









Казан финанс-икътисад институты

Казанский финансово-экономический институт

The Kazan Institute for Finance and Economics

Ветеринария фәнни-тикшеренү институты

Научно-исследовательский Ветеринарный институт

Research and Development Veterinary Institute

В. И. Ленин исем. Табибларның белемнәрен камилләштерү институты

Институт усовершенствования врачей им. В. И. Ленина

Institute for Advanced Medical Education n. a. V. I. Lenin

Казан химия-технология институтының төп бинасы

Главное здание Казанского химико-технологического института

The main building of the Kazan Institute for Chemical Technology



Ф. Бурнаш, язучы, драматург

Ф. Бурнаш, писатель, драматург

F. Burnash, writer, playwright



Ф. Әмирхан, язучы, әдәби тәнкыйтьче

Ф. Амирхан, писатель, литературный критик

F. Amirkhan, writer, literary critic



М. Галәү, язучы, журналист, тәрҗемәче

М. Галяу, писатель, журналист, переводчик

M. Galyau, writer, journalist, translator

1920 – 1930 еллар Татарстанның күпмилләтле әдәбияты тарихында «яңа социалистик» әдәбият тудыру чоры була. Шигъриятта якты киләчәккә өметләрнең раслануы өстенлек итә (Һ. Такташ, Х. Туфан һ. б.). Роман һәм повесть жанрларының активлыгы тарихи вакыйгаларның кеше аңына һәм язмышына йогынтысын чагылдыруга юнәлтелә (Г. Ибраһимов, М. Галәү, Г. Кутуй һ. б.). Өлкән буын вәкилләре (Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һ. б.) үз иҗатларында шул заман хәлләренә үткәннең югалмый торган кыйммәтләрен һәм милли күзаллауның нигезен җимерү буларак бәя бирә.

Уңнан сулга: Һ. Такташ, И. Усманов, А. Айдар, Ш. Усманов, Д. Фәтхи, Г. Минский

Справа налево: Х. Такташ, И. Усманов, А. Айдар, Ш. Усманов, Д. Фатхи, Г. Минский

From right to left: K. Taktash, I. Usmanov, A. Aidar, S. Usmanov, D. Fatkhi, G. Minsky





Матбугат йорты

Дом печати

The House of Press



Г. Кутуй, язучы

А. Кутуй, писатель

A. Kutuy, writer

1920 – 1930-е гг. в истории многонациональной литературы Татарстана стали периодом создания «новой социалистической» литературы. В поэзии преобладало утверждение надежды на светлое будущее (Х. Такташ, Х. Туфан и др.). Активизация жанров романа и повести была нацелена на отражение влияния исторических событий на сознание и судьбы людей (Г. Ибрагимов, М. Галяу, А. Кутуй и др.). Представители старшего поколения (Г. Исхаки, Ф. Амирхан и др.) в своём творчестве оценивали ситуацию как разрушение непреходящих ценностей прошлого и основ национального мировоззрения.

The 1920s and 1930s in the history of the multinational literature of Tatarstan became the period of creation of the "new, Socialist" literature. Poetry was dominated by statement of hope for the bright future (K. Taktash, K. Tufan, and so on). The rise of the genres of a novel and short novel was aimed at the reflection of the influence of historical events on the consciousness and fates of people (G. Ibragimov, M. Galyau, A. Kutuy, and so on). Representatives of the older generation (G. Ishaki, F. Amirkhan, and so on), in their work, were considering the situation as the destruction of the eternal values and fundamentals of the national world view.



Н. Җиһанов, композитор, музыка-җәмәгать эшлеклесе, педагог, СССРның халык артисты, профессор

Н. Жиганов, композитор, музыкально-общественный деятель, педагог, народный артист СССР, профессор

N. Zhiganov, composer, musical and public figure, pedagogue, People's Artist of the USSR, professor

Татарстанда музыкаль-иҗтимагый тормышның активлашуына кинематографиянең һәм радиотапшыруларның бик көчле үсеше (1930 елларның ахырында 337 кино күрсәтү җайланмасы, 59,3 мең радионокта исәпләнә), Җыр һәм бию ансамбле оештырылу (1937 ел), Татар филармониясе (1937 ел), Татар опера һәм балет театры (1938 ел), Халык иҗаты йорты (1939 ел) ачылу сәбәп була. Татар профессиональ музыкасы барлыкка килү беренче татар профессиональ композиторы, музыкасы гомуммилли әһәмияткә ия булган С.Сәйдәшев иҗаты белән бәйле. Аның К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Наёмщик», «Ил» һ. б. пьесаларына язган музыкасы татар профессиональ музыка сәнгатен үстерүдә зур роль уйный. Татар музыка һәм сәхнә сәнгатенең казанышлары арасында – С. Габәши, Г. Әлмөхәммәтов һәм В. Виноградовларның «Сания» һәм «Эшче» беренче милли опералары, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсы, Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе.




Татар дәүләт филармониясенең Дәүләт симфоник оркестры чыгышы. 1937

Выступление Государственного симфонического оркестра Татарской государственной филармонии. 1937

Performance by the State Symphony Orchestra of the Tatar State Philharmonic Society. 1937

Активизации музыкальной общественной жизни в Татарстане способствовало бурное развитие кинематографии и радиовещания (в конце 1930-х гг. насчитывалось 337 киноустановок, 59,3 тыс. радиоточек), создание Ансамбля песни и танца (1937 г.), открытие Татарской филармонии (1937 г.), Татарского театра оперы и балета (1938 г.), Дома народного творчества (1939 г.). Становление татарской профессиональной музыки связано с творчеством С. Сайдашева – первого татарского профессионального композитора, музыка которого приобрела общенациональное значение. Большую роль в развитии татарской профессионального музыкального искусства сыграла его музыка к пьесам К. Тинчурина «Голубая шаль», «Наёмщик», «Родина» и др. Среди достижений татарского музыкально-сценического творчества – первые национальные оперы «Сания» и «Эшче» С. Габаши, Г. Альмухамедова и В. Виноградова, балет «Шурале» Ф. Яруллина, опера «Алтынчеч» Н. Жиганова, музыкальная комедия «Башмачки» Дж. Файзи.


The rise of the musical public life of Tatarstan was supported by the rapid growth of cinematography and radio-broadcasting (at the end of the 1930s, the republic had 337 cinema projectors, 59 300 wired radio outlets), as well as by the creation of the Ensemble of Singing and Dancing (1937), the opening of the Tatar Philharmonic Society (1937), the Tatar Theatre of Opera and Ballet (1938), the House of Folk Art (1939). The formation of the Tatar professional music was connected with the art of S. Saidashev – the first Tatar professional composer, whose music gained recognition of the entire Tatar nation. A great role in the development of the Tatar professional art of music was played by his music for the plays written by K. Tinchurin: "Blue Shawl", "Mercenary", "Motherland", and so on. The achievements of the Tatar musical and stage art include the first national operas: "Saniya" and "Eshche" by S. Gabashi, G. Almukhamedov and V. Vinogradov; ballet "Shurale" by F. Yarullin; opera "Altynchech" by N. Zhiganov, and a musical comedy "Shoes" by J. Faizi.



Җ. Фәйзи, композитор, татар радиокомитетының музыка җитәкчесе

Дж. Файзи, композитор, музыкальный руководитель Татрадиокомитета

J. Faizi, composer, musical leader of the Tatar Radio Committee



С. Сәйдәшев, композитор, дирижёр, пианист

С. Сайдашев, композитор, дирижёр, пианист


S. Saidashev, composer, conductor, pianist



Ф. Яруллин, композитор

Ф. Яруллин, композитор

F. Yarullin, composer



В. И. Виноградов, Казан музыка училищесы укытучысы

В. И. Виноградов, преподаватель Казанского музыкального училища

V. I. Vinogradov, teacher of the Kazan Music School

ТАССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле

Государственный ансамбль песни и танца ТАССР

State Ensemble of Singing and Dancing of the TASSR





Татар академия театры бинасы

Здание Татарского академического театра

The building of the Tatar Academic Theatre

Республика шәһәрләрендә авыл тамашачылары өчен – күчмә театрлар челтәре, Пионерларның үзәк клубы каршында Яшь тамашачы театры һәм рус, татар группалары булган курчак театры оештырыла. 1939 елда Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татар бүлеге төзелә, 1940 елда Актёрлар йорты ачыла. Татар академия театры һәм Казан Рус зур драма театры элеккечә Татарстанның әйдәп баручы театрлары булып кала, аларның репертуарында драматургларның һәм язучыларның көндәлек совет тормышын тасвирлаган әсәрләре торган саен күбрәк урын ала.

В городах республики была создана сеть передвижных театров для сельских зрителей, при Центральном клубе пионеров – театр юного зрителя и театр кукол с русскими и татарскими группами. В 1939 г. создано Татарское отделение Всероссийского театрального общества, в 1940 г. открыт Дом актёра. Ведущими театрами Татарстана по-прежнему оставались Татарский академический театр и Казанский русский большой драматический театр, в репертуаре которых большое место стали занимать произведения драматургов и писателей, иллюстрировавших советскую повседневность.

Created in the towns of the republic was a network of travelling theatres for rural citizens, as well as the Youth Theatre and the Puppet Theatre with Russian and Tatar companies, which were opened under the Central Club of Pioneers. In 1939, the Tatar Branch of the All-Russian Theatre Society was established. In 1940, the House of Actor was opened. The leading theatres of Tatarstan still were the Tatar Academic Theatre and the Kazan Russian Bolshoi Drama Theatre, the repertoire of which included a large number of plays created by playwrights and writers who were illustrating the Soviet everyday life.



Беренче милли «Сания» (С. Габәши, Г. Әлмөхәммәтов, В. И. Виноградов) операсыннан күренеш

Сцена из первой национальной оперы «Сания» (С. Габаши, Г. Альмухамедов, В. И. Виноградов)

A scene from “Saniya”, the first national opera (S. Gabashi, G. Almukhamedov, V. I. Vinogradov)





«Галиябану» (М. Фәйзи) спектакленнән күренеш. 1937

Сцена из спектакля «Галиябану» (М. Файзи). 1937

A scene from “Galiyabanu” performance (M. Faizi). 1937



К. Тинчурин Әстерхан артистлары белән

К. Тинчурин с артистками Астрахани

K. Tinchurin with the female artists from Astrakhan



«Шәмсекамәр» (М. Әблиев) спектакленнән күренеш. 1938

Сцена из спектакля «Шамсекамар» (М. Аблиев). 1938

A scene from “Shamsekamar” performance (M. Abliev). 1938




ТАССР Югары Советына сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе. 1930 еллар

Центральная избирательная комиссия по выборам в Верховный Совет ТАССР. 1930-е

Central election commission for elections to the Supreme Council of the TASSR. 1930s

## Сталинның команда-административ системасы формалашу шартларында хакимият һәм җәмгыять

1920 – 1930 елларда Татарстан икътисадта, фән, мәгариф һәм мәдәнияттә шактый уңышларга ирешә. Республиканы җитештерү-техника, фән, белем бирү-педагогика һәм мәдәни-агарту учреждениеләре челтәре каплап ала. Дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар аппаратларын җирле кадрлар белән ныгыту һәм татар телен республикада киң колач белән гамәлгә кертү Татарстанның үзәк һәм район хакимият органнарындагы идарә структураларында татар җитәкче хезмәткәрләренең шактый зур катламын булдырырга мөмкинлек бирә.

## Власть и общество в условиях формирования сталинской командно-административной системы

В 1920 – 1930-е гг. Татарстан достиг значительных успехов в экономике, науке, образовании и культуре. В республике функционировала развитая сеть производственно-технических, научных, образовательно-педагогических и культурно-просветительских учреждений. Интенсивная коренизация аппаратов государственных и общественных учреждений и масштабная реализация татарского языка в республике способствовали формированию в управленческих структурах центральных и районных органов власти Татарстана значительной прослойки татарских руководящих работников.

## Power and Society under Conditions of Formation of Stalin's Command and Administration System

In the 1920s and 1930s, Tatarstan achieved great success in the economy, science, education, and culture. The republic created a well-developed network of production and technical, scientific, educational and pedagogical, and cultural and enlightenment institutions. The intensive involvement of local ethnic personnel in the work of offices of state and public institutions and the large-scale implementation of the Tatar language in the republic contributed to the formation of a considerable layer of the Tatar administrative personnel in the administrative structures of the central and district bodies of power in Tatarstan.





«Кызыл юл» станоклар төзү заводының инженер-техник хезмәткәрләре һәм эшчеләре Сталинның яңа Конституция турындагы докладын тыңлыйлар

Рабочие и служащие станкостроительного завода «Красный путь» слушают доклад Сталина о новой конституции

Workers and employees of engineering and technology at the Red Way machine tool plant listen to Stalin's report on the new constitution

Әлеге уңышлар Татарстан җитәкчелегенә Татар республикасының сәяси һәм икътисади статусын күтәрү турындагы мәсьәләгә яңадан кайтырга мөмкинлек бирә. 1930 елларның икенче яртысында СССРның яңа Конституциясе проекты хакында фикер алышу барышында ТАССРның дәүләт статусы мәсьәләсе кабат күтәрелә, аңа союздаш республика статусын бирү мөмкинлеге турында ВКП(б) Үзәк Комитеты карары проекты эшләнгән була. Әмма ул проект И. В. Сталин тарафыннан кире кагыла, юлбашчы 1936 елның 25 ноябрендә СССР Советларының 8 нче корылтаенда: «Башкорт яки Татар республикаларын союздаш республикалар дәрәҗәсенә күчерергә ярамый, чөнки алар бөтен яктан совет республикалары һәм өлкәләре белән чорнап алынган, һәм алар СССР составыннан беркая да чыга алмый», – дип белдерә. 1937 елда ТАССРның беренче Конституциясе кабул

Эти успехи позволили татарскому руководству вернуться к вопросу о повышении политического и экономического статуса Татарской республики. Во второй половине 1930-х гг. в ходе обсуждения проекта новой Конституции СССР вновь встал вопрос о государственном статусе ТАССР, был разработан проект решения ЦК ВКП (б) о возможности предоставления ей статуса союзной республики. Но проект был отвергнут И. В. Сталиным, который на 8-м съезде Советов СССР 25 ноября 1936 г. заявил, что «Башкирскую или Татарскую республики нельзя переводить в разряд союзных, так как они со всех сторон окружены советскими республиками и областями и им некуда выходить из состава СССР». В 1937 г. была принята первая Конституция ТАССР, утверждены первый герб и флаг республики, избран первый состав Верховного Совета ТАССР и его президиума во главе

These achievements enabled the Tatar leadership to come back to the issue of upgrading the political and economic status of the Tatar Republic. In the second half of the 1930s, during the discussion of the draft new Constitution of the USSR, there was once again raised the question on the state status of the TASSR, and a draft decision of the Central Committee of VCP(b) on the possibility of providing the republic with the status of the union republic was developed. But the draft document was rejected by Joseph Stalin, who stated at the Eighth Congress of Councils of the USSR on 25 November 1936, that "the Bashkir or the Tatar Republics could not be transferred into the category of the Union Republics because they were surrounded by the Soviet republics or regions and could not leave the USSR". In 1937, the first Constitution of the TASSR was adopted, just like the first coat of arms and the flag of the republic. Besides, the first composition of the Supreme

ителә, республиканың беренче гербы һәм флагы раслана, ТАССР Югары Советының беренче составы, аның Ә. М. Дәүләтьяров җитәкчелегендәге Президиумы сайлана, соңгысының вәкаләтләренә республика халыкларының иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышының мөһим мәсьәләләрен хәл итү керә.

Әмма сталинчыл җитәкчелекнең хакимиятне үзәкләштерүгә һәм либераль-демократик ирекләрне чикләүгә корылган максатчан сәясәте нәтиҗәсендә совет җәмгыятенә СССРның 1936 елгы, ТАССРның 1937 елгы Конституцияләрендә игълан ителгән гражданлык хокуклары буш формальлеккә әйләнә. 1937 – 1938 елларда Татарстандагы сәяси репрессияләр үзенең югары ноктасына җитә, «зур террор» дип аталган вакыйгалар республика халыклары тормышында иң фаҗигале һәм драматик чорларның берсе була. Милли-буржуаз, солтангалиевче, троцкийчы, бухаринчы һәм башка оешмаларда әгъза булып торулары турындагы ялa ягулар нигезендә, шулай ук «корткычлык», «дәүләткә хыянәт итү» дигән ялган гаепләүләр белән татар халкының һәм башка халыкларның сәяси, хәрби, фәнни, иҗади элитасының күренекле вәкилләре меңәрләп юк ителә яки ГУЛАГ системасына ябылуга хөкем ителә.

1920 – 1930 елларда Татар республикасында «хәрби коммунизм» сәясәте актив алып барыла, ул бөтен җирдә диннәрне тамырдан корытуга һәм атеизмны көчләп тагуга юнәлдерелгән була. 1929 – 1939 елларда диннәргә каршы массакүләм дулкын уза, аның барышында 1 200 мәчеттән (1920 ел) 1940 елга эшли торган 5 мәчет, 650 православие храмыннан 2 чиркәү кала. Иске христиан диненең 50 җәмгыяте, синагога, католик һәм лютеран чиркәүләре дә шушындый ук язмышка дучар була. Бер үк вакытта дини уку йортлары да мәҗбүри ябыла: 600 мөселман-татар мәктәбенең (1926 елда 30 мең укучы) берсе дә калмый. Төрле конфессияләргә караган меңнәрчә рухани бу елларда сәяси репрессия корбанына әйләнә.

с А. М. Давлетьяровым, к полномочиям которого были отнесены важнейшие вопросы общественно-политической, социально-экономической и культурной жизни народов республики.

Однако в результате целенаправленной политики сталинского руководства по централизации власти и ограничению либерально-демократических свобод гражданские права, декларированные советскому обществу Конституциями СССР 1936 г. и ТАССР 1937 г., превратились в пустую формальность. В 1937 – 1938 гг. политические репрессии в Татарстане достигли высшей точки, так называемый «большой террор» стал одним из самых трагичных и драматических периодов в жизни народов республики. По сфабрикованным политическим делам о принадлежности к буржуазно-националистическим, султангалиевским, троцкистским, бухаринским и другим организациям, а также по ложным обвинениям во «вредительстве», «государственной измене» были уничтожены или заключены в систему ГУЛАГа тысячи видных представителей политической, военной, научной, творческой элиты татарского и других народов Татарстана.

В 1920 – 1930-е гг. в Татарской республике активно проводилась политика «воинствующего коммунизма», которая была направлена на повсеместное искоренение религий и насаждение атеизма. В 1929 – 1939 гг. прокатилась массовая антирелигиозная волна, в ходе которой из 1 200 мечетей (1920 г.) к 1940 г. осталось 5 действующих, из 650 православных храмов – 2 церкви. Такая участь постигла и 50 старообрядческих общин, синагогу, католическую и лютеранскую церкви. Одновременно принудительно закрывались религиозные учебные заведения: из 600 мектебов (с 30 тысячами учащихся в 1926 г.) не осталось ни одного. В эти годы жертвами политических репрессий стали тысячи священнослужителей различных конфессий.

Council of the TASSR and its first Presidium were elected. The Presidium was headed by A. M. Davletyarov. His authorities included the most important issues of social and political, social and economic, and cultural life of the republic.

However, as a result of the targeted policy of the Stalin's leadership that was aimed at centralisation of power and at restricting the liberal democratic freedoms, the civil rights, which were declared to be granted to the Soviet society by Constitutions of the USSR of 1936 and of the TASSR of 1937, turned into a mere formality. In 1937 – 1938, the political repressions reached its peak in Tatarstan. The so-called "big terror" became one of the most tragic and dramatic periods in life of the peoples inhabiting the republic. The fabricated political cases on belonging to bourgeois-nationalistic, Sultan-Galiev's, Trotsky's, Bukharin's, and other organisations, as well as the cases that were based on false accusations of "sabotage", "treason against the State" were used to kill or place into the system of GULAG thousands of notable representatives of the political, military, scientific, and creative elite of the Tatar and other peoples of Tatarstan.

In the 1920s and 1930s, the Tatar Republic was actively pursuing the policy of the "Militant Communism", which was aimed at the total eradication of religions and the propagation of atheism. In 1929 – 1939, the large-scale anti-religious campaign took place in the republic, as a result of which only 5 functioning mosques remained out of 1 200 (1920) by the year 1940, and only 2 functioning churches remained out of 650 Orthodox temples. The same fate befell 50 Old Believers communities, a synagogue, the catholic and the Lutheran churches. Besides, forcedly closed were religious educational institutions: all of 600 maktabs (with 30 000 students in 1926) were closed. Thousands of clergy men of different religions became victims of political repressions of those years.



Клуб, элеккеге мәчет

Клуб, бывшая мечеть

The Club, formerly a mosque



Починки авылының урам чатында торган кәшәнәне сүтү

Ликвидация часовни в деревне Починки

Liquidation of a bell-tower in the village of Pochinki

# КЫРЫС СЫНАУ ЕЛЛАРЫНДА (1941 – 1945)

## В ГОДЫ СУРОВЫХ ИСПЫТАНИЙ (1941 – 1945)

## IN THE YEARS OF SEVERE TRIALS (1941 – 1945)










А. Н. Туполев, Социалистик Хезмәт Герое, очкычлар төзү буенча баш конструктор

А. Н. Туполев, Герой Социалистического Труда, главный конструктор по самолётостроению

A. N. Tupolev, Hero of the Socialist Labour, chief aircraft designer



И. И. Русецкий, невролог-вегетолог, медицина фәннәре докторы, профессор

И. И. Русецкий, невролог-вегетолог, доктор медицинских наук, профессор

I. I. Rusetsky, neurologist-vegetologist, Doctor of Medical Sciences, professor



И. В. Курчатов, физик, физика-математика фәннәре докторы, профессор

И. В. Курчатов, физик, доктор физико-математических наук, профессор

I. V. Kurchatov, physicist, Doctor of Physical and Mathematical Sciences, professor

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк республика Кызыл Армиянең мөһим тыл базасына әйләнә. Татарстанга, эшләүче персоналы һәм аларның гаилә әгъзалары (барлыгы 226 мең кеше, шул исәптән 15 мең ятим бала) белән бергә, 70тән артык фабрика һәм завод, СССР Фәннәр академиясенең 33 институты, СССРның Финанслар наркоматы, Дәүләт банкы һәм башка ведомстволар эвакуацияләнә. Республикада 80нән артык эвакогоспиталь оештырыла, яраланган 334 мең сугышчы аларда дәвалану курсы уза, шуларның 207 меңе хәрби сафка кабат кайта.

Сугышның беренче айларыннан ук Татарстанның күп сәнәгать предприятиеләре хәрби заказлар үтәүгә күчә: В. В. Куйбышев исемендәге 8 нче номерлы Казан киноплёнка фабрикасы югары биеклектән фотога төшерү өчен яңа төр авиацион плёнка эшләп чыгаруны үзләштерә; ясалма күн, бастыру машинкалары, автогараж җиһазлары ясау заводлары миналар, снарядлар, яктырткыч бомбалар ясауга керешә; мех, киез итек-киез һәм трикотаж предприятиеләре хәрби кием

## Переход народного хозяйства на режим военного времени

С первых дней Великой Отечественной войны республика стала важнейшей тыловой базой Красной Армии. В Татарстан было эвакуировано свыше 70 фабрик и заводов, 33 института Академии наук СССР, Наркомат финансов СССР, Госбанк и ряд других ведомств с персоналом и членами их семей (свыше 226 тыс. человек, в том числе 15 тыс. детей-сирот). В республике было развёрнуто свыше 80 эвакогоспиталей, в которых прошли курс лечения 334 тыс. раненых воинов, из них 207 тыс. возвратились в строй.

С первых месяцев войны многие промышленные предприятия Татарстана переключились на выполнение военных заказов: Казанская фабрика кинoплёнки № 8 им. В. В. Куйбышева освоила выпуск новых видов авиационной

## Transfer of National Economy to Wartime Mode

From the first days of the Great Patriotic War the republic became a most important rear base of the Red Army. Evacuated to Tatarstan were over 70 factories and plants, 33 R&D institutes of the Academy of Sciences of the USSR, the People's Commissariat for Finance of the USSR, the State Bank, and a number of other departments with personnel and members of their families (more than 226 000 people, including 15 000 orphaned children). Deployed in the republic were over 80 evacuation hospitals, in which 334 000 wounded warriors underwent a course of treatment. Of this number, 207 000 returned to the ranks.

From the first months of the war many industrial enterprises of Tatarstan switched to fulfilment of military orders: the Kazan Cinefilm Factory No. 8 named after V. V. Kuibyshev mastered the production of the new kinds of film for high altitude photography; the plants for production of synthetic leather, typewriters, auto

чыгаруга көйләнә. Фронтлардагы сугышчылар Татарстанның кыска туннарын, колакчынлы бүрекләрен, унтыларын, итекләрен югары бәяли. 1941 елның июленнән Татарстанга илнең көнбатыш һәм үзәк төбәкләреннән эвакуацияләнгән заводлар һәм фабрикалар килә башлый, алар арасында үз тармакларында иң эреләрдән саналганнары да була, мәсәлән: С. П. Горбунов исемендәге Мәскәү авиация заводы, 387 номерлы Ленинград авиация заводы, Гомель «Труд» аяк киеме фабрикасы, 2 нче Мәскәү сәгать заводы. Бирегә эвакуацияләнгән предприятиеләр, республикада индустриаль базаның булуы аркасында, санаулы айлар һәм атналар эчендә кабат сафка баса: С. П. Горбунов исемендәге авиация заводында пикега сәләтле Пе-2 бомбардировщикларын (сугыш елларында алар барлыгы 10 меңнән артык данәдә җитештерелә) чыгару өчен җиһазлар ике ай эчендә җайга салына һәм эшли дә башлый; 387 номерлы Ленинград авиация заводы ике атна эчендә У-2 (1944 елдан – По-2) очкычларын җитештерүне башлап җибәрә.

Казанда чыгарылган, «тавышсыз оча торган» По-2 сугыш елларында легендар фронт машинасы буларак дан ала (немец командованиесе бу очкычны бәреп төшерә алган һәркемгә 5 мең марка күләмендә бүләк вәгъдә итә). Заводта хәрби очкычлар җитештерү 1945 елга 3,5 тапкырга арта: бер айга 100 дән – 350 данәгә кадәр. Сугыш елларында 387 номерлы завод фронтка барлыгы 11 553 очкыч җибәрә, моның өчен завод коллективы 1945 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Сугыш елларында Казанда ерак ара авиациясе өчен авыр Пе-8 бомбардировщигы – уникаль «оча торган ныгытма» эшләп чыгарыла. Аның сугышчан йөк күтәрү мөмкинлеге 6 тонна тәшкил итә, очу ераклыгы – 2 мең километрдан артык, очу биеклеге – 9,3 км. СССРда беренче буларак 1943 елда (АКШтан һәм Бөекбританиядән алданрак)

плёнки для фотосъёмок с больших высот; заводы искусственной кожи, пишущих машин, автогаражного оборудования перешли на изготовление мин, снарядов, осветительных бомб; меховые, валяльно-войлочные и трикотажные предприятия наладили выпуск военного обмундирования. Воевавшие на фронтах бойцы высоко ценили татарстанские полушубки, шапки-ушанки, унты, валенки. С июля 1941 г. в Татарстан начали прибывать эвакуированные заводы и фабрики из западных и центральных регионов страны, в том числе крупнейшие в своих отраслях: Московский авиационный завод им. С. П. Горбунова, Ленинградский авиационный завод № 387, Гомельская обувная фабрика «Труд», 2-й Московский часовой завод. Эвакуированные предприятия, во многом благодаря имевшейся в республике индустриальной базе, за считанные месяцы и недели вновь вступали в строй действующих: за два месяца на Авиационном заводе им. С. П. Горбунова было налажено оборудование по выпуску пикирующих бомбардировщиков Пе-2 (всего их за годы войны было произведено более 10 тыс.); за две недели Ленинградский авиационный завод № 387 наладил производство самолётов У-2 (с 1944 г. – По-2).

В годы войны По-2 – «небесный тихоход», выпускаемый в Казани, стал легендарной фронтовой машиной (немецкое командование объявило награду в 5 тыс. марок каждому, кто сумеет сбить этот самолёт). К 1945 г. производство боевых самолётов на заводе выросло в 3,5 раза: со 100 до 350 в месяц. Всего за годы войны заводом № 387 было отправлено на фронт 11 553 самолёта, за что коллектив завода в 1945 г. был награждён орденом Трудового Красного Знамени.

garage equipment switched to production of mines, shells, and flash bombs; the factories that were engaged in production of fur, felt, and knitwear products mastered the production of military uniform clothing. The frontline army men highly valued the short sheepskin coats, winter fur caps, high fur boots, and felt boots made in Tatarstan. From July 1941, the evacuated plants and factories began arriving in Kazan from the western and central regions of the country, including the largest one in their sectors of industry, such as the Moscow Aircraft Plant named after S. P. Gorbunov, the Leningrad Aircraft Plant No. 387, the Gomel Shoe Factory "Trud", and the Second Moscow Watch Factory. To a great degree it was owing to the industrial base that was available in the republic, that the enterprises, which were evacuated to the republic, were put into operation in just several weeks or months. For example, it took only two months for the Aircraft Plant named after S. P. Gorbunov to put into operation the equipment for the manufacture of Pe-2 dive bombers (all in all over 10 000 such bombers were manufactured over the years of war). The Leningrad Aircraft Plant No. 387 mastered the manufacture of U-2 airplanes (from 1944, Po-2) in just two weeks.

During the years of war, Po-2, known as the heavenly slug, that was manufactured in Kazan, became a legendary frontline aircraft (the German command offered a reward of 5 000 Deutschemarks to everyone, who would be able to shoot down the plane). By 1945, the manufacture of combat planes grew at the plant 3.5 times: from 100 up to 350 units a month. All in all, for the years of war, the Plant No. 387 sent to the front 11 553 planes, for which fact the personnel of the plant was awarded in 1945 the Order of the Red Banner of Labour.



Табиблар
Р. Гарифуллина һәм
З. Идиятуллина

Врачи Р. Гарифуллина
и З. Идиатуллина

Doctors R. Garifullina and
Z. Idiatullina



«Пишмаш» заводы.
Инструктор-технолог
Н. П. Тихонов басу
машинасы моделе
янында

Завод «Пишмаш».
Инструтор-технолог
Н. П. Тихонов у модели
пишущей машинки

"Pishmash" plant.
Instructor-technical
engineer N. P. Tikhonov
by the model
of a typewriter





В. М. Петляков, авиация конструкторы.
I дәрәҗәдәге Сталин премиясе лауреаты

В. М. Петляков, авиаконструктор. Лауреат
Сталинской премии I степени

V. M. Petlyakov, aircraft designer. Winner of the
Stalin's Award of the First Grade



В. Фролов, медицина-
инструментлар заводы
токаре


В. Фролов,
токарь медико-
инструментального
завода

V. Frolov, turner of the
Medical Instruments Plant

очкычның сугышчан коралланышында 5 тонна авырлыктагы бомба кулланыла. 1942 елның маенда шушы очкычта СССРның тышкы эшләр буенча халык комиссары В. М. Молотов җитәкчелегендәге совет делегациясе, Европаның оккупацияләнгән илләре өстеннән очып, союзниклар белән сөйләшүләр өчен башта – Бөекбританиягә, аннары Америка Президенты Рузвельт белән очрашу өчен АКШка барып җитә һәм исән-имин Мәскәүгә әйләнеп кайта. Казан заводында сугыш елларында 79 Пе-8 очкычы чыгарыла.

В годы войны в Казани производился уникальный тяжёлый бомбардировщик дальней авиации Пе-8 – «летающая крепость». Его боевая нагрузка составляла 6 т, дальность полёта – более 2 тыс. км, практическая высота – 9,3 км. В 1943 г. в боевом вооружении самолёта впервые в СССР стала использоваться бомба весом 5 т (раньше, чем в США и Великобритании). На нём в мае 1942 г. советская делегация во главе с наркомом иностранных дел СССР В. М. Молотовым пролетела над оккупированными странами Европы, направляясь на переговоры с союзниками в Великобританию, затем в США для встречи с американским президентом Рузвельтом, и благополучно вернулась в Москву. На казанском заводе в годы войны было выпущено 79 самолётов Пе-8.

In addition to that, during the years of war, Kazan was also manufacturing a unique long-range heavy bomber – Pe-8 – known as the "flying fortress". Its combat load was 6 tonnes, its range exceeded 2 000 km., and its operating altitude was 9.3 km. In 1943, for the first time in the USSR, the combat weaponry of the plane was supplemented with the bomb weighing 5 tonnes (which took place earlier than in the USA and in the Great Britain). This plane was used in May of 1942 by the Soviet delegation headed by People's Commissar for Foreign Affairs V. M. Molotov to fly, over the occupied European countries, first to the Great Britain to hold talks with the allies and then to the USA to meet with US President Roosevelt, after which the delegation safely returned to Moscow. The Kazan plant manufactured 79 Pe-8 planes over the years of war.



По-2 төнге бомбардировщиклары. 387 нче заводның җыю цехы. 1943

Ночные бомбардировщики По-2. Цех сборки завода № 387. 1943

PO-2 night bombers. Assembly workshop of the Plant No 387. 1943





Идел буе хәрби флотының Кожанов десант отряды пароходта Казан янында

Десантный отряд Кожанова Волжской военной флотилии на пароходе под Казанью

Assault regiment of Kozhanov of the Volga Military Flotilla at a steamship near Kazan

Сугыш елларында республиканың сәнәгать предприятиеләре фронтка 13 млрд сумлык 600 төрдән артык корал, кием, сугыш кирәк-яраклары (шул исәптән Пе-2, Пе-8, По-2 бомбардировщиклары, бронекатерлар, десант көймәләре, станоклы пулемётлар, миналар, гранаталар, мылтыклар, артиллерия һәм реактив кораллар өчен дары зарядлары, бинокльләр, төбәгечләр, перископлар һәм навигация приборлары, аэрофотография һәм рентген тасмалары, медикаментлар, парашютлар, чаңгылар, хәрби кием, өс һәм аяк киемнәре, эчке кием һ. б.) җибәрә. Сугыш елларында тулай сәнәгать продукциясен җитештерү – 2,2 тапкырга, шул исәптән машина төзелешендә 6,8 тапкырга үсә.

За годы войны промышленные предприятия республики поставили фронту свыше 600 видов вооружения, боеприпасов, снаряжения и обмундирования на 13 млрд рублей, в том числе бомбардировщики Пе-2, Пе-8, По-2, бронекатера, десантные баркасы, станковые пулемёты, мины, гранаты, пороховые заряды для стрелкового, артиллерийского и реактивного оружия, бинокли, прицелы, перископы и навигационные приборы, аэрофотографические и рентгеновские плёнки, медикаменты, парашюты, лыжи, обмундирование, обувь и нательное бельё. В годы войны валовой выпуск промышленности вырос в 2,2 раза, в том числе машиностроения – в 6,8 раза.

During the war, industrial enterprises of the republic supplied to the front over 600 types of weapons, munitions, and uniforms to the total amount of 13 billion roubles, including Pe-2, Pe-8, and Po-2 bombers, armoured boats, landing launches, mounted machine guns, mines, grenades, propellant powder for small-, artillery-, and rockets weapons, binoculars, sights, periscopes, and navigators, films for aerial photography and X-ray films, medications, parachutes, skis, uniform, footwear, and underwear. During the war, the gross industrial output grew 2.2 times, including the 6.8 times growth achieved in mechanical engineering.

Эвакуацияләнгән предприятиеләр базасында республикада авиация, моторлар төзү, сәгать ясау, ит консервлау, медицина инструментлары җитештерү, трикотаж һәм киҗе-мамык сәнәгать тармаклары барлыкка килә. 22 яңа предприятие төзелә, шулар арасында – Казандагы резина-техник эшләнмәләр, нефть-май, механика һәм ремонт-подшипник заводлары, ит комбинаты, туку, аяк киемнәре һәм киез фабрикалары, консервлау заводы, Алабугада, Урыссуда электр станцияләре. Сәнәгатьнең яңа – нефть чыгару тармагы барлыкка килә (1943 ел). Республика сәнәгате казанышлары – эшчеләрнең, инженер-техник хезмәткәрләрнең дошманны җиңү хакына үз-үзләрен аямыйча хезмәт куюы нәтиҗәсе, алардан 4 200 кеше орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

На базе эвакуированных предприятий в республике сложились авиационная, двигателестроительная, часовая, мясоконсервная, медико-инструментальная, трикотажная и хлопчатобумажная отрасли промышленности. Было построено 22 новых предприятия, в том числе завод резинотехнических изделий, нефтемаслозавод, механический и ремонтно-подшипниковый заводы в Казани, мясокомбинат, текстильная, сапожная и валяльная фабрики, консервный завод, электростанции в Елабуге, Уруссу. Появилась новая отрасль промышленности – нефтяная (1943 г.). Достижения промышленности республики – это результат самоотверженного труда рабочих, инженерно-технических работников во имя Победы над врагом, из них 4 200 человек были награждены орденами и медалями.

The evacuated enterprises provided the basis for the formation in the republic of the aircraft-building, engine-manufacturing, watch-making, meat-canning, medical instruments, knitwear, and cotton industries. Twenty two new enterprises were built, including the plant for production of industrial rubber goods, a petroleum oil plant, mechanical and ball-bearing repair plants that were built in Kazan, a meat-processing combine, a textile, shoemaking and milling plants, a canning plant, and power stations that were built in Yelabuga and Urussu. The new – oil – industry emerged (1943). The achievements of the republic's industry became the result of the self-denying labour of workers and engineers in the name of Victory over enemy. All in all, 4 200 people were awarded different orders and medals.

Очкычны суга төшерүгә әзерлек

Подготовка самолёта к спуску на воду

Preparing the plane for immersion





## Сугыш елларында авыл

Сугыш авыл халкының социаль-икътисади хәлен нык катлауландыра: сау-сәламәт, эшкә яраклы ир-атларның яртысыннан артыгы үзләре теләп фронтка китә; Кызыл Армия һәм сәнәгать ихтыяҗлары өчен автомашиналарның, тракторларның, дистә меңнәрчә эш атларының күп өлеше мобилизацияләнә. Моннан тыш, чәчүлек мәйданнары 1 млн гектардан артыкка кими, шул исәптән бодай чәчелә торган өлеше – 2 тапкырга. Өч ел эчендә (1942 – 1945) бөртеклеләрнең еллык уңышы 2,5 тапкырга түбәнәя. Сыер, сарык, кәҗә, дуңгызларның баш саны шушы елларда уртача – 1,8 тапкырга, атларныкы 2 тапкырдан артыгракка кими.

## Деревня в годы войны

Война серьёзно осложнила социально-экономическое положение населения деревень: более половины здоровых, работоспособных мужчин добровольно ушли на фронт; для нужд Красной Армии и промышленности была мобилизована значительная часть автомашин, тракторов, десятки тысяч рабочих лошадей. Кроме того, посевные площади сократились более чем на 1 млн га, в том числе под пшеницей – в 2 раза. За три года (1942 – 1945 гг.) ежегодные сборы зерновых уменьшились в 2,5 раза. Поголовье коров, овец, коз, свиней за эти годы сократилось в среднем в 1,8 раза, лошадей – более чем в 2 раза.

## Village During the Wartime

The war made seriously more difficult the lives of the rural population: over a half of healthy, able-bodied men went to the front as volunteers; a considerable portion of motor vehicles and tractors were mobilised for the needs of the Red Army, just like tens of thousands of working horses. What is more, the areas under crops were reduced by more than 1 million hectares, including such used for growing wheat, which were reduced 2 times. Over three years (1942 – 1945), the annual yield of grain crops reduced 2.5 times. The stock of cows, sheep, goats, and pigs over these years reduced, in average, 1.8 times, and the stock of horses reduced more than 2 times.

Бөек Ватан сугышы елларында уңыш җыю

Сбор урожая в годы Великой Отечественной войны

Harvesting during the years of the Great Patriotic War






Р. Ф. Сәйфуллин. «Югары уңыш өчен!» плакаты. 1942

Р. Ф. Сайфуллин. Плакат «За высокий урожай!». 1942

R. F. Saifullin. Poster “For High Yield!”. 1942



Тәмте урта мәктәбе укытучысы И. А. Касаткина Мәйдан машина-трактор станциясе комбайнында эштә. 1942

Учительница Теньковской средней школы И. А. Касаткина за работой на комбайне Майдановской МТС. 1942

I. A. Kasatkina, a teacher of the Tenkovo secondary school while working on a combine harvester of the Maidanovskaya machine and tractor station. 1942

Әмма, шуңа да карамастан, сугыш елларында ТАССРның авыл хезмәтчәннәре дәүләткә 2 363 мең тонна ашлык, 600 мең тонна бәрәңге һәм яшелчә, 325 мең тоннага якын терлекчелек продукциясе, 200 миллион литр сөт, 500 мең поттан артык йон, дистәләгән мең пот май, бал, туңмай, 11 млн пот печән һәм башка продукция бирә. Болар барысы да гадәттән тыш тырышлык һәм корбаннар бәрабәренә мөмкин була. Эшкә яраклы бер колхозчыга салынган йөкләмә 3 тапкырга арта.

Несмотря на эти обстоятельства, за годы войны сельские труженики ТАССР поставили государству 2 363 тыс. т зерна, более 600 тыс. т картофеля и овощей, около 325 тыс. т животноводческой продукции, 200 млн л молока, свыше 500 тыс. пудов шерсти, десятки тысяч пудов масла, мёда, сала, 11 млн пудов сена и другой продукции. Всё это стало возможно в результате чрезвычайных усилий и жертв. Нагрузка на одного трудоспособного колхозника возросла в 3 раза.

But, despite these circumstances, over the years of war, the village workers of the TASSR supplied to the state 2 363 000 tonnes of grain, over 600 000 tonnes of potato and vegetables, some 325 000 tonnes of animal products, 200 million litres of milk, over 500 000 poods of wool, tens of thousands of poods of butter, honey, pork fat, 11 million poods of hay, and other products. All this became possible as a result of extraordinary efforts and sacrifice. The load per one able-bodied collective farmer grew 3 times.

Шул ук вакытта хезмәт хакы шактый зур күләмдә кими: 1943 елда колхозчыларга бер хезмәт көненә уртача 0,4 кг икмәк бирелә (1940 елда – уртача 1,4 кг). 1942 елда хәрби салым кертелү, натураль түләүләрнең күләме арттырылу белән авыл кешесенең матди хәле һәм азык-төлек ягы тагын да начарая, шул сәбәпле төрле эпидемияләр баш калкыта. Шуларның иң куркынычы үлекле тамак бакасы була. Авыру 1944 елда Татарстан авылларының шактый өлешен биләп ала, дистәләгән мең кешенең үлеменә китерә.

При этом произошло значительное сокращение заработной платы: в 1943 г. колхозникам на трудодень в среднем выдавали 0,4 кг хлеба (в 1940 г. – в среднем 1,4 кг). С введением в 1942 г. военного налога, увеличением размеров натуральных поставок материальное и продовольственное положение сельского населения ещё больше ухудшилось, что стало причиной различных эпидемий, наиболее страшной из них была септическая ангина, которая в 1944 г. охватила значительную часть сельских территорий Татарстана, став причиной смерти десятков тысяч людей.

At the same time, a considerable reduction of wages took place: in 1943, the collective farmers were given, in average, 0.4 kg of bread for one labour day (in 1940, in average, 1.4 kg). The introduction, in 1942, of the war tax and the increased amounts of supplies in kind worsened the material standing and food situation of the rural population even more. This became the reason for different epidemics, the worst of which was the septic angina, which struck a significant portion of rural areas of Tatarstan in 1944 and caused death of tens of thousands of people.

Беренче Май районының «Үзәк» колхозы активы сәясәт дәресендә

Политзанятие активов колхоза «Үзяк» Первомайского района

Political lessons for activists of “Uzyak” Collective Farm in the Pervomaisky District



## Фронтка бөтен халык ярдәме

Республика халкы фронтка ярдәм күрсәтүдә бик актив катнаша. Сугыш башланып бер ай узуга ук, алар мәскәүлеләрнең Оборона фонды төзү турындагы башлангычын хуплап ала. 1941 елның ахырына Татарстан хезмәт ияләреннән илнең Оборона фондына 16,2 млн сум акча, 26 кг көмеш һәм 800 грамм алтын керә; фронтовиклар өчен 10 мең кыска тун, 25,5 мең пар киез итек, 30 мең пардан артык җылы урынҗир әйберләре, 46 мең колакчынлы бүрек җыела. 1943 ел ахырына фондка ирекле иганә итеп бирелгән акчаларның гомуми суммасы 51 млн сумга җитә. Кызыл Армия өчен җылы әйберләр туплау буенча хәрәкәт Татарстан халкы арасында киң таралыш ала: сугыш елларында барлыгы 10 миллионнан артык җылы әйбер җыела. Сугыш башлангач та, республикада хәрби техника төзелешенә акча җыю хәрәкәте барлыкка килә. Казан тимер юлы эшчеләре үзләре җыйган акчага «Кызыл Татарстан», «Чапаев», «Куйбышев» бронепоездларын төзи, ә аларның экипажларын үз хезмәттәшләреннән туплый. Яшел Үзән шәһәре халкы тулысынча коралландырылган ике бронялы кораб төзүгә акча җыеп бирә. Республикада яшәүчеләр акчасына «Татарстан комсомолы», «Татарстан колхозчысы», «Кызыл Татарстан» танк колонналары, 202 нче Урта Дон авиация дивизиясе составында сугышучы «Совет Татарстаны» авиаэскадрильясе өчен бомбардировщиклар төзелә. 1942 елның сентябрь аенда 6 җиңел бомбардировщик Кызыл Байраклы 930 нчы Трансильвания

## Всенародная помощь фронту

Жители республики активно участвовали в оказании помощи фронту. Через месяц после начала войны они поддержали почин москвичей о создании Фонда обороны. К концу 1941 г. от трудящихся Татарстана в Фонд обороны страны поступило 16,2 млн рублей, 26 кг серебра и 800 г золота; для фронтовиков было собрано 10 тыс. полушубков, 25,5 тыс. пар валенок, более 30 тыс. пар тёплого белья, 46 тыс. шапок-ушанок. К концу 1943 г. общая сумма добровольных пожертвований в фонд достигла 51 млн рублей. Среди населения Татарстана широкое развитие получило движение по сбору тёплых вещей и белья для бойцов Красной Армии: всего за годы войны было собрано более 10 млн единиц тёплых вещей. В начале войны в республике возникло движение по сбору средств на строительство боевой техники. Железнодорожники Казанской железной дороги на собственные средства построили бронепоезда «Кызыл Татарстан», «Чапаев», «Куйбышев», а их экипажи укомплектовали своими рабочими. Жители Зеленодольска пожертвовали средства на строительство двух бронированных кораблей с полным вооружением. На средства населения республики были построены танковые колонны «Комсомолец Татарии», «Колхозник Татарии», «Красная Татария», бомбардировщики для авиаэскадрильи «Совет Татарстаны», сражавшейся в составе 202-й Средне-Донской бомбардировочной авиационной дивизии. В сентябре 1942 г. 6 лёгких бомбардировщиков было передано лётчикам 930-го Трансильванского Краснознамённого авиаполка, всего за годы войны полк получил из Казани 48 самолётов, построенных на

## National Support to the Front

Citizens of the republic took an active part in provision of support to the front. One month after the war began they supported the initiative of Moscow citizens to establish a Defence Fund. By the end of 1941, the working people of Tatarstan contributed to the Defence Fund of the country 16.2 million roubles, 26 kg of silver and 800 g of gold. Collected for the frontliners were 10 000 short fur coats, 25 500 pairs of felt boots, over 30 000 pairs of warm underwear, and 46 000 winter fur caps. By the end of 1943, the total amount of voluntary contributions to the Fund made up 51 million. Wide spread among the population of Tatarstan became the movement for collection of warm clothes and underwear for the Red Army: all in all over the years of war collected were more than 10 million items of warm clothes. In the beginning of the war, a movement emerged in the republic for collection of funds for the building of combat equipment. The railroad workers of the Kazan Railways contributed their own funds for the manufacture of “Kyzyl Tatarstan”, “Chapayev”, and “Kuibyshev” armoured trains, and staffed them with workers of the enterprise. Citizens of Zelenodolsk contributed funds for the manufacture of two fully armed armoured ships. The funds collected by citizens of the republic were used to build tank columns named “Young Communist of Tataria”, “Collective Farmer of Tataria”, and “The Red Tataria”, as well as bombers for the aircraft squadron named “Soviet Tatarstan” that fought on the front being a part of the 202nd Middle Don Bomber Air Division. In September of 1942, 6 light bombers were handed over to pilots of the 930th Transylvanian Order of the Red Banner Aviation Regiment. All in all, over the years of the war, the regiment received from Kazan 48 planes that were built with the money collected from the youth. The total amount collected for the manufacture of different combat equipment was 380 million roubles.




«Син фронтка нәрсә белән ярдәм иттең? Кызыл Армия өчен җылы кием-салым тапшырдыңмы!» плакаты

Плакат «Чем ты помог фронту? Сдал ли ты тёплые вещи и бельё для Красной Армии!»

Poster “How did you help the front? Did you bring warm clothes and underwear for the Red Army?”. 1941



Фронт өчен җыелган җылы киемнәрне исәпләү. 1941

Учёт собранных тёплых вещей для фронта. 1941

Taking inventory of the collected warm clothes for the front. 1941




Д. С. Моор. «Син фронтка ничек ярдәм иттең?» плакаты. 1941

Д. С. Моор. Плакат «Ты чем помог фронту?». 1941

D. S. Moor. Poster “How did you help the front?”



Киез-фетр фабрикасы стахановчылары Нәбиуллина һәм Заһирова

Стахановки валяльно-фетровой фабрики Набиуллина и Загирова

Nabiullina and Zagirova, Stakhanov’s followers from the milling and felt-wear factory




Р. Ф. Сәйфуллин. «Кызыл Армиягә – җылы киемнәр!» плакаты. 1941

Р. Ф. Сайфуллин. Плакат «Красной Армии – тёплые вещи!». 1941

R. F. Saifullin. Poster “Warm Clothes for the Red Army!”. 1941




«Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай оешмалары – Кызыл Армиянең иң якын ярдәмчеләре» плакаты. 1942

Плакат «Организации Красного Креста и Красного Полумесяца – ближайшие помощники Красной Армии». 1942

Poster of the “Organisations of the Red Cross and Red Crescent are the Closest Assistants of the Red Army”. 1942

авиаполкы очучыларына тапшырыла, әлеге полк сугыш елларында Казаннан яшьләр акчасына төзелгән 48 очкыч ала. Төрле хәрби техника төзелеше өчен барлыгы 380 млн сум акча җыела.

Посылкалар җибәрү фронтовикларга шефлык итүнең киң таралган формасы булып тора. Яңа елга (1942 ел) хәрәкәттәге армиягә 500 мең сумлык посылкалар җибәрелә, 1942 – 1944 елларда гомуми бәясе 10,6 млн сумлык бүләкләр озатыла. Республика комиссиясенең бүләкләр сатып алу өчен тәгаенләнгән агымдагы хисабына халыктан 38,2 млн сум акча керә.

Тыл хезмәтчәннәренең фронтка әчкерсез һәм риясыз ярдәме Кызыл Армия сугышчыларының мораль халәтен һәм героик рухын күтәрүгә ярдәм итеп кенә калмый, республикада яшәүчеләрне какшамас бербөтен итеп берләштерә, дошманны җиңүгә һәркемнең өлеш кертә алу мөмкинлеге барлыгын күрсәтә.

средства молодёжи. Всего на строительство различной боевой техники было собрано 380 млн рублей.

Распространённой формой шефства над фронтовиками стала отправка им посылок. К Новому году (1942 г.) в действующую армию было отправлено посылок на 500 тыс. рублей, в 1942 – 1944 гг. – отправлено подарков на общую сумму 10,6 млн рублей. На текущий счёт республиканской комиссии для закупки подарков от населения поступило 38,2 млн рублей.

Беззаветная и бескорыстная помощь фронту тружеников тыла не только способствовала поднятию морального и героического духа бойцов Красной Армии, но и сплотила население республики в одно нерушимое целое, показав, что каждый способен внести свой вклад в победу над врагом.

The sending of parcels to the front became a wide-spread form of supporting the frontliners. Sent by the new (1942) year to the active army were parcels to the total amount of 500 000 roubles. In 1942 – 1944, sent to the front were various presents to the total amount of 10.6 million roubles. The population transferred 38.2 million roubles to the current account of the republic's commission for purchase of presents.

The self-denying and selfless assistance rendered to the front by homefront workers not only contributed to the improvement of the morale and the heroic spirit of soldiers of the Red Army, but also welded the population of the republic into the imperishable whole, having shown that everyone was able of making his own contribution to the victory over the enemy.




Калинин фронты. Генерал И. В. Панфилов дивизиясе. Стан пулемёты расчёты: А. Н. Моратов, Н. Ф. Фадеев. 1942

Калининский фронт. Дивизия генерала И. В. Панфилова. Расчёт станкового пулемёта: А. Н. Муратов, Н. Ф. Фадеев. 1942

The Kalininsky front. Division of General I. V. Panfilov. The crew of a heavy machine gun: A. N. Muratov, N. F. Fadeyev. 1942

## Хәрби подразделениеләр төзелү

Татар республикасы сугыш елларында Кызыл Армия өчен хәрби резервлар әзерләү үзәкләренең берсенә әйләнә. 1941 – 1945 елларда Всевобуч-та – 186 мең кеше, физик культура оешмаларында – 250 мең чаңгычы, кул сугышы остасы һәм йөзүче, ОСОАВИАХИМ курсларында 163 655 укчы-атучы, 1,9 меңнән артык һава һөҗүме һәм химия оборонасы белгече әзерлек үтә. Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай җәмгыяте тарафыннан – 6 590 шәфкать туташы һәм сандружиначы, «Санитар оборонага әзер» һәм «Санитар оборонага әзер бул» программалары буенча 943 мең кеше укытыла. Хәрби хәзерлекнең төрле формалары белән бөтен Татарстан халкы диярлек колачланган була.

## Формирование воинских подразделений

Татарская республика в годы войны стала одним из центров подготовки военных резервов для Красной Армии. В 1941 – 1945 гг. во Всевобуче прошли подготовку 186 тыс. человек, в физкультурных организациях – 250 тыс.лыжников, бойцов рукопашного боя и пловцов, на курсах ОСОАВИАХИМ – 163 655 бойцов-стрелков (специалистов) и свыше 1,9 тыс. специалистов по противовоздушной и химической обороне. Обществом Красного Креста и Красного Полумесяца было обучено 6 590 медсестёр и сандружинниц, 943 тыс. человек – по программам «Готов к санитарной обороне» и «Будь готов к санитарной обороне». Различными формами военной подготовки было охвачено практически всё население Татарстана.

## Formation of Military Elements

During the war, the Tatar Republic became one of the training centres engaged in training of military reserves for the Red Army. In 1941 – 1945, 186 000 people were trained by Vsevobuch (Universal Military Training); sport organisations trained 250 000 skiers, close-in combat fighters, and swimmers; trained at the courses organised by OSOAVIAKhIM (Union of Societies of Assistance to Defence and Aviation-Chemical Construction) were 163 655 expert gunners and over 1 900 specialists in air and chemical defence. The Red Cross and Red Crescent Society trained 6 590 nurses and members of medical detachments; 943 000 people were trained under programmes named “Ready for Sanitary Defence” and “Be Ready for Sanitary Defence”. Almost entire population of Tatarstan was involved in different forms of military training.



М. Сыртланова, гвардия өлкән лейтенанты, Советлар Союзы Герое

М. Сыртланова, гвардии старший лейтенант, Герой Советского Союза

M. Syrtlanova, Senior Lieutenant of the Guards, Hero of the Soviet Union



Г. Сафиуллин, генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое

Г. Сафиуллин, генерал-лейтенант, Герой Советского Союза

G. Safiullin, LieutenantGeneral, Hero of the Soviet Union



С. В. Коновалов, лейтенант, Советлар Союзы Герое

С. В. Коновалов, лейтенант, Герой Советского Союза

S. V. Konovalov, Lieutenant, Hero of the Soviet Union

Сугыш елларында ТАССР территориясендә 7 укчы дивизия (шул исәптән 18 нче һәм 86 нчы дивизияләр – сугышка кадәрге чорда), танк бригадасы, зенит-артиллерия полкы һәм башка хәрби берләшмәләр төзелә, алар дошманны җиңүгә үзләренең саллы өлешен кертә. Араларында – ТАССРда 1941 елның август – октябрь айларында төзелгән, Мәскәү өчен сугышта, Белоруссия, Литва һәм Латвияне азат итүдә, Көнчыгыш Пруссия территориясендәге сугышларда катнашкан Кызыл Байраклы, Суворов орденлы 334 нче Витебск укчы дивизиясе; ТАССРда 1942 елның март – июнь айларында оешкан, 120 нче укчы дивизия буларак Сталинград һәм Курск сугышларында, Корсунь-Шевченко һәм Яссы-Кишинёв һөҗүм операцияләрендә, Румыния, Венгрия, Австрияне азат итүдә катнашкан Кызыл Байраклы 69 нчы Звенигород гвардия укчы дивизиясе; Бөгелмәдә 1941 елның август – ноябрь айларында төзелгән, Мәскәү янындагы сугышларда, Смоленск төбәген һәм Белоруссияне азат итүдә, Польша, Көнчыгыш Пруссия, Чехословакия территорияләрендә немец гаскәрләрен тармар итүдә катнашкан Кызыл Байраклы, Суворов орденлы 352 нче Орша укчы дивизиясе; Казанда 1941 ел ахырында – 1942 ел башында оешкан, Мәскәү тирәсендәге сугышларда, Остров, Тарту, Рига, Варшава шәһәрләрен азат итүдә, Берлинны штурмлауда катнашкан Кызыл Байраклы, Суворов орденлы 146 нчы Остров укчы дивизиясе; 1942 елда тупланган, Сталинград өчен, шулай ук Волхов, Степной, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары составында сугышларда катнашкан 147 нче Станислав укчы дивизиясе; 1942 елның март – май айларында төзелгән, Сталинград һәм Курск сугышларында, Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлин һәм Прага операцияләрендә катнашкан 91 нче Фастов танк бригадасы; 1940 елның җәендә формалашкан, Минск, Смоленск, Мәскәү, Сталинград, Курск янындагы оборона сугышларында, Украина, Чехословакия, Польша, Германияне азат итүдә катнашкан Кызыл Байраклы, Суворов орденлы ТАССР Югары Советы исемендәге 202 нче Урта Дон бомбардировщиклар авиациясе дивизиясе. 1943 елның 1 маенда Казан аэродромында тантаналы шартларда шушы авиация дивизиясенә, шул исәптән «Совет Татарстаны» авиаэскадрильясе өчен, республика халкы акчасына төзелгән 102 бомбардировщик тапшырыла. 1942 елның җәеннән Татарстанда 8 нче запас авиация бригадасы урнаштырыла, анда сугыш елларында марштагы 69 полк, марштагы 7 эскадрилья, 1201 аерым экипаж Пе-2 очкычына тәгаенләп яңадан укытыла.

В годы войны на территории ТАССР были сформированы 7 стрелковых дивизий (в том числе 18-я и 86-я дивизии – в довоенный период), танковая бригада, зенитно-артиллерийский полк и другие воинские формирования, внесшие весомый вклад в победу над врагом. Среди них: 334-я Витебская Краснознамённая ордена Суворова стрелковая дивизия, сформированная в ТАССР в августе – октябре 1941 г., участвовавшая в битве за Москву, в сражениях за освобождение Белоруссии, Литвы и Латвии, на территории Восточной Пруссии; 69-я Звенигородская Краснознамённая гвардейская стрелковая дивизия, сформированная в ТАССР в марте – июне 1942 г. как 120-я стрелковая дивизия, – в Сталинградской и Курской битвах, Корсунь-Шевченковской и Ясско-Кишинёвской наступательных операциях, в освобождении Румынии, Венгрии, Австрии; 352-я Оршанская Краснознамённая ордена Суворова стрелковая дивизия, сформированная в г. Бугульме в августе – ноябре 1941 г., – в битве под Москвой, в освобождении Смоленщины и Белоруссии, в разгроме немецких войск на территории Польши, Восточной Пруссии, Чехословакии; 146-я Островская Краснознамённая ордена Суворова стрелковая дивизия, сформированная в конце 1941 – начале 1942 г. в Казани, – в битве под Москвой, в освобождении гоородов Остров, Тарту, Рига, Варшава, в штурме Берлина; 147-я Станиславская стрелковая дивизия, сформированная в 1942 г., – в битве за Сталинград, в сражениях в составе Волховского, Степного, Воронежского и 1-го Украинского фронтов; 91-я Фастовская танковая бригада, сформированная в марте – мае 1942 г., – в Сталинградской и Курской битвах, в освобождении Украины и Польши, в Берлинской и Пражской операциях; 202-я Средне-Донская Краснознаменная ордена Суворова бомбардировочная авиационная дивизия им. Верховного Совета ТАССР, сформированная летом 1940 г., – в оборонительных боях под Минском, Смоленском, Москвой, Сталинградом, Курском, в освобождении Украины, Чехословакии, Польши, Германии. 1 мая 1943 г. на Казанском аэродроме в торжественной обстановке авиационной дивизии были переданы 102 бомбардировщика, построенные на средства населения республики, в том числе для авиаэскадрильи «Совет Татарстаны». С лета 1942 г. в Татарстане была развёрнута 8-я запасная авиационная бригада, в которой за годы войны прошли переобучение на самолёт Пе-2 69 маршевых полков, 7 маршевых эскадрилий, 1201 отдельный экипаж.

During the years of war, formed in the territory of Tatarstan were 7 rifle divisions (including the 18th and the 86th divisions that were formed in the pre-war period), a tank brigade, an anti-aircraft artillery regiment, and other military units that made a considerable contribution to the victory over the enemy. Among them: the 334th Vitebsk Red Banner and Order of Suvorov Rifle Division that was formed in the TASSR in August-October 1941, which took part in the battle of Moscow, in battles for liberation of Byelorussia, Lithuania and Latvia, as well as in battles in the territory of East Prussia; the 69th Zvenigorod Red Banner Guards Rifle Division that was formed in the TASSR in March-June 1942 as the 120th Rifle Division, which took part in the battles of Stalingrad and Kursk, in the Korsun-Chevchenko and Jassy-Kishinev offensive operations, in battles for liberation of Romania, Hungary, and Austria; the 352nd Orsha Red Banner and Order of Suvorov Rifle Division that was formed in Bugulma in August-November 1941, which took part in the battle of Moscow, in battles for liberation of Smolensk Region and Byelorussia, in the destruction of German forces in the territory of Poland, East Prussia, and Czechoslovakia; the 146th Ostrov Red Banner and Oder of Suvorov Rifle Division that was formed at the end of 1941 and early 1942 in Kazan, which took part in the battle of Moscow, in battles for liberation of the towns of Ostrov, Tartu, Riga, Warsaw, in the assault of Berlin; the 147th Stanislav Rifle Division that was formed in 1942, which took part in the battle of Stalingrad, in battles on the Volkhov, Steppe, Voronezh and the 1st Ukrainian fronts; the 91st Fastov Tank Brigade that was formed in March – May 1942, which took part in the battles of Stalingrad and Kursk, in battles for liberation of Ukraine and Poland, in the Berlin and Prague operations; the 202nd Middle Don Red Banner and Order of Suvorov Bomber Aviation Division named after the Supreme Council of the TASSR that was formed in summer of 1940, which took part in defensive battles near Minsk, Smolensk, Moscow, Stalingrad, Kursk, in battles for liberation of Ukraine, Czechoslovakia, Poland, and Germany. On 1 May 1943, 102 bombers, including such for the "Soviet Tatarstan" aircraft squadron, that were manufactured with the funds of the republic's population were handed over to the aviation division in the course of an official ceremony held at the Kazan airdrome. Starting from summer of 1942, deployed in Tatarstan was the 8th Reserve Aircraft Brigade that was engaged in retraining of pilots for flying the Pe-2 plane of 69 cruise regiments, 7 cruise squadrons, and 1 201 separate crews.



Генерал-лейтенант А. О. Ахманов часть командирлары белән Луцк шәһәрендәге Беренче Май парадыннан соң

Генерал-лейтенант А. О. Ахманов с командирами части после первомайского парада в г. Луцке

Lieutenant General A. O. Akhmanov with unit commanders after the May Day Parade in Lutsk






Х. Г. Якупов. Ireккә очыш. Михаил Девятаев батырлыгы. 1971

Х. А. Якупов. Полёт на свободу. Подвиг Михаила Девятаева. 1971

K. A. Yakupov. Flight to Freedom. Feat of Mikhail Devyatayev. 1971



М. П. Девятаев әсирлектән качкан Heinkel He-111 очкычы

Самолёт Heinkel He-111, на котором М. П. Девятаев бежал из плена

He-111 aircraft used by M. P. Devyatayev to flee from captivity



Советлар Союзы Герое М. П. Девятаев хәрби хезмәткәрләр белән очрашуда

Герой Советского Союза М. П. Девятаев на встрече с военнослужащими

M. P. Devyatayev, Hero of the Soviet Union, at a meeting with military men

## Татарстанлыларның сугышчан батырлыгы

Сугыш елларында хәрәкәттәге армия сафларына республикадан 700 меңгә якын кеше җибәрелә, аларның 350 меңгә якыны һәлак була. Татарстанлылар меңнәрчә тапкыр хәрби каһарманлык үрнәкләре күрсәтә. Бөек Ватан сугышы фронтларында кылган батырлыклары һәм фидакярлекләре өчен 100 меңнән артык татарстанлы орден һәм медальләр белән бүләкләнә, 225 тән артык кеше югары дәрәҗәдә танылуга – Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, 50 кеше Дан орденының тулы кавалеры була. Бүләкләнүчеләр арасында – төп чыгышлары белән Татарстаннан булганнар: Советлар Союзы Геройлары – Брест крепосте оборонасы каһарманы майор П. М. Гаврилов; дошманның ут ноктасы амбразурасын үз гәүдәсе белән каплаган Г. Гафиятуллин; дошманның «Хейнкель-111» бомбардировщигын куып алып китеп, немец концлагереннан качкан М. П. Девятаев; немец концлагерьларындагы яшерен татар антифашистик хәрәкәтенең идея җитәкчесе һәм рухландыручысы һәм актив катнашучысы М. Җәлил; Сталинград сугышында һәм күп һөҗүм операцияләрендә катнашкан генерал-майор

## Ратные подвиги уроженцев Татарстана

За годы войны в ряды действующей армии из республики было отправлено около 700 тыс. человек, из них около 350 тыс. погибли. Уроженцы Татарстана показали тысячи примеров воинской доблести. За героизм и самоотверженность, проявленные на фронтах Великой Отечественной войны, свыше 100 тыс. татарстанцев были награждены орденами и медалями, более 225 человек удостоены высшей степени отличия – звания Героя Советского Союза, 50 человек стали полными кавалерами ордена Славы. Среди награждённых – уроженцы Татарстана: Герои Советского Союза – майор П. М. Гаврилов, герой обороны Брестской крепости; Г. Гафиятуллин, закрывший своим телом амбразуру вражеского дота; М. П. Девятаев, совершивший побег из немецкого концлагеря на угнанном им бомбардировщике «Хенкель-111»; М. Джалиль – идейный вдохновитель и активный участник татарского антифашистского подполья в немецких концлагерях; генерал-майор Г. Сафиуллин, участник Сталинградской битвы и многих наступательных операций; Н. Г. Столяров – лётчик, штурман штурмовой авиации; отважная лётчица М. Сыртланова, летавшая на самолёте По-2; героический лётчик-истребитель Г. Р. Павлов (впоследствии генерал-лейтенант авиации), совершивший к марту

## Feats of Arms of Natives of Tatarstan

Over the years of war, sent by the republic to the ranks of the active army were some 700 000 people, of which some 350 000 were killed. Natives of Tatarstan showed thousands of examples of martial prowess. Over 100 000 natives of Tatarstan were awarded the orders and medals for heroism and self-defiance displayed on the fronts of the Great Patriotic War. Over 225 people were awarded the highest title of the Hero of the Soviet Union, 50 people became Full Cavaliers of the Order of Glory. The awardees included the following natives of Tatarstan: Heroes of the Soviet Union – Major P. M. Gavrilov, hero of defence of the Brest Fortress, G. Gafiyatullin, who covered the firing port of the enemy's permanent fire position with his body, M. P. Devyatayev, who escaped the German concentration camp on a stolen Heinkel-111 bomber, M. Jalil, a thought leader and an active participant of the Tatar anti-fascist underground movement in German concentration camps, Major General G. Safiullin, participant of the Battle of Stalingrad and numerous offensive operations, N. G. Stolyarov, a pilot, navigator of attack aviation (awarded two times), M. Syrtlanova, a brave pilot who flew Po-2 plane, G. R. Pavlov, a heroic fighter pilot (later Lieutenant General of Aviation), who took 507 combat flights by March 1945 and who personally shot down 17 enemy planes

Х. Г. Якупов. Хөкем алдыннан (1941 елда Моабит төрмәсендә җәзаланган патриот шагыйрь Муса Җәлил). 1954

Х. А. Якупов. Перед приговором (поэт-патриот Муса Джалиль, казнённый в Моабитской тюрьме в 1941 г.). 1954

K. A. Yakupov. Before the sentence (poet-patriot Musa Jalil, who was executed in the Moabit Prison in 1941). 1954



Ф. Булатов, хәрби начальник, генерал-майор

Ф. Булатов, военачальник, генерал-майор

F. Bulatov, military commander, Major General



В. Н. Гордов, хәрби начальник, генерал-полковник, Советлар Союзы Герое

В. Н. Гордов, военачальник, генерал-полковник, Герой Советского Союза

V. N. Gordov, military commander, Colonel General, Hero of the Soviet Union



Я. Җ. Чанышев, хәрби эшлекле, генерал-лейтенант

Я. Дж. Чанышев, военный деятель, генерал-лейтенант

Y. J. Chanyshev, military commander, Lieutenant General

Г. Сафиуллин; очучы, штурмлаучы авиация штурманы Н. Г. Столяров; По-2 самолётында очкан кыю очучы М. Сыртланова; каһарман очучы-истребитель (соңыннан авиация генерал-лейтенанты), 1945 елның мартына кадәр 507 сугышчан очыш ясаган һәм 108 һава сугышында дошманның 17 очкычын бәреп төшергән Г. Р. Павлов; куркусыз танкист, КВ-1 танкы командиры, чолганышта калган килеш тигезсез сугышта дошманның 16 танкын һәм үзйөрешле артиллерия җайланмасын юкка чыгарган С. В. Коновалов. Сугыш елларында ике мәртәбә (1941 елда һәм 1942 елда (үлгәннән соң) Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән батыр очучы Г. С. Смирновның лаеклы бүләге 2008 елда гына иясен таба: Россия Президенты В. В. Путин Указы белән аңа Россия Федерациясе Герое исеме бирелә (үлгәннән соң).

Генераллар А. О. Ахманов, Ф. Г. Булатов, В. Г. Бурков, В. Н. Гордов, А. Ф. Казанкин, А. В. Кирсанов, З. Ю. Кутлин, Г. Б. Сафиуллин, Я. Җ. Чанышев һ. б. югары дәрәҗәдәге хәрби талант һәм батырлык күрсәтәләр.

Татарстанлылар партизаннар хәрәкәтендә катнаша, зур батырлык һәм ныклык үрнәкләре күрсәтә. Мисал өчен: И. Заикин, З. Нури (Белоруссиядә); Н. А. Барышев, Т. Гайнанов, К. Галләмов (Кырымда); Г. С. Әмиров, А. Ш. Бикбаев, Б. Х. Кадырмәтов, Х. М. Садров (Смоленск өлкәсендә). Чехословакия территориясендәге партизаннар отрядларында – Д. Мурзин (партизаннар бригадасы командиры), Н. В. Сметанин (партизаннар бригадасы комиссары), К. Әминов, К. Батуллин, Ш. Бикбулатов, Б. Г. Мадьяров, М. Н. Мифтахов, А. Г. Мостафин, Г. С. Усманов, Г. Шәйхуллов; Югославиядә – Г. Г. Малов (бригада комиссары), Польшада М. С. Атаманов («Мишка Татар») батырларча көрәшкән.

Немец концлагерьларындагы Каршылык хәрәкәтен оештыруда – А. Аднашев, А. Алиш, А. Батталов, Н. Дәүли, М. Җәлил, Г. Нурдинов, Ә. Симаев, М. Хәйретдинов һ. б.; Франциядәге Каршылык хәрәкәтендә Р. Боков, М. Ф. Гайсин, В. П. Игнатьев, З. К. Камалов, Р. Н. Рылова, Ә. Г. Үтәшев, З. Шамигуллов һ. б. катнаша.

Сугышчы татарстанлылар, батырлык, каһаманлык һәм хәрби кыюлык үрнәкләре күрсәтеп, фашистлар Германиясен һәм аның иярченнәрен тар-мар итеп, дөньяны фашист коллыгыннан коткарып, Бөек Җиңү елъязмасына үз исемнәрен алтын хәрефләр белән яздылар.

1945 г. 507 боевых вылетов и в 108 воздушных боях лично сбивший 17 самолётов противника; бесстрашный танкист, командир танка КВ-1 С. В. Коновалов, оказавшийся во вражеском окружении, в неравном бою уничтоживший 16 танков и САУ противника. Мужественный лётчик Г. С. Смирнов, в годы войны дважды представленный к званию Героя Советского Союза (посмертно), свою заслуженную награду получил только в 2008 г.: указом Президента России В. В. Путина ему было присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).

Полководческий талант и героизм проявили генералы А. О. Ахманов, Ф. Г. Булатов, В. Г. Бурков, В. Н. Гордов, А. Ф. Казанкин, А. В. Кирсанов, З. Ю. Кутлин, Г. Б. Сафиуллин, Я. Дж. Чанышев и др.

Уроженцы Татарстана участвовали в партизанском движении и проявили образцы героизма и стойкости: И. Заикин, З. Нури (в Белоруссии); Н. А. Барышев, Т. Гайнанов, К. Галлямов (в Крыму); Г. С. Амиров, А. Ш. Бикбаев, Б. Х. Кадырметов, Х. М. Садров (в Смоленской области). В партизанских отрядах на территории Чехословакии героически сражались Д. Мурзин (командир партизанской бригады), Н. В. Сметанин (комиссар партизанской бригады), К. Аминов, К. Батулин, Ш. Бикбулатов, Б. Г. Мадьяров, М. Н. Мифтахов, А. Г. Мустафин, Г. С. Усманов, Г. Шайхулов; в Югославии – Г. Г. Малов (комиссар бригады), в Польше – М. С. Атаманов («Мишка Татар»).

В организации сопротивления в немецких концлагерях участвовали А. Аднашев, А. Алиш, А. Батталов, Н. Даули, М. Джалиль, Г. Нурдинов, А. Симаев, М. Хайрутдинов и др.; во французском движении Сопротивления – Р. Боков, М. Ф. Гайсин, В. П. Игнатьев, З. К. Камалов, Р. Н. Рылова, А. Г. Утяшев, З. Шамигулов и др.

Мужеством, героизмом и воинской доблестью воины-татарстанцы вписали свои имена в анналы великой Победы над фашистской Германией и её сателлитами, избавив мир от фашистской чумы.

in 108 air fights, S. V. Konovalov, a fearless tankman, commander of KV-1 tank, who, being encircled by enemies, destroyed 16 tanks and self-propelled guns of the enemy in an unequal battle. G. S. Smirnov, a brave pilot, who was a two-times nominee for the title of the Hero of the Soviet Union during the years of war (posthumously), received the just award as late as in 2008: he was awarded the title of the Hero of the Russian Federation (posthumously) by Decree of President of Russia V. V. Putin.

The talent of a military leaders and heroism were displayed by Generals A. O. Akhmanov, F. G. Bulatov, V. G. Burkov, V. N. Gordov, A. F. Kazankin, A. V. Kirsanov, Z. Y. Kutlin, G. B. Safiullin, Y. D. Chanyshev, and so on.

The natives of Tatarstan who participated in the guerrilla movement and showed heroism and persistence included I. Zaikin, Z. Nuri (in Byelorussia); N. A. Baryshev, T. Gainanov, K. Gallyamov (in the Crimea); G. S. Amirov, A. S. Bikbayev, B. K. Kadyrmetov, K. M. Sadrov (in the Smolensk Region). Fighting heroically in the guerrilla regiments in the territory of Czechoslovakia were D. Murzin (commander of a guerrilla brigade), N. V. Smetanin (commissar of a guerilla brigade), K. Aminov, K. Batulin, S. Bikbulatov, B. G. Madyarov, M. N. Miftakhov, A. G. Mustafin, G. S. Usmanov, G. Shaikhulov; in the territory of Yugoslavia: G. G. Malov (brigade commissar), in Poland: M. S. Atamanov (nicknamed Mishka Tatar).

Participating in the organisation of resistance in German concentration camps were A. Adnashev, A. Alish, A. Battalov, N. Dauli, M. Jalil, G. Nurdinov, A. Simayev, M. Khairutdinov, and so on; in the French Resistance: R. Bokov, M. F. Gaisin, V. P. Ignatyev, Z. K. Kamalov, R. N. Rylova, A. G. Utyashev, Z. Shamigulov, and so on.

Bravery, heroism, and martial prowess of warriors from Tatarstan inscribed their names to the annals of the Great Victory over the Fascist Germany and its satellites and helped save the world from the fascist plague.



Х. Г. Якупов. Полкташым пулемётчы Мария Щербак. 2000

Х. А. Якупов. Моя однополчанка пулемётчица Мария Щербак. 2000

K. A. Yakupov. My regimental comrade machine gunner Mariya Shcherbak. 2000

## Тылдагы хезмәт батырлыклары

Ирләрнең күбесен массакүләм рәвештә фронтка мобилизацияләү сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында һәм транспортта кадрлар проблемасын кискенләштерә. Аны хәл итү максаты белән кайбер кичектергесез чаралар кабул ителә: җиде көнлек эш атнасы гамәлгә кертелә, яллар бетерелә, хезмәт йөкләмәсе кертелә, соңгысы тиздән хезмәт мобилизациясе белән алмаштырыла, эшкә соңга калу яки аны үз иркең белән калдырып китү өчен җинаять җәзасы карала. Моннан тыш, республика халкы мәҗбүри тәртиптә урман әзерләү, төзелеш мәйданнарын чистарту, Казан – Бөгелмә тимер юлын төзү һ. б. эшләргә җәлеп ителә. 1941 елның октябреннән 1942 елның февраленә кадәр барлыгы 110 мең кеше республика территориясендәге оборона ныгытмалары – озынлыгы 331 км тәшкил иткән Казан киртәсе – төзелешендә катнаша. Биредә бер кешегә көнлек норма 2 кубометрны тәшкил итә. Начар матди-көнкүреш шартлары, туңу-өшү һәм инфекцияләр аркасында, мобилизацияләнгәннәр арасында бик күпләр авырый һәм үлә, кайберләре алынган авырулары нәтиҗәсендә соңрак вафат була.

Предприятиеләрдә социалистик ярышның төрле формалары, берьюлы берничә станокта эшләүчеләр, рационализаторлар, уйлап табучылар хәрәкәтләре киң тарала. Икейөзчеләр хәрәкәтен башлап җибәрүче, Казанның «Спартак» комбинаты күн кисүчесе Н. Хәбибуллина, «Татарстанның 20 еллыгы» исемендәге артель өчйөзчеләре М. Романова белән А. Булаева, «Светоч» кондитер фабрикасы бишйөзчесе М. Йосыпова, машина төзелеше заводлары цехларында хезмәт куйган меңчеләр Ф. Габдрахманова, С. Һидиятуллина, А. Бирюкова исемнәре бөтен республикага билгеле була. Сугыш ахырына республика заводларында һәм фабрикаларында якынча 50 мең стахановчы исәпләнә.

## Трудовые подвиги в тылу

Массовая мобилизация значительной части мужского населения на фронт резко обострила кадровую проблему в промышленности, сельском хозяйстве, транспорте. С целью её решения был предпринят ряд неотложных мер: введена семидневная рабочая неделя, отменены отпуска, введена трудовая повинность, которая вскоре была заменена на трудовую мобилизацию с последствиями в виде уголовного наказания за опоздание на работу или самовольное её оставление. Кроме того, население республики в принудительном порядке привлекалось на лесозаготовки, расчистку территорий под строительные площадки, строительство железной дороги Казань – Бугульма и другие работы. Свыше 110 тыс. человек с октября 1941 г. по февраль 1942 г. принимали участие в строительстве оборонительных рубежей на территории республики – Казанского обвода, протяжённость которого составляла 331 км. Дневная норма на человека составляла 2 кубометра. Из-за плохих материально-бытовых условий, переохлаждения и инфекций среди мобилизованных многие болели и умирали, некоторые скончались позднее вследствие полученных болезней.

На предприятиях широкое распространение получили различные формы социалистического соревнования, движения многостаночников, рационализаторов, изобретателей. Всей республике были известны имена зачинательницы движения двухсотников – закройщицы юфти Казанского комбината «Спартак» Н. Хабибуллиной, трёхсотниц артели имени «20-летия Татарии» М. Романовой и А. Булаевой, пятисотницы кондитерской фабрики «Светоч» М. Юсуповой, тысячников Ф. Абдрахманова, С. Хидиятуллина, А. Бирюкова, трудившихся в цехах машиностроительных заводов. К концу войны на заводах и фабриках республики насчитывалось около 50 тыс. стахановцев.

## Labour Feats in the Home Front

The mass mobilisation of a considerable part of male population to the front aggravated the personnel problem in industry, agriculture, and in transport. To solve this problem, a number of urgent measures were taken: the seven-day working week was introduced, vacations were abolished, labour conscription was introduced, which was soon substituted by labour mobilisation with consequences in the form of punishment under criminal law for being late for work or for voluntary leaving the workplace. In addition to that, the population of the republic was forcedly involved in wood harvesting, clearing of territories for construction sites, construction of the Kazan – Bugulma railroad, and in doing other types of works. In the period from October 1941 to February 1942, over 110 000 people took part in the construction of defensive belts in the territory of the republic – the so-called Kazan perimeter, which extended for 331 km. The daily work quota per one person was 2 cubic metres. Many of the mobilised people got ill or died because of bad material and living conditions, hypothermia and infections, some died later because of acquired diseases.

Widely spread at enterprises became various forms of Socialist competitions, movements of workers operating a number of machines simultaneously, of innovators, and inventors. Known to the entire republic were the names of N. Khabibullina, the initiator of the movement of two-hundred per cent performers, the yuft cutter of "Spartak", the Kazan Footwear Combine, of M. Romanova and A. Bulayeva, the initiators of the movement of three-hundred per cent performers, who worked at an artel named after the 20th Anniversary of Tataria, of M. Yusupova, the initiator of the movement of five-hundred per cent performers from "Svetoch" Confectionary Factory, as well as the names of F. Abdrakhmanov, S. Khidiyatullin, and A. Biryukov, the initiators of the movement of thousand per cent performers, who worked in the workshops of mechanical engineering plants. By the end of the war, working at the plants and factories of the republic were some 50 000 Stakhanov's followers.



Нократта сал агызу

Сплавка леса на Вятке

Floating of timber on the Vyatka



Ваня Чередилин – 6 ай эчендә тимерче белгечлеген үзләштергән 12 яшьлек үсмер

Ваня Чередилин – 12-летний подросток, за 6 месяцев освоивший специальность токаря


Vanya Cheredilin, a 12-year-old boy who mastered the profession of a turner in 6 months



Е. Н. Евстафьева, «Спартак» күн аяк киемнәре тегү цехы стахановчысы

Е. Н. Евстафьева, стахановка цеха пошива кожно-обувного комбината «Спартак»

Y. N. Yevstafyeva, Stakhanov's follower from the sewing shop of "Spartak" Leather Footwear Combine



Станок артында. 1940 еллар

За станком. 1940-е

At the machine tool. 1940s

ТЭ-22 тахометры приборын җыю күренеше.1942

Общий вид сборки прибора тахометра ТЭ-22 на конвейере. 1942

General view of the assembly of TE-22 tachometer on the conveyor. 1942



Фронт яшьләр звеносы комсомолы Балдин норманы 310 % ка үти. 1940 еллар

Комсомолец фронтового молодёжного звена Балдин выполнил норму на 310 %. 1940-е

Komsomol member of the frontline youth team Baldin fulfilled his norm by 310 %. 1940s




Горбунов исем. Казан авиация-житештерү берләшмәсе. 1940 еллар

КАПО им. Горбунова. 1940-е

Kazan Aircraft Building Association n. a. Gorbunov. 1940s






Норманы 250 % ка үтәүче фронт комсомол яшьләре бригадасы комсомолы станок янында. 1940 еллар

За станком комсомолец фронтовой комсомольско-молодёжной бригады, выполняющий норму на 250 %. 1940-е

Komsomol member of the frontline youth team at the machine tool fulfilling his norm by 250 %. 1940s

Пе-2 очкычын төзәтү

Ремонт самолёта Пе-2

Repair of Pe-2 plane





Пе-2 очкычы фюзеляжлары линиясе. 22 нче завод. 1940 еллар

Поточная линия фюзеляжей самолёта Пе-2. Завод № 22. 1940-е

Production line for assembly of bodies of Pe-2 planes. Plant No 22. 1940s



А. Е. Арбузов, химик-органик, химик-фосфорорганиклар фәнни мәктәбенә нигез салучы

А. Е. Арбузов, химик-органик, основатель научной школы химиков-фосфороргаников

A. Y. Arbuzov, organic chemist, founder of scientific school of organophosphorus chemists



А. В. Вишневский, хирург, Казан һәм Мәскәү хирургия мәктәпләренә нигез салучы

А. В. Вишневский, хирург, основатель казанской и московской хирургических школ

A. V. Vishnevsky, surgeon, founder of the Kazan and Moscow surgical schools

## Фән – фронтка

Сугыш елларында Татарстан СССРдагы әйдәп баручы фәнни-тикшеренү үзәкләренең берсенә әверелә. СССР ФА фәнни көчләренең өчтән бер өлеше (1 884 фәнни хезмәткәр) аның Президиумы җитәкчелегендә Казанда урнаша. Республиканың югары фәнни потенциалы эвакуацияләнгән галимнәргә иң кыска вакыт арасында фундаменталь һәм фәнни-гамәли тикшеренүләрен башларга мөмкинлек бирә. Казанда хәрби техниканың, коралларның, шул исәптән атом-төш коралының өр-яңа системалары (И. В. Курчатов, А. П. Александров һ. б.), хәрби очкычларның һәм реактив двигательләрнең яңа типлары (В. П. Глушко, С. П. Королёв, В. М. Петляков, А. Н. Туполев һ. б.) эшләнә.

Татарстан галимнәре А. Е. Арбузов оптик приборлар җитештерү өчен мөһим роль уйный торган матдәләр табу; Б. А. Арбузов синтетик каучукның салкынга чыдамлыгын арттыру; Н. А. Ливанов ризык аксымы һәм витаминнар җитештерү технологиясе; С. Н. Ушаков оборона сәнәгате өчен яңа төр пластмассалар ясау; Г. Х. Камай кетгутның яңа төрләрен булдыру юнәлешләрендә эшлиләр.

А. В. Вишневский, В. А. Гусынин, Б. Л. Мазур, А. Н. Мурзин, И. И. Русецкий, Н. В. Соколов, Л. И. Шулутко һ. б. тикшеренүләре яралыларны нәтиҗәле дәвалауны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

1944 елда Е. К. Завойский тарафыннан Казан университетында дөньякүләм әһәмияткә ия фәнни ачыш ясала – электрон парамагнит резонансы күренеше ачыла.

Галимнәренең Ватанны саклауга керткән хезмәтен тану буларак 1945 елның апрелендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы төзелә.

## Наука фронту

В годы войны Татарстан превратился в один из ведущих научно-исследовательских центров СССР. В Казани разместилась третья часть научных сил АН СССР во главе с её Президиумом (1 884 научных сотрудника). Высокий научный потенциал республики позволил эвакуированным учёным в самые сжатые сроки начать фундаментальные и прикладные научные исследования. В Казани разрабатывались новейшие системы военной техники, оружия и вооружения, в том числе ядерного (И. В. Курчатов, А. П. Александров и др.), новые типы военных самолётов и реактивных двигателей (В. П. Глушко, С. П. Королёв, В. М. Петляков, А. Н. Туполев и др.).

А. Е. Арбузов получил вещества, имевшие важное значение для производства оптических приборов; Б. А. Арбузов работал над повышением морозостойкости синтетического каучука; Н. А. Ливанов – над технологией производства пищевых белков и витаминов; С. Н. Ушаков – новых видов пластмасс для оборонной промышленности; Г. Х. Камай – новых видов кетгута.

Изыскания А. В. Вишневского, В. А. Гусынина, Б. Л. Мазура, А. Н. Мурзина, И. И. Русецкого, Н. В. Соколова, Л. И. Шулутко и др. позволили обеспечить эффективное лечение раненых.

В 1944 г. Е. К. Завойским в стенах Казанского университета было сделано научное открытие мирового значения – явление электронного парамагнитного резонанса.

Признанием вклада учёных в дело защиты Родины стало создание в апреле 1945 г. Казанского филиала Академии наук СССР.

## Science to the Front

Over the years of war Tatarstan turned into one of the leading research and development centres of the USSR. One third of scientific forces of the Academy of Sciences of the USSR led by its Presidium (1 884 scientific workers) were accommodated in Kazan. The high scientific potential of the republic made it possible for the evacuated scientists to commence the fundamental and applied scientific research work within the shortest time possible. It was in Kazan, where they were developing the newest systems of military machines, weapons, and ammunition, including the nuclear ones (I. V. Kurchatov, A. P. Alexandrov, and so on), the new types of war planes and jet engines (V. P. Glushko, S. P. Korolev, V. M. Petlyakov, A. N. Tupolev, and so on).

Also important was the contribution made by scientists of Tatarstan: A. Y. Arbuzov developed the substances that played a significant role for the production of optical instruments; B. A. Arbuzov was working for increasing the frost resistance of synthetic rubber; N. A. Livanov developed the technology for production of food protein and vitamins; S. N. Ushakov developed new types of plastics for defence industry; G. K. Kamay developed the new types of catgut.

The research carried out by A. V. Vishnevsky, V. A. Gusynin, B. L. Mazur, A. N. Murzin, I. I. Rusetsky, N. V. Sokolov, L. I. Shulutko, and other scientists helped ensure the efficient treatment of the wounded.

In 1944, Y. K. Zavoisky, while working at Kazan University, made a discovery of global scale: he discovered the phenomenon of electron paramagnetic resonance.

The opening of the Kazan Branch of the Academy of Sciences of the USSR in April of 1945 became a sign of recognition of the contribution made by scientists to defence of their Motherland.



Г. Х. Камай, химия буенча беренче татар профессоры

Г. Х. Камай, первый из татар профессор-химик

G. K. Kamay, the first Tatar professor in chemistry



С. П. Королёв, ракета төзелеше, космонавтика өлкәсе галиме һәм конструкторы, гамәли космонавтикага нигез салучы һәм оештыручы

С. П. Королёв, учёный и конструктор в области ракетостроения и космонавтики, организатор и основоположник практической космонавтики

S. P. Korolev, scientist and designer in the field of rocket science and cosmonautics, organiser and founder of practical cosmonautics



Е. К. Завойский, физик, физика-математика фәннәре докторы

Е. К. Завойский, физик, доктор физико-математических наук

Y. K. Zavoisky, physicist, Doctor of Physical and Mathematical Sciences

## Мәдәният – фронтка

Дошманны тар-мар итүгә халыкны мобилизацияләүдә һәм каһарман образларын тудыруда иҗат интеллигенциясе вәкилләре әһәмиятле роль уйный. Фронттагы һәм тылдагы кешеләрнең батырлыгы Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Ә. Еники һ. б. ның әсәрләрендә чагылыш таба. Иҗат интеллигенциясенең күп вәкилләре, кулларына корал алып, Ватан бәйсезлеге өчен көрәшә: ТАССР Язучылар берлегенең 53 әгъзасыннан 25 е сугышның беренче елында ук фронтка китә. Г. Әпсәләмов, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, М. Максуд, Ә. Фәйзи, А. Шамов һ. б. фронт газеталары чыгаруда хезмәт итә. Татарстанның 30 язучысы Җиңү өчен башларын сала.

Республика композиторлары сугыш елларында 108 әсәр яза, шуларның 72 се хәрби тематиканы чагылдыра. С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарёв, З. Хәбибуллин музыкасы дошманга каршы көрәшкә чакыра. Н. Җиһановның «Илдар», М. Юдинның «Фәридә» опералары сугыш темасына язылган.

Рәссамнар Г. В. Житков, Г. П. Катков, И. И. Князьков, И. А. Новосёлов һ. б. картиналары каһарманлык-патриотлык рухы белән сугарылган була. ТАССР Рәссамнар берлегенең 46 әгъзасыннан 22 се фронтка китә, аларның 14 е һәлак була.

Театрлар репертуарында сугыш турындагы пьесалар барлыкка килә: К. Симоновның «Рус кешеләре», А. Корнейчукның «Фронт», Н. Исәнбәтнең «Мәрьям», Р. Ишморатның «Кайту», М. Әмирнең «Миңлекамал» һ. б. әсәрләр. Сугыш елларында оештырылган 18 махсус концерт һәм театр бригадасы, 11 фронтка барып, сугышчылар өчен 2 меңгә якын концерт һәм спектакль күрсәтә.

## Культура фронту

Важную роль в мобилизации населения на разгром врага и формировании образов героев сыграла творческая интеллигенция. Героизм людей на фронте и в тылу получил отражение в произведениях А. Абсалямова, Г. Баширова, А. Еники и др. Многие представители творческой интеллигенции с оружием в руках отстаивали независимость Родины: 25 из 53 членов Союза писателей ТАССР в первый год войны ушли на фронт. В издательствах фронтовых газет служили А. Абсалямов, А. Ерикей, Р. Ишмурат, Ф. Карим, А. Кутуй, М. Максуд, А. Файзи, А. Шамов и др. 30 писателей Татарстана отдали свою жизнь за Победу.

Композиторы республики за годы войны написали 108 произведений, 72 из которых отражали военную тематику. Музыка С. Сайдашева, Н. Жиганова, М. Музафарова, А. Ключарёва, З. Хабибуллина призывала к борьбе с врагом. На тему войны были написаны оперы «Ильдар» Н. Жиганова, «Фарида» М. Юдина.

Героико-патриотическим духом были проникнуты картины художников Г. В. Житкова, Г. П. Каткова, И. И. Князькова, И. А. Новосёлова, и др. Из 46 членов Союза художников ТАССР 22 ушли на фронт, 14 из них погибли.

В репертуаре театров появились пьесы о войне: «Русские люди» К. Симонова, «Фронт» А. Корнейчука, «Марьям» Н. Исанбета, «Возвращение» Р. Ишмурата, «Минникамал» М. Амира и др. 18 фронтовых концертных и театральных бригад, сформированные в годы войны, побывали на 11 фронтах, организовали около 2 тыс. концертов и спектаклей.

## Culture to the Front

An important role in mobilisation of the population for the destruction of the enemy and in the formation of images of heroes was played by creative intelligentsia. Heroism of people on the front and in the rear of the country was reflected in the works created by A. A. Absalyamov, G. Bashirov, A. Yeniki, and so on. Many representatives of creative intelligentsia fought for the independence of their Motherland with weapons in their hands: 25 out of 53 members of the Union of Writers of the TASSR went to the front during the first year of the war. Working at publishing offices of the frontline newspapers were A. Absalyamov, A. Yerikey, R. Ishmurat, F. Karim, A. Kutuy, M. Maksud, A. Faizi, A. Shamov, and so on. Thirty writers of Tatarstan sacrificed their lives for the Victory.

Over the period of war, the composers of the republic created 108 musical works, 72 of which were dedicated to military theme. The music created by S. Saidashev, N. Zhiganov, M. Muzafarov, A. Klyucharev, Z. Khabibullin was calling for fighting the enemy. The theme of war was central in such operas as “Ildar” by N. Zhiganov and “Farida” by M. Yudin.

The heroic and patriotic spirit permeated the paintings crated by such artists as G. V. Zhitkov, G. P. Katkov, I. I. Knyazkov, I. A. Novoselov, and so on. Of 46 members of the Union of Artists of the TASSR 22 went to the front, and 14 of them were killed.

The repertoire of the theatres were supplemented by plays dedicated to war: “Russian people” by K. Simonov, “The Front” by A. Korneychuck, “Maryam” by N. Isanbet, “The Return” by R. Ishmurat, “Minnikamal” by M. Amir, and so on. Formed during the years of war, 18 frontline concert and theatre brigades visited 11 fronts and gave some 2 000 concerts and performances.



Фронт бригадасы. Уртада – Л. Латыйпова (торбада уйнаучы), артта (уңнан икенче) – Җ. Сәлахова. 1943

Фронтовая бригада. В середине – Л. Латыпова (трубач), сзади справа вторая Дж. Саляхова. 1943

Frontline brigade. In the middle: L. Latypova (trumpet-player), second right behind: J. Salyakhova. 1943



Казан артистлары фронтта. 1942

Казанские артисты на фронте. 1942

The Kazan artists at the front. 1942



Чистай, Ленин ур., 81. 1941 – 1943 елларда биредә шагыйрь Б. Л. Пастернак яши

Чистополь, ул. Ленина, 81. В 1941 – 1943 гг. здесь жил поэт Б. Л. Пастернак


81, Lenin Street, Chistopol. Poet B. L. Pasternak lived here in 1941 – 1943



Н. Н. Асеев, И. Л. Сельвинский, Б. Л. Пастернак. Чистай. 1942

Н. Н. Асеев, И. Л. Сельвинский, Б. Л. Пастернак. Чистополь. 1942

N. N. Aseyev, I. L. Selvinsky, B. L. Pasternak. Chistopol. 1942



К. Г. Паустовский, прозаик, СССР Язучылар берлеге әгъзасы

К. Г. Паустовский, прозаик, член Союза писателей СССР

K. G. Paustovsky, prose writer, member of the Union of Writers of the USSR

1941 елның июль–октябрь айларында Чистай шәһәренә Мәскәүдән, Ленинградтан һәм башка шәһәрләрдән 200 дән артык язучы, әдәби һәм театр тәнкыйтьчесе, рәссамнар, артистлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан якынча 2 мең кеше эвакуацияләнә: Н. Асеев, А. Ахматова, Д. Бедный, Е. Долматовский, М. Исаковский, Л. Леонов,

В июле – октябре 1941 г. в г. Чистополь из Москвы, Ленинграда, других городов и районов было эвакуировано более 200 писателей, литературных и театральных критиков, художников, артистов и около 2 тыс. членов их семей: Н. Асеев, А. Ахматова, Д. Бедный, Е. Долматовский,

Over the period from July to October 1941, evacuated to Chistopol from Moscow, Leningrad and other regions were over 200 writers, literary and theatre critics, artists, and actors and some 2 000 members of their families: N. Aseyev, A. Akhmatova, D. Bedny, Y. Dolmatovsky, M. Isakovsky, L. Leonov,



Л. М. Леонов, прозаик

Л. М. Леонов, прозаик

L. M. Leonov, prose writer



М. В. Исаковский, шагыйрь, мемуарчы, әдәби тәнкыйтьче

М. В. Исаковский, поэт, мемуарист, литературный критик

M. V. Isakovsky, poet, writer of memoirs, literary critic



М. С. Петровых, шагыйрь, тәрҗемәче

М. С. Петровых, поэт, переводчик

M. S. Petrovykh, poet, translator



А. А. Тарковский, шагыйрь, тәрҗемәче

А. А. Тарковский, поэт, переводчик

A. A. Tarkovsky, poet, translator



Кулына бакырдан коелган Гитлер башын тоткан шагыйрь Е. А. Долматовский рейхстаг янәшәсендә. 1945 елның 2 мае

Поэт Е. А. Долматовский у рейхстага с бронзовой головой Гитлера в руках. 2 мая 1945

Poet Y. A. Dolmatovsky by the Reichstag with the bonze head of Hitler in his hands. 2 May 1945

А. А. Сурков, шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе. 1940 еллар

А. А. Сурков, поэт, журналист, общественный деятель. 1940-е

A. A. Surkov, poet, journalist, public figure. 1940s





А. А. Ахматова, шагыйрә

А. А. Ахматова, поэтесса

A. A. Akhmatova, poetess



М. И. Цветаева, шагыйрә, прозаик, драматург

М. И. Цветаева, поэтесса, прозаик, драматург

M. I. Tsvetayeva, poetess, prose writer, playwright



Прозаик, тәнкыйтьче, әдәбият теоретигы А. А. Фадеев гаиләсе белән. 1949

Прозаик, критик, теоретик литературы А. А. Фадеев с семьёй. 1949

A. A. Fadeyev, prose writer, critic, theoretician of literature, with his family. 1949

С. Маршак, Б. Пастернак, К. Паустовский, М. Петровых, А. Сурков, А. Тарковский, К. Тренёв, А. Фадеев, К. Федин, М. Цветаева һ. б. үзләре һәм аларның гаиләләре. А. Твардовский фронттан ике тапкыр – 1941 елның кышында һәм 1943 елның язында – Чистайдагы гаиләсе янына кайтып, монда да үзенең «Василий Тёркин» поэмасы өстендә эшләвен дәвам итә. Б. Пастернак эвакуациядә күбрәк тәрҗемәчелек белән шөгыльләнә – У. Шекспирның «Антоний һәм Клеопатра», «Ромео һәм Джульетта» драмаларын тәрҗемә итә, шигырьләр яза, соңгылары һәм «Марина Цветаева истәлегенә» шигыре аның «На ранних поездах» җыентыгына кертелә. «Доктор Живаго» романын язу фикере дә анда Чистайда туа (шушы романы өчен ул соңыннан Нобель премиясе ала). А. Тарковский 7 шигырьдән торган «Чистай дәфтәре» циклын иҗат итә. М. Исаковский берничә дистә шигырь яза, аларның күбесе музыкага салына һәм җырлар булараk киң танылу ала: «Ой, туманы мои», «В лесу прифронтовом», «Огонёк», «Здесь похоронен красноармеец» һ. б.

М. Исаковский, Л. Леонов, С. Маршак, Б. Пастернак, К. Паустовский, М. Петровых, А. Сурков, А. Тарковский, К. Тренёв, А. Фадеев, К. Федин, М. Цветаева и др.; А. Твардовский дважды приезжал с фронта в Чистополь к семье – зимой 1941-го и весной 1943 г., где продолжал работать над поэмой «Василий Тёркин». Б. Пастернак в эвакуации занимался главным образом переводческой деятельностью – перевёл драмы В. Шекспира «Антоний и Клеопатра», «Ромео и Джульетта», написал стихотворения, которые вошли в сборник «На ранних поездах», в том числе «Памяти Марины Цветаевой». В Чистополе он задумал роман «Доктор Живаго» (за который впоследствии получил Нобелевскую премию). А. Тарковский создал цикл «Чистопольская тетрадь», состоявший из 7 стихотворений. М. Исаковский написал несколько десятков стихотворений, многие из которых были переложены на музыку и стали известными песнями: «Ой, туманы мои», «В лесу прифронтовом», «Огонёк», «Здесь похоронен красноармеец» и др.

S. Marshak, B. Pasternak, K. Paustovsky, M. Petrovykh, A. Surkov, A. Tarkovsky, K. Trenev, A. Fadeyev, K. Fedin, M. Tsvetayeva, and so on; A. Tvardovsky came from the frontline two times to visit his family in Chistopol – in winter of 1941 and in spring of 1943. While in Chistopol, he continued the work on his poem "Vasili Tyorkin". While in evacuation, B. Pasternak was mainly occupied with the translation work: he translated the tragedies by W. Shakespeare "Antony and Cleopatra", "Romeo and Juliet", but also wrote the verses which were included to the collection titled "On Early Trains", including the verse "In Memory of Marina Tsvetayeva". It was in Chistopol where he conceived his novel "Doctor Zhivago" (for which he would later be awarded the Nobel Prize). A. Tarkovsky created a cycle titled "The Chistopol Notebook", which included 7 verses. M. Isakovsky wrote several tens of verses, many of which were put to music and became the well-known songs: "Oh, My Fogs", "In the Frontier Forest", "The Little Flame", "A Red Army Man is Buried Here", and so on.



## Иҗтимагый-сәяси тормыш

Сугышның башлангыч чорында иҗтимагый һәм дини тормышта булган сәяси диктат берникадәр йомшара, халыкларның героик эпосларын, элекке ватан сугышларының һәм халык күтәрелешләренең тарихын өйрәнү бик хуплана. Татар иҗат интеллигенциясе вәкилләре, героик-романтик мотивлар эзләп, урта гасыр төрки-татар тарихына мөрәҗәгать итәләр. Анда исә Алтын Урданы саклап калу һәм берләштерү өчен батырларча көрәшкән иң күренекле каһарман Идегәй әмир була. Әсәрнең тематикасы һәм идеясе шул көннәр вазгыятенә аеруча төгәл туры килә, илен саклап калу һәм үзенең киләчәге өчен көрәш алып баручы совет халкының психологик халәте белән тәңгәллектә, уртак яңгырашта тора. Моннан тыш, татар язучыларының һәм тарихчыларының иҗади эзләнүләре, асылда, башка халыклар тарихы контекстында татар халкының объектив тарихын язу зарурлыгына китерә.

Сугыш вакытында хакимиятнең дини оешмаларга мөнәсәбәте күпкә түземлерәк һәм лояльрәк була: 1944 – 1948 елларда Татарстанда 20 мәчет, 18 православие общинасы, 2 иске православие, яһүд дине, тагын 2 протестант общинасы үз эшчәнлеген яңарта. Бер үк вакытта урыннарда руханиларның эше легальләштерелә, чөнки эшләренең төп эчтәлеге булып тол хатыннарга һәм сугыш ятимнәренә – сугыш корбаннарына рухи ярдәм, басып алучыларның чын йөзен ача, сугышчыларның батырлык һәм кыюлыкларын данлый, совет җитәкчеләренең зирәклеген мактый торган вәгазь-нәсыйхәтләр, шулай ук төрле фондларга акча җыюда катнашу тора.

Сугышның беренче елларында үзләренең «бизәлмәгән, матурланмаган» милли тарихларын язу омтылышларына карата ста-

## Общественно-политическая жизнь

В начальный период войны произошло некоторое ослабление политического диктата в сфере общественной и религиозной жизни, начало широко поощряться изучение героического эпоса народов, истории прошедших отечественных войн и восстаний. Представители татарской творческой интеллигенции в поисках героико-романтических мотивов обратились к средневековой тюрко-татарской истории, в которой ярчайшим героем был эмир Идегей, героически боровшийся с внутренними и внешними врагами за сохранение и объединение Золотой Орды. Тематика и идея произведения наиболее точно соответствовали ситуации, создавая параллели и созвучия с психологическим состоянием советского народа, ведущего борьбу за сохранение страны и своего будущего. Кроме того, творческие поиски и находки татарских писателей и историков, по сути, вплотную привели к необходимости написания объективной истории татарского народа в контексте истории других народов.

Во время войны отношение властей к религиозным организациям также стало более терпимым и лояльным: в 1944 – 1948 гг. в Татарстане возобновили работу 20 мечетей, 18 православных общин, 2 старообрядческие, иудейская и 2 протестантские общины. Одновременно на местах легализовалась деятельность священнослужителей, основным содержанием которой стали моральная поддержка вдов и сирот – жертв войны, обличающие врагов-оккупантов проповеди и благостные проповеди по возвеличению героизма и доблести воинов, восхвалению мудрости советских руководителей, а также участие в сборе средств в различные фонды.

## Social and Political Life

During the initial period of the war there took place a certain easement of political dictate in the field of social and religious life. Broadly supported was the study of the heroic eposes of peoples, of history of the past patriotic wars and revolts. While seeking the heroic-romantic motifs, the representatives of the Tatar creative intelligentsia reverted to the mediaeval Turkic-Tatar history, in which Emir Idegey was the brightest figure. He heroically fought the domestic and external enemies for the preservation and unification of the Golden Horde. The theme and the idea of the work best corresponded to the situation, creating the parallels and consonants with the psychological state of the Soviet people that was fighting for the preservation of the country and for its future. Besides, the creative searches and findings of the Tatar writers and historians have, actually, led them very close to necessity of writing an objective history of the Tatar people in the context of history of the other peoples.

During the war, the attitude towards religious organisations on the part of authorities also became more tolerant and loyal: in 1944 – 1948, 20 mosques resumed their work in Tatarstan, as well as 18 Orthodox communities, 2 Old Believers, 1 Judaic, and 2 Protestant communities. At the same time, the work of clergymen was legalised at the local level, their major function being the provision of moral support to widows and orphans as victims of the war, delivering sermons, which were either convicting the enemies/invaders or praising the heroism and prowess of warriors and wisdom of the Soviet leaders, and participation in the collection of funds to various foundations.

The tolerance of the Stalin's leadership to the attempts of writing the "unretouched" ethnic history during the first years of the war turned, at its final stage, into deportation of a number of Muslim Turkic peoples of the North Caucasus

линчыл җитәкчелекнең сабырлык күрсәтүе аның йомгаклау этабында Төньяк Кавказ һәм Кырымның кайбер мөселман төрки халыкларын депортацияләү белән тәгәлләнә. Сугыш бетәргә бер ел кала, Татарстан АССР сәяси җитәкчелегенә дә идеологик басым көчәя. 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитетының «Татарстан партия оешмасында массакүләм-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» дигән махсус карары кабул ителә. Анда татар интеллектуаль иҗади элитасы Урта гасырның патриархаль феодаль нигезләрен мактауда һәм Алтын Урда вәкиле Идегәйне каһарман сыйфатында данлауда гаепләнә. Әлеге карар татар тарихы фәненә, әдәбиятына һәм драматургиясенә бик зур зыян китерә.

## Көтеп алынган Җиңү

1945 елның 9 мае Советлар Союзы халыкларының фашизмны бөек Җиңүе тарихында иң югары нокта була. Сугыш тәмамлану һәм дошманны Җиңү турындагы хәбәр килеп җитә. Меңләгән татарстанлы сугышның дүрт гаять авыр елы буена көткән сүзләрне Юрий Левитаннан үз колаклары белән ишетү өчен шәһәр һәм авыл урамнарына чыга. Сугыш бетү яшәү өчен авыр көрәшнең ахырын гына түгел, фронтларда исән-имин калганнарның тиздән өйләренә кайтачагын да аңлата. Күпләр үзләренең туганнарын, якыннарын һәм дусларын көтеп ала алмасалар да, бу көн татарстанлылар хәтерендә гомерләренең иң якты һәм дулкынландыргыч мизгеле булып мәңгегә кала.

Терпимость сталинского руководства к попыткам написания своей «неретушированной» национальной истории в первые годы войны обернулась на её завершающем этапе депортацией ряда мусульманских тюркских народов Северного Кавказа и Крыма. В предпоследний год войны усилилось идеологическое давление и на политическое руководство Татарской АССР. 9 августа 1944 г. было принято специальное Постановление ЦК ВКП(б) «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы Татарской партийной организации», в котором татарская интеллектуальная и творческая элита обвинялась в воспевании средневековых патриархальных феодальных устоев и в прославлении в качестве героя Идегея – представителя Золотой Орды. Постановление нанесло огромный вред татарской историографии, литературе и драматургии.

## Долгожданная Победа

9 мая 1945 г. стало кульминационным моментом в истории великой Победы народов Советского Союза над фашизмом. Услышав весть об окончании войны и Победе над врагом, тысячи татарстанцев вышли на улицы городов и деревень, чтобы лично услышать слова Юрия Левитана, которых они ждали четыре страшных военных года. Окончание войны означало не только конец тяжёлой борьбы за выживание, но и то, что вскоре вернутся домой те, кто уцелел в этой страшной битве. И хотя многие так и не дождались своих родных, близких и друзей, этот день навсегда остался в памяти татарстанцев как самый светлый и трогательный момент в их жизни.

and the Crimea. During the next-to-last year of the war, also stronger became the ideological pressure on the leadership of the Tatar ASSR. On 9 August 1944, a special resolution of the central Committee of VCP(b) was adopted “On the State and Measures for Improvement of Mass-Political and Ideological Work at the Tatar Party Organisation”, in which the Tatar intellectual creative elite was accused of glorifying the mediaeval patriarchal feudal principles and of glorifying Idegey as a hero, who was a representative of the Golden Horde. The Resolution inflicted a huge harm to the Tatar historiography, literature, and dramaturgy.

## The Long-awaited Victory

The day of the 9th of May of 1945 became the culmination point in the history of the great Victory of peoples of the Soviet Union over fascism. Having heard the news on the end of war and Victory over the enemy, thousands of citizens of Tatarstan went out into the streets of towns and villages to personally listen to the words read by Yury Levitan, which they all waited for four scary years of the war. The end of war meant not only that the heavy struggle for survival has come to an end, but also that those who survived in the fierce battles would soon return home. Even though many lost their relatives, close ones, and friends, that day will always be remembered by citizens of Tatarstan as the brightest and touching moment of their lives.




Казанда Җиңү көне

День Победы в Казани

Victory Day in Kazan



Казанда Җиңү көне. Бауман урамы

День Победы в Казани. Улица Баумана

Victory Day in Kazan. Bauman Street

# СУГЫШТАН СОҢГЫ ТЕРНӘКЛӘНҮ ЧОРЫ (1945 – 1953)

# ПЕРИОД ПОСЛЕВОЕННОГО ВОССТАНОВЛЕНИЯ (1945 – 1953)

# PERIOD OF POST-WAR RECOVERY (1945 – 1953)







## Тыныч тормышка күчү авырлыклары


Татарстан икътисадын торгызу авыр шартларда бара. Республика сугыш елларында матди һәм хезмәт ресурсларының шактый өлешен югалта. Оборона сәнәгатенә карамаган күп предприятиеләр, сәүдә учреждениеләре, күмәк хуҗалыклар һәм совхозлар таркалыш хәлендә була. Татарстанның сугыштагы югалтулары 350 мең кешене тәшкил итә, республиканың күп гражданнары фронттан авыр яраланып һәм гарипләнеп кайта (50 меңгә якын кеше). Тылда да югалтулар зур була. Татарстанның сугышка кадәрге халык саны 1960 еллар башында гына элеккеге санына җитә. Меңләгән татарстанлы үзләренең якыннарын югалта, тол һәм ятим кала. Сугыш нәтиҗәләре республика икътисады өчен һәлакәтле була: ул 30 процентка якын берләштерелгән милли керемен югалта.

## Трудности перехода к мирной жизни

Восстановление экономики Татарстана проходило в сложных условиях. Республика в годы войны потеряла значительные материальные и трудовые ресурсы. Многие промышленные предприятия необоронного значения, торговые учреждения, колхозы и совхозы находились в состоянии упадка. Военные потери Татарстана составили более 350 тыс. человек, многие граждане республики вернулись с фронта с тяжёлыми увечьями (около 50 тыс. человек). Были большие людские потери и в тылу. Довоенная численность населения Татарстана восстановилась только к началу 1960-х гг. Тысячи татарстанцев потеряли своих близких, остались вдовами и сиротами. Последствия войны для экономики республики были катастрофическими: она потеряла около 30 % совокупного национального дохода.

## Difficulties of Transfer to Peaceful Life

The recovery of the economy of Tatarstan was taking place under difficult conditions. During the years of war, the republic lost considerable material and labour resources. Many non-defensive industrial enterprises, commercial institutions, collective and Soviet farms were in the state of recession. The military losses of Tatarstan totalled over 350 000 people; many citizens of the republic returned from the front with dreadful injuries (nearly 50 000 people). The large human losses were also recorded in the home front. Tatarstan managed to restore the pre-war numbers of people living in Tatarstan as late as in the early 1960s. Thousands of citizens of Tatarstan lost their relatives, husbands, and parents. The consequences of the war for the economy of the republic were catastrophic: it lost some 30% of the gross national income.



Бөек Ватан сугышының аяныч нәтиҗәләре турында Сталинга язылган хат

Письмо Сталину о последствиях Великой Отечественной войны

A letter to Stalin about the consequences of the Great Patriotic War

Казан. Спас манарасы

Казань. Спасская башня

Kazan. Spasskaya Tower



1945 елның май азагында Дәүләт Оборона Комитеты карары нигезендә Татарстандагы оборона сәнәгате предприятиеләренең бер өлеше халык куллану товарлары җитештерә башлый. Яшел Үзәннең Серго исемендәге заводында алюминий һәм бакыр савыт-саба, примуслар, культиваторлар өчен кискечләр (1946), сортларга аеру машиналары (1947), чәчкечләр (1949 – 1950) җитештерә башлау сугыштан соңгы үзгәрешләрнең беренче нәтиҗәләре булып тора.

1946 елда авыр сәнәгатьнең төп тармаклары үсешен тизләтү максатыннан республика сәнәгатен үзгәртеп кору башлана. Татарстанда очкычлар, двигательләр һәм суднолар төзүне киңәйтү планлаштырыла. Әлеге тармакларга зур финанслар, матди һәм хезмәт ресурслары юллана. Авыр сәнәгать һәм оборона сәнәгате үсеше шартларыннан берсе булып фәнни-техник алгарыш казанышларын максималь файдалану тора.

В конце мая 1945 г. на основании постановления Государственного Комитета Обороны часть предприятий Татарстана, работавших на оборону, была перестроена на выпуск товаров для населения. Одним из первых результатов послевоенной конверсии на Зеленодольском заводе им. Серго стало производство алюминиевой и медной посуды, примусов, режущих лап для культиваторов (1946 г.), сортировочных машин (1947 г.), сеялок (1949 – 1950 гг.).

В 1946 г. началась новая структурная перестройка промышленности республики с целью форсирования развития основных отраслей тяжёлой промышленности. Планировалось расширение самолётостроительной, двигателестроительной и судостроительной базы в Татарстане. В эти отрасли направлялись значительные финансовые средства, материальные и трудовые ресурсы. Одним из условий развития отраслей тяжёлой и оборонной промышленности было максимальное использование достижений научно-технического прогресса.

At the end of May of 1945, based on the Resolution of the State Committee for Defence, a number of enterprises of Tatarstan, which were working for the defence, were reconstructed for the production of consumer goods. One of the first results of the post-war conversion at the Zelenodolsk Plant n.a. Sergo became the production of aluminium and copper ware, primus heaters, blades for cultivators (1946), assorting engines (1947), and sowing machines (1949 – 1950).

In 1946, the new structural reform of the republic's industry was started in order to accelerate the development of the basic sectors of the heavy industry. The plans included the expansion of the aircraft-, engine-, and ship-building base in Tatarstan. Considerable amounts of money, material and labour resources were allocated for these industries. The maximum possible use of achievements of scientific and



Татарстанның тулай продукциясе күләмен арттыруда эвакуцияләнгән предприятиеләр зур роль уйный. Сугышның соңгы елларында алар базасында авыр сәнәгатьнең очкычлар төзү, двигательләр җитештерү, медицина инструментлары, оптик-механик, сәгать эшләү кебек технологик яктан алга киткән тармаклары барлыкка килә. Моның нәтиҗәсендә республика илнең эре индустриаль төбәгенә әверелә. Сугыштан соңгы беренче елларда приборлар төзү һәм радиоэлектроника сәнәгатенә нигез салына. Шул ук вакытта хәрби сәнәгать комплексы үсешенә дә аерым игътибар бирелә. 1950 елда сәнәгать продукциясе күләме, 1940 ел белән чагыштырганда, 3,5 тапкырга арта.

Значительную роль в повышении валового продукта Татарстана сыграли эвакуированные предприятия, на базе которых к концу войны возникли такие технологически развитые отрасли тяжёлой промышленности, как самолётостроение, двигателестроение, медико-инструментальная, оптико-механическая, часовая. В результате республика превратилась в крупный индустриальный регион страны. В первые послевоенные годы были заложены основы приборостроительной и радиоэлектронной промышленности. При этом особое внимание уделялось развитию военно-промышленного комплекса. Объём промышленной продукции в 1950 г. увеличился в 3,5 раза по сравнению с 1940 г.

technical progress was one of the conditions for the development of sectors of the heavy and defence industries.

An important role in the increasing of the gross regional product of Tatarstan was played by the evacuated enterprises. They provided the basis for the emergence, by the end of war, of such technologically advanced sectors of the heavy industry as aircraft-, engine-building, medical instruments, optical and mechanical, and watch industries. As a result, the republic turned into a large industrial region of the country. Over the first post-war years, there were laid down the fundamentals of instrument-making and radio-electronic industries. At the same time, special attention was paid to the development of the military industrial complex. In the year 1950, the industrial production volume grew 3.5 times compared to 1940.

Н. Д. Кузнецов. Казан – биш диңгез порты. 1959

Н. Д. Кузнецов. Казань – порт пяти морей. 1959

N. D. Kuznetsov. Kazan, the port of five seas. 1959





Нефть районы

Нефтяной район

The oil-rich district



Самотлор-Әлмәт торбаүткәрече төзелеше. 1973

Строительство трубопровода Самотлор-Альметьевск. 1973

Construction of Samotlor-Almetyevsk pipeline. 1973

Сугыш елларында нефть чыгара башлау Татарстанда җирле сәнәгатьнең киләчәктәге структур-тармак үсешен билгеләи: яңа нефть ятмалары үзләштерелә, нефть чыгару һәм нефть химиясе тармаклары киңәйтелә. Сугыштан соңгы чорда үзләштерелә башлаган беренче эре нефть ятмалары булып Баулы һәм Ромашкино чыганаклары санала. 1950 елга Татарстанда нефть чыгару шулкадәр зур күләмгә (866,5 мең тонна) ия була ки, республикада нефть чыгару буенча нефтьче-геолог А. Т. Шмарёв җитәкчелегендә «Татнефть» берләшмәсе төзү турында карар кабул ителә. 1950 елларда Татарстанда куәтле нефть, газ чыгару һәм нефть эшкәртү комплексы («Татнефть», «Лениногорскнефтестрой», Миңнебай газ эшкәртү заводы һ. б.) формалаша башлый.

Начало промышленной добычи нефти в военные годы определило дальнейшее структурно-отраслевое развитие местной промышленности Татарстана: освоение новых месторождений нефти, расширение нефтедобывающей и нефтехимической отраслей. Первыми крупными месторождениями, освоение которых началось в послевоенный период, были Бавлинское и Ромашкинское. К 1950 г. добыча нефти в Татарстане обрела столь значительные объёмы (866,5 тыс. т), что в республике было создано союзное объединение по добыче нефти «Татнефть» во главе с геологом-нефтяником А. Т. Шмарёвым. В 1950-е гг. в Татарстане начал формироваться мощный нефтегазодобывающий и нефтеперерабатывающий комплекс («Татнефть», «Лениногорскнефтестрой», Миннибаевский газоперерабатывающий завод и др.).

The start of commercial extraction of crude oil during the war period determined the subsequent development of the regional industry of Tatarstan: the development of new oilfields, expansion of the oil-extraction and petrochemical industries. The first large oilfields, the development of which started in the years of war, included the Bavlinskoye and the Romashkinskoye. By the year 1950, oil extraction in Tatarstan achieved such impressive numbers (866 500 tonnes), that an All-Union Oil Production Association, Tatneft, was established in the republic. The enterprise was headed by A. T. Shmaryov, an oil geologist. In the 1950s, a powerful oil-and-gas-extracting and oil-processing complex began to shape up in Tatarstan (Tatneft, Leninogorskneftestroy, Minnibayevo Gas Processing Plant, and so on).



Нефть вышкасын күчерү

Перевозка нефтяной вышки


Transportation of an oil derrick


«Теплоконтроль» җитештерү берләшмәсе республикада беренчеләрдән булып сыгылмалы сәнәгать системасын оештыра

ПО «Теплоконтроль» одним из первых в республике внедрило гибкую производственную систему

PO Teplokontrol was one of the first in the republic to install a flexible production system







«Пишмаш» заводы стахановчысы

Стахановец завода «Пишмаш»

A Stakhanov's follower from "Pishmash" Plant

С. Галиев, М. И. Калинин исем. завод стахановчысы

С. Галеев, стахановец завода им. М. И. Калинина

S. Galeyev, Stakhanov's follower from the Plant n.a. M.I. Kalinin

1951 елның 7 июлендә Казан компрессорлар заводы үзенең беренче продукциясен бирә. Казанның беренче компрессорын үз куллары белән ясаучылар цех башлыгы А. Крысин, токарьлар Н. Каулис һәм Б. Шахмаев, слесарь Н. Саламатов һ. б. була. Соңрак завод зур егәрлекле, югары җитештерүчәнлекле үзәктән куучы компрессорлар һәм сәнәгый суыту машиналары чыгара башлый. 1952 елның 13 октябрендә беренче продукциясен чыгарган заманча яңа предприятие – «Теплоконтроль» заводы ачылу Татарстан өчен зур вакыйга була. Аның приборлары СССРда гына түгел, чит илләрдә дә киң кулланыла. 1956 елда гына да завод читкә 4,5 млн сумлык 18 580 прибор чыгара.

Җирле сәнәгатьне торгызу һәм аны тыныч тормышка җайлаштырып эшләтеп җибәрү 1947 елга төгәлләнә. 1950 еллар башына сәнәгать җитештерү дәрәҗәсе сугышка кадәргедән артып китә. Әмма авыр индустрияне җиңел һәм азык-төлек сәнәгатенең әйләнештәге акчалары исәбенә өстенлекле үстерү сәнәгый җитештерүнең структурасы хәрби-оборона билгеләнешендәге продукция җитештерү артуы ягына деформацияләнүенә китерә.

7 июля 1951 г. свою первую продукцию дал Казанский компрессорный завод. Непосредственными исполнителями первого казанского компрессора стали начальник цеха А. Крысин, токари Н. Каулис, Б. Шахмаев, слесарь Н. Саламатов и др. Впоследствии завод начал выпускать высокопроизводительные центробежные компрессоры и промышленные холодильные машины большой мощности. Большим событием для Татарстана стал пуск нового современного предприятия – завода «Теплоконтроль», который 13 октября 1952 г. выпустил первую продукцию. Его приборы были востребованными не только в СССР, но и за рубежом. Только в 1956 г. завод отправил на экспорт 18 580 приборов на сумму 4,5 млн рублей.

Работы по восстановлению и демилитаризации местной промышленности в основном были завершены в 1947 г. К началу 1950-х гг. уровень промышленного производства превысил довоенный. Однако приоритетное развитие тяжёлой индустрии за счёт оборотных средств лёгкой и пищевой промышленности привело к дальнейшей деформации структуры промышленного производства в сторону увеличения производства продукции военно-оборонного назначения.

On 7 July 1951, the Kazan Compressor Plant unveiled its first products. The direct manufacturers of the first Kazan-made compressor included shop manager A. Krysin, turners N. Kaulis, B. Shakhmayev, metal worker N. Salamatov, and other specialists of the enterprise. Later, the plant mastered the manufacture of highly efficient centrifugal compressors and industrial high-capacity cooling machines. The opening of the new, modern enterprise – Teplocontrol – became a notable event for Tatarstan. On 13 October 1952, the plant manufactured its first products. The instruments produced by the enterprise were in demand not only in the USSR, but also abroad. In the year 1956 alone, the plant exported 18 580 instruments to the amount of 4.5 million roubles.

The work for the recovery and demilitarisation of the local industry were mainly completed in 1947. By the early 1950s, the level of industrial production exceeded the pre-war one. However, the priority-driven development of the heavy industry that relied on the working assets of the light and food industries resulted in further deformation of the structure of industrial production towards the increase of military industrial production.

## Сугыштан соңгы чорда авыл хуҗалыгы

Татарстан авыл хуҗалыгына сугыш авыр йогынты ясый. Сугыш елларында күмәк хуҗалыклардагы бөртекле культуралар мәйданы – 39,9 % ка (655 мең гектар), техник культуралар мәйданы – 35,2 % ка, бәрәңге мәйданы – 8,1 % ка; атларның баш саны – 20,3 % ка, дуңгызларныкы – 44,1 % ка, сарык һәм кәҗәләрнеке 34,5 % ка кими. Машина-трактор станцияләренең автотрактор һәм техник паркы искерә. Эшкә яраклы халыкның саны өчтән бер өлешкә кими, нәтиҗәдә авыл хуҗалыгы эшләре күпкә соңга калып башкарыла, бу үз чиратында уңышның кимүенә китерә.

Авыл хуҗалыгы бик көчсезләнә. 1945 елда аның тулаем продукциясе, сугышка кадәрге чор белән чагыштырганда, 60 % ны тәшкил итә. Сугыштан соңгы беренче бишьеллыкта һава шартлары да бик начар була. 1946 елда Татарстанга куркыныч корылык килә, уңыш сугышка кадәрге чордан ике мәртәбә ким җыела, бу авыл җирлегенә массакүләм ачлык алып килә. 1948, 1949 еллар да коры була. Сугыш елларында матди-техник базасы нык какшаган авылларга табигать афәтләренә каршы тору авырга туры килә.

Коллектив бригады заливщиков из литейного цеха Казанского моторостроительного завода

The team of pour men from the foundry shop of the Kazan Engine-Building Plant

## Фәнни-техник революция шартларында сәнәгать

«Җепшеклек» чорында индустрия үсеше нигездә яңа сәнәгый төзелеш, барыннан беренче чиратта авыр сәнәгатьнең хәрби-оборона комплексына бәйле югары технологияле предприятиеләрен төзү хисабына бара. Шул ук вакытта авыр индустриянең машина төзелеше һәм металл эшкәртү кебек техник алгарыш казанышлары кулланылган тармакларына зур әһәмият бирелә. Хәрби-сәнәгый комплекс предприятиеләрендә заманча җиһазландырылган цехлар, конструкторлык бюролары оештырыла, башлыча оборона билгеләнешендәге уникаль эшләнмәләр җитештерелә. 1955 елда Казан махсус конструкторлык бюросында радиолокация станцияләре өчен махсус радиоүлчәгеч аппаратура эшләнә. Махсус конструкторлык бюролары «Уран», «Грунт», «Акация», «Флокс», «Вольт» һ. б. дигән кодлы исемнәр бирелгән югары технологияле эшләнмәләр чыгара.

## Промышленность в контексте научно-технической революции

Развитие индустрии в период «оттепели» происходило в основном за счёт нового промышленного строительства, прежде всего высокотехнологичных предприятий тяжёлой промышленности, связанных с военно-оборонным комплексом. При этом большое значение придавалось таким отраслям тяжёлой индустрии, как машиностроение и металлообработка, в которых внедрялись передовые достижения технического прогресса. На предприятиях военно-промышленного комплекса создавались оснащённые современным оборудованием цеха, конструкторские бюро, разрабатывались и производились уникальные изделия, преимущественно оборонного назначения. В 1955 г. в Казанском особом конструкторском бюро была создана специальная радиоизмерительная аппаратура для радиолокационных станций. Особые конструкторские бюро разрабатывали высокотехнологичные изделия под различными кодовыми названиями: «Уран», «Грунт», «Акация», «Флокс», «Вольт» и др.

## Industry in the Context of Scientific and Technical Revolution

The development of the industry in the period of the "Thaw" was taking place mainly in the form of the new industrial construction, first of all, of high technology enterprises in the heavy industry connected with the defence/military complex. Great attention was paid to such sectors of the heavy industry as mechanical engineering and metal-working, in which the advanced technical achievements were being introduced. Created at enterprises of the military-industrial complex were the workshops and design bureaus that were fitted with modern equipment. They designed and manufactured unique products, mainly for defensive purposes. In 1955, the Kazan special design bureau developed special-purpose radio-measuring devices for radio detecting and ranging stations. Special design



Илнең хәрби потенциалын ныгытуда 1953 елда илдә беренче буларак югары тизлекле Ту-16 реактив бомбардировщигын җитештерә башлаган Горбунов исемендәге Казан авиация заводы зур роль уйный. Бу самолётларда дөнья авиация рекордлары куела. Моннан тыш, завод гражданлык авиациясе үсешенә дә зур өлеш кертә. 1956 елдан заводта дөньяда беренче Ту-104 реактив пассажир очкычын җитештерү җайга салына. М. Горький исемендәге Яшел Үзән суднолар төзү заводы хәрби диңгез ведомствосының катлаулы заказларын үти. Заводта СССР Кораллы көчләре өчен кеймәләргә каршы оборона системасын төзү буенча моңарчы күрелмәгән эшләнмәләр уйлап тапкан конструкторлык бюросы эшли.

Төгәл машиналар төзү, моторлар төзү, вертолёт, «Радиоприбор», Серго исемендәге заводларда, вакуумлы машиналар төзи торган тәҗрибә заводында сәнәгать продукциясе, аеруча хәрби юнәлештәге продукция җитештерү, югары темплар белән үсә. Татарстан предприятиеләрендә, илдә беренче буларак, компрессорлар, насослар, үлчәү һәм оптика приборлары, сәгатьләр, медицина

Огромную роль в укреплении военного потенциала страны играл Казанский авиационный завод им. Горбунова, который в 1953 г. первым в стране освоил выпуск скоростных реактивных бомбардировщиков Ту-16. На этих самолётах были установлены мировые авиационные рекорды. Кроме того, завод внёс большой вклад и в развитие гражданской авиации. С 1956 г. на нём было налажено серийное производство первого в мире реактивного пассажирского самолёта Ту-104. Сложнейшие заказы военно-морского ведомства выполнял Зеленодольский судостроительный завод

bureaus were engaged in the development of high-technology devices under various code names: "Uran", "Grunt", "Akatsiya", "Floks", "Volt", and so on.

The great role in the enhancement of the military potential of the country was played by the Kazan Aircraft Building Plant n.a. Gorbunov, which, in 1953, was the country's first enterprise to master the manufacture of high-speed Tu-16 jet



Ту-16 реактив күпмаксатлы очкычы

Реактивный многоцелевой самолёт Ту-16

Tu-16, a multi-purpose jet plane

Ту-104 реактив пассажирлар очкычы

Реактивный пассажирский самолёт Ту-104

Tu-104, a passenger jet plane



аппаратлары һәм башка эшләнмәләрнең күп төрләре эшләп чыгарыла. 1950 елларда 387 номерлы Казан авиазаводында – вертолётлар, Серго исемендәге Яшел Үзән заводында «Мир» көнкүреш суыткычлары җитештерелә башлый.

1950 елларда Татарстанда нефть чыгару сәнәгате куәтле үсеш ала, 1950 елда 866,5 мең тонна нефть чыгарылса, 1958 елда бу күрсәткеч 31,8 миллион тоннага җитә, ягъни 36,7 тапкырга арта. Республика илнең нефть чыга-




Ми-1 вертолёты

Вертолёт Ми-1

Mi-1 helicopter



«Теплоконтроль» җитештерү берләшмәсе. Манометрлар җыюның автоматик линиясен көйләү һәм җайга салу

Производственное объединение «Теплоконтроль». Регулировка и отладка автоматической линии предварительной сборки манометров

“Teplokontrol” Production Association. Regulation and adjusting of an automated line for preliminary assembly of manometers

им. М. Горького. Конструкторское бюро завода выполняло уникальные разработки по созданию системы противолодочной обороны Вооружённых сил СССР.

Высокими темпами росло производство промышленной продукции, особенно военного назначения, на моторостроительном, вертолётном заводах, заводах точного машиностроения, «Радиоприбор», им. Серго, заводе штепсельных разъёмов, опытном заводе вакуумного машиностроения. На предприятиях Татарстана впервые в стране были разработаны и изготовлены многие типы компрессоров, насосов, измерительных и оптических приборов, часов, медицинских аппаратов и других изделий. В 1950-е гг. на Казанском авиазаводе № 387 было начато производство вертолётов, на Зеленодольском заводе им. Серго освоен широкий выпуск бытовых холодильников «Мир».



Космик корабльләрнең элемтәсен тәэмин итүче югары төгәллекка ия гидростабилизатор. Җитештерү 1965 елда җайга салына. Казан «Электроприбор» заводы

Гидростабилизатор высокоточный для обеспечения стыковки космических кораблей. Производство освоено в 1965 г. Казанский завод «Электроприбор»

High-precision hydrostabiliser for spacecraft mating. The production was mastered in 1965. “Electropribor” Plant, Kazan

bombers. These planes established world records. Besides, the plant also made a great contribution to the development of civil aviation. Starting from 1956, it was engaged in large-scale manufacture of the world’s first commercial jet airplane, Tu-104. The Zelenodolsk Ship-building Plant n. a. M. Gorky implemented the most difficult orders from the navy department. The plant included the design bureau, which was devising the unique developments for the creation of a system of anti-submarine defence of the Armed Forces of the USSR.

Growing at a rapid pace was the production of industrial products, especially of military purpose, at the precise engineering, engine-building, and helicopter plants, at “Radiopribor” plant, at the plant n.a. Sergo, the plant for production of breakaway connectors, at the experimental plant of vacuum mechanical engineering. The enterprises of Tatarstan were the first in the country to develop and start the manufacture of various types of compressors, pumps, measuring and optical devices, watches, medical equipment and other goods. In the 1950s, the Kazan Aircraft-Building Plant No 387 started the manufacture of helicopters, and the Zelenodolsk Plant n. a. Sergo mastered the large-scale production of “Mir” household refrigerators.



ру тармагында әйдәп баручыга («икенче Баку»га) әверелә. Ул елдан-ел кара алтын чыгаруны арттыра һәм нефть чыгаруда беренчелекне алып тора. Моннан тыш, Татарстанның нефть чыгаручы көньяк-көнчыгыш районнарында, нефтьне республикадан читкә җибәрү өчен, товар парклары, нефтьүткәргечләр төзелә. 1959 елда «Дуслык» нефтьүткәргечен кору башлана, аның өч тармагы төзелә, алар буенча нефть Польша, ГДР, Чехословакия, Венгриягә озатыла.

Татарстанда нефть чыгару индустриясенең эре үзәген оештыру нефть химиясе сәнәгате өчен нигез була: Казан Органик синтез заводы, Түбән Кама Нефтехимия комбинаты һ. б. төзелә башлый. Республикада яңа территорияләрне сәнәгый үзләштерү белән энергетика тармагын үстерүдәге мөһим үзгәрешләр үзара бәйле була. 1963 елда уникаль гидрокорылма булган Зәй ГРЭСының 1200 МВт егәрлектәге беренче чираты кулланылышка тапшырыла. 1958 – 1959 елларда Казан

В 1950-е гг. интенсивное развитие в Татарстане получила нефтедобывающая промышленность, объём которой увеличился в 36,7 раза (с 866,5 тыс. т в 1950 г. до 31,8 млн т в 1958 г.). Республика стала бесспорным лидером нефтедобывающей отрасли в стране («вторым Баку»). Она из года в год наращивала добычу чёрного золота и прочно удерживала первенствующее положение в нефтедобыче. Кроме того, в юго-восточных нефтедобывающих районах Татарстана активно строились товарные парки, нефтепроводы, по которым нефть переправлялась за пределы республики. В 1959 г. началось сооружение нефтепровода «Дружба», были построены три нитки этого нефтепровода, по которым нефть поступала в Польшу, ГДР, Чехословакию, Венгрию.

Создание в Татарстане крупного центра нефтедобывающей индустрии послужило основой для возникновения нефтехимической промышленности:

In the 1950s, actively developing in Tatarstan was the oil-extraction industry. Its volume grew 36.7 times (from 866 500 tonnes in 1950 up to 31.8 million tonnes in 1958). The republic became an undoubted leader of the oil extracting industry in the country (“the second Baku”). Every year it was increasing the production of the black gold and stood firm as the leader in oil production. In addition to that, actively built in the republic’s south-eastern oil-producing districts were the tank farms and oil pipelines that were used to transport oil outside the territory of the republic. In 1959, there began the construction of the “Druzhba” oil pipeline. All in all, three lines were built to transport oil to Poland, GDR, Czechoslovakia, and Hungary.


The establishment in Tatarstan of a large centre of the oil extracting industry provided the basis for the emergence of the petrochemical industry: there began the construction of the Kazan Organic Synthesis Plant, the Nizhnekamsk




«Дуслык» нефтьүткәргече. Әлмәт районы

Нефтепровод «Дружба». Альметьевский район


“Druzhba” pipeline. Almetyevsky District



Түбән Кама Нефтехимия комбинаты

Нижнекамский нефтехимкомбинат

Nizhnekamsk Petrochemical Combine



Идел буендагы иң эре дәүләт район электр станциясе төзелеше. Зәй ГРЭСы. 1960 еллар

Строительство крупнейшей в Поволжье государственной районной электростанции. Заинская ГРЭС. 1960-е

Construction of the state central station generating power plant, the largest in the Volga region. Zainsk Hydro Power Plant. 1960s

машина төзелеше предприятиеләрендә җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыруга, яңа техника һәм алгарыш технологияләрен кулланылышка кертүгә юнәлдерелгән 400 дән артык эре чара үтә. Шулай да азык-төлек һәм җиңел сәнәгатьнең күп кенә предприятиеләре физик һәм мораль яктан искергән җиһазлар белән эшли, бу – әзер продукциянең сыйфатында ачык чагыла, шуның өчен дә ул халык арасында киң кулланылыш тапмый.

началось строительство Казанского завода органического синтеза, Нижнекамского нефтехимического комбината и др. С промышленным освоением новых территорий в республике были связаны важные изменения в развитии её энергетической отрасли. В 1963 г. была введена в эксплуатацию первая очередь уникального гидросооружения – Заинская ГРЭС (мощностью 1200 МВт).

За 1958 – 1959 гг. на машиностроительных предприятиях Казани было выполнено свыше 400 крупных мероприятий, направленных на механизацию и автоматизацию производства, внедрение новой техники и прогрессивной технологии. Однако многие предприятия пищевой и лёгкой промышленности работали на физически и морально устаревшем оборудовании, что сильно сказывалось на качестве готовой продукции, которая поэтому не пользовалась спросом у населения.

Petrochemical Combine, and so on. Connected with industrial development of new territories in the republic were the major changes in the development of its power engineering sector. In 1963, the first stage of the unique hydraulic works, the Zainsk hydroelectric power plant, was put into operation, being rated at 1 200 megawatts).

In 1958 – 1959, the mechanical engineering plants of Kazan implemented over 400 large enterprises aimed at mechanisation and automation of production, introduction of new equipment and advanced technologies. However, many enterprises of the food and light industries were operating physically and morally obsolete equipment, which affected considerably the quality of the finished products, for which reason in was not in demand with the population.

Хәрби сәнәгать комплексына бәйле индустрияне өстенлекле үстерүнең тискәре тенденцияләре 1950 еллар ахырында республика милкендәге предприятиеләрнең чагыштырма саны кимүдә тагын да ачыграк чагылыш таба (1954 елда 20 процenttан алып 1958 елда 12 процентка кадәр). Мондый тенденция 1990 еллар башына кадәр саклана.

Хрущёв унъеллыгы Татарстанда шәһәр халкы санының тиз үсеш темплары белән дә характерлана (гомумсоюз күрсәткечләреннән 1,5 мәртәбә артык). Бу чорда республикада шәһәр һәм авыл халкының урнашып яшәү картинасы да үзгәрә. Бигрәк тә Татарстанның көньяк-көнчыгышында зур үзгәрешләр була, ул республиканың күпмилләтле шәһәр халкы булган икенче сәнәгать үзәгенә әйләнеп китә. Анда Әлмәт, Лениногорск кебек яңа шәһәрләр, Азнакай, Актүбә, Баулы, Карабаш һ. б. шәһәр тибындагы бистәләр барлыкка килә.

Негативные тенденции преимущественного развития индустрии, связанной с военно-промышленным комплексом, в конце 1950-х гг. стали более отчётливо проявляться в сокращении удельного веса предприятий, находившихся в республиканской собственности (с 20 % в 1954 г. до 12 % в 1958 г.). Такое положение сохранялось вплоть до начала 1990-х гг.

Хрущёвское десятилетие характеризовалось и быстрыми темпами роста городского населения в Татарстане (в 1,5 раза превышающими общесоюзные показатели). В этот период изменилась и картина расселения городского и сельского населения в республике. Наиолее значительные перемены произошли на юго-востоке Татарстана, который стал представлять собой вторым промышленным центром республики с многонациональным городским населением. Там появились новые города – Альметьевск, Лениногорск, посёлки городского типа Азнакаево, Актюбинский, Бавлы, Карабаш и др.

The negative tendencies of the prevailing development of the industry that was connected with the military industrial complex became visible at the late 1950s, which manifested itself in the reduction of a portion of enterprises that were the republic's property (from 20 % in 1954 down to 12 % in 1958). Such tendency existed until the early 1990s.

The Khrushchev's decade was also marked in Tatarstan by rapid growth of the urban population (1.5 times higher compared to the country's average). Also changed over that period was the pattern of migration of the urban and rural population in the republic. Especially drastic were the changes in the south-east of Tatarstan, which became the second industrial centre of the republic with the multi-national urban population. The new towns, such as Almetyevsk, Leninogorsk, and urban settlements, such as Aznakayevo, Aktyubinsky, Bavly, Karabash, and so on have emerged there.

Н. Д. Кузнецов. Язга таба. Казан Оргсинтез заводы. 1963 – 1964

Н. Д. Кузнецов. К весне. Казанский завод оргсинтеза. 1963 – 1964

N. D. Kuznetsov. By spring. The Kazan Organic Synthesis Plant. 1963 – 1964



## Реформалар шартларында авыл

1953 – 1957 елларда эзлекле аграр реформалар уздыру нәтиҗәсендә Татарстанның авыл хуҗалыгы акрынлап депрессия хәленнән чыга башлый. Авыл хуҗалыгы продукциясенә әзерләү һәм сатып алу бәяләрен арттыру, авылда хезмәтне механикалаштыру һәм электрлаштыруны үстерү, хуҗалыкларның дәүләт алдындагы бурычын юкка чыгару, колхозчыларның шәхси ярдәмче хуҗалыкларыннан натуралата салымнарны бетерү һәм башка чаралар авылны үстерүдә һәм Татарстандагы күмәк хуҗалык крестьяннарының социаль-икътисадый хәлендә уңай чагылыш таба. 1945 – 1958 елларда күп кенә күмәк хуҗалыкларда һәм совхозларда җитештерү күрсәткечләре 2 – 3 тапкырга арта. Республикада авыл хуҗалыгы җитештерүе күрсәткечләренең уңай динамикасы шулай ук дәүләт тарафыннан авыл хуҗалыгына капитал салуларның артуы (узган бишьеллык белән чагыштырганда, 2 мәртәбәгә күбрәк) белән дә аңлатыла.

Моннан тыш, әлеге принципиаль мөһим чаралар күрелү белән, авылның икътисади һәм социаль-мәдәни үсешендә дә уңай

## Деревня в условиях реформ

В результате проведения последовательных аграрных реформ в 1953 – 1957 гг. сельское хозяйство Татарстана постепенно стало выходить из депрессивного состояния. Повышение заготовительных и закупочных цен на сельскохозяйственную продукцию, рост механизации труда и электрификации деревни, списание долгов и недоимок хозяйств государству, отмена натуральных сборов с личных подсобных хозяйств колхозников и другие меры благоприятно отразились на развитии деревни и на социально-экономическом положении колхозного крестьянства Татарстана. В 1954 – 1958 гг. во многих колхозах и совхозах производственные показатели увеличились в 2 – 3 раза. Положительная динамика показателей сельскохозяйственного производства республики стала возможной также благодаря росту государственных капиталовложений в сельское хозяйство – в 2 раза по сравнению с предыдущим пятилетием.

Кроме того, с реализацией этих принципиально важных мер произошли положительные подвижки в экономическом и социально-культурном развитии

## Village Under Reforms

As a result of consistent agrarian reforms of 1953 – 1957 the agriculture of Tatarstan began to gradually find its way out of the depression. The rise in the procurement and purchasing prices for agricultural produce, the growth of mechanisation of labour and electrification of village, the writing off of debts and arrears owed by enterprises with respect to the state, the abolishment of taxes payable in kind by personal small-holdings of collective farmers and other measures had a favourable effect on the development of village and on the social and economic condition of the collective farmers of Tatarstan. In 1954 – 1958, the performance indicators have improved 2 – 3 times at many collective and Soviet farms. The positive changes in performance of agriculture of the republic became possible, inter alia, due to the growth of state capital investment in agriculture, which grew 2 times compared to previous five-year period.

In addition to that, along with the taking of these important measures, favourable changes took place in the economic, social, and cultural development of village,



Биектау районының «Серп и молот» колхозы. Бәрәңге рәтләре арасын эшкәртү

Колхоз «Серп и молот» Высокогорского района. Возделывание картофеля

“Serp i Molot” Collective Farm in the Vysokogorsky District. Potato cultivation



Югары Ослан районының Ворошилов исем. колхоз бакчасында

В саду колхоза им. Ворошилова Верхнеуслонского района

In the garden of the Collective Farm n.a. Voroshilov in the Verkhneuslonsky District

үзгәрешләр була – авыл халкының тормышы яхшыра башлый. Күмәк хуҗалыкларда һәм совхозларда хезмәтне механикалаштыру шактый арта, 1959 – 1965 елларда трактор паркы 7,3 мең машинага арта. 1965 елга Татарстанның авыл торак пунктларын электр белән тәэмин итү төгәлләнә. Колхозчылар айлык хезмәт хакын аванс белән ала башлыйлар.

Әмма 1950 еллар ахырына авыл хуҗалыгын күтәрүдәге икътисади чаралар волюнтаристлык ысуллары белән кысрыклана башлый. «Алдынгы» җитештерү технологияләре дип аталган кукуруз һәм кайбер башка культураларны җитештерүне көчләп тагу буенча кампанияләр гадәти административ характерда була. Машина-трактор станцияләрен үзгәртеп кору һәм күмәк хуҗалыкларга кыйммәтле авыл хуҗалыгы техникасын ваклап түләү шарты белән сату җәмәгать хуҗалыкларының финанс хәлендә тискәре чагылыш таба. Нәтиҗәдә, 1953 – 1957 еллардагы уңай үзгәрешләр чорында туплаган акчаларын югалтып, Татарстан күмәк хуҗалыкларының күп өлеше банкрот хәлендә кала. Бу игрьк тә терлекчелек үсешендә тискәре чагылыш таба. Акча булмау колхозларга иске терлекчелек ферма-



Тракторчы. «Социализм» колхозы. 1960 еллар

Тракторист. Колхоз «Социализм». 1960-е

Tractor driver. "Sotsializm" Collective Farm. 1960s



Сарман районының «Үрнәк» колхозында язгы чәчүгә әзерлеккә багышланган семинар

Семинар в колхозе «Урняк» Сармановского района по подготовке к весеннему севу

A workshop dedicated to preparations for spring works in the "Urnyak" Collective Farm in the Sarmanovsky District

деревни – стало повышаться благосостояние сельского населения. В колхозах и совхозах значительно возросла энерговооружённость труда: в 1959 – 1965 гг. тракторный парк увеличился на 7,3 тыс. машин. К 1965 г. была завершена электрификация сельских населённых пунктов Татарстана. Колхозники начали получать ежемесячную авансовую зарплату.

Однако к концу 1950-х гг. экономические меры по подъёму сельского хозяйства стали вытесняться волюнтаристскими методами администрирования. Типично административный характер носили кампании по повсеместному навязыванию производства кукурузы и других культур, некоторых так называемых «передовых» производственных технологий. Реорганизация машинно-тракторных станций и продажа в рассрочку дорогостоящей сельскохозяйственной техники колхозам негативно отразились на экономике общественных хозяйств. В результате большая часть колхозов Татарстана, потеряв свои накопления, сделанные в период благоприятных перемен 1953 – 1957 гг., оказались в положении банкрота. Это особенно тяжело отразилось на развитии животноводства. Отсутствие средств не позволяло

which resulted in the growth of the welfare of the rural population. Considerably higher in the collective and Soviet farms became the power availability per man: in 1959 – 1965, the tractor park grew by 7 300 units. By 1965, the electrification of the rural settlements in Tatarstan was completed. Collective farmers began receiving monthly advance wage payments.

However, by the end of the 1950s the economic measures taken for the recovery of the agriculture began to be substituted by voluntary methods of administration. Typically administrative were the campaigns for the total intrusion of corn and other crops, of certain so-called "advanced" production technologies. The reorganization of the machine and tractor stations and the sale of expensive agricultural equipment to collective farms in installments had but the adverse effect on the economy of the public entities. As a result, the major portion of collective farms of Tatarstan, having lost their savings that were accumulated in the period of favourable changes of 1953 – 1957, proved to be on the verge of bankruptcy. The heaviest blow was struck on the development of cattle-breeding. The absence of funds did not allow the collective farms to reconstruct the old and build




«Оседлаю я горячего коня» плакаты. 1962

Плакат «Оседлаю я горячего коня». 1962

Poster "I will saddle a high-mettled steed". 1962

ларын төзекләндерергә һәм яңа фермалар төзергә, җитештерү процессларын механикалаштырырга, шулай ук нәселле терлек һәм кош-корт сатып алырга мөмкинлек бирми.

Күмәк хуҗалык крестьяннарының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын чикләү кампаниясе авыл халкының хәлен тагын да начарайта, ул Татарстанда азык-төлек мәсьәләләренең кискенләшүенә генә түгел, авылдагы социаль-икътисади вазгыятьне тотрыксызландыруга һәм авыл халкының шәһәр һәм шәһәр тибындагы поселокларга күпләп күченүенә дә китерә. 1939 һәм 1959 еллар арасындагы чорда Татарстанда шәһәр халкы 600 меңнән 1,2 млн кешегә кадәр арта, ә авыл халкы 2,3 млн кешедән 1,7 млн кешегә кала. Авыл халкының интенсив миграциясе Татарстанның аграр секторында кадрлар мәсьәләсен кискенләштерә, бигрәк тә авылларда югары квалификацияле белгечләр (агрономнар, ветеринарлар, зоотехниклар, инженерлар һ. б.) җитмәү нык сизелә.

Татарстанның авыл хуҗалыгы «җепшеклек» чорында өзлексез үзгәрешләрдән, даими рәвештә күмәк хуҗалыкларны эреләндерү һәм таркатудан, аларны совхозларга үзгәртеп корудан авырлык кичерә. Күп кенә үзгәртеп кору чаралары еш кына ашыгыч рәвештә, конкрет шартларны исәпкә алмыйча башкарыла, шул ук вакытта торак пунктларның этник үзенчәлекләре игътибарсыз кала. Бу хәл татар яки рус авыллары белән бер күмәк хуҗалыкка кертелгән мари, чуваш, удмурт авылларының күмәк хуҗалыгы крестьяннары тарафыннан ризасызлык тудыра. Аларның канәгатьсезлегенең төп сәбәбе, кагыйдә буларак, бөтен административ-хуҗалык һәм социаль-мәдәни инфраструктураның рус яки татар авылларында туплануы була. Шулай итеп, «перспективалы булмаган» авыллар белән көрәш милли авылларда каршылыкларга китерә.

колхозам реконструировать старые и строить новые животноводческие фермы, осуществлять механизацию производственных процессов, а также приобретать высокопородистый продуктивный скот и птицу.

Положение сельского населения ещё больше ухудшила кампания по ограничению личных подсобных хозяйств, которая привела не только к обострению продовольственной проблемы в Татарстане, но и к дестабилизации социально-экономической ситуации в деревне и массовой миграции сельского населения в города и посёлки городского типа. За период между 1939 и 1959 гг. городское население в Татарстане увеличилось с 600 тыс. до 1,2 млн человек, а сельское – уменьшилось с 2,3 млн до 1,7 млн. Интенсивная миграция сельского населения обострила кадровую проблему аграрного сектора Татарстана, особенно остро ощущалась в деревнях нехватка кадров высокой квалификации (агрономов, ветеринаров, зоотехников, инженеров и др.).

Сельское хозяйство Татарстана в период «оттепели» лихорадило от бесконечных реорганизаций, периодически проводившихся укрупнений и разукрупнений колхозов, преобразования их в совхозы. Многие реорганизационные меры часто осуществлялись в спешке, без учёта конкретных обстоятельств, при этом игнорировались этнические особенности населённых пунктов. Это нередко вызывало недовольство и жалобы со стороны колхозного крестьянства марийских, чувашских, мордовских, удмуртских деревень, которые попадали в один колхоз с татарскими или русскими сёлами. Главная причина их недовольства, как правило, заключалась в том, что вся административно-хозяйственная и социально-культурная инфраструктура сосредотачивалась в русских или татарских сёлах. Таким образом, борьба с «неперспективными деревнями» привела к протестным настроениям в национальных сёлах.

the new cattle-breeding farms, implement the mechanisation of production processes, and acquire the pedigree productive cattle and poultry stock.

What made the condition of the rural population even more was the campaign aimed at restricting the personal small-holdings of collective, which led not only to aggravation of the food problem in Tatarstan, but also to the destabilisation of the social and economic situation in villages and the large scale migration of the rural population to towns and urban settlements. In the period from 1939 to 1959, the urban population of Tatarstan increased from 600 000 up to 1.2 million, while the rural population decreased from 2.3 million down to 1.7 million. The intensive migration of the rural population aggravated the personnel problem in the agrarian sector of Tatarstan. Especially hard in villages was the situation with the highly qualified personnel (agronomes, veterinaries, zootechnicians, engineers, and so on).

In the period of the “Thaw”, the agriculture of Tatarstan was disorganised by the endless reorganisations, periodical consolidations and downsizing of collective farms, and their transformation into Soviet farms. Many reorganisational measures were often implemented in a hurry, without taking into account the specific circumstances. Besides, ignored were the ethnic peculiarities in the settlements. This often caused discontent of the population and complaints on the part of collective farmers from the Mari, Chuvash, Mordovian, and Udmurt villages, which found themselves being consolidated into one collective farm with the Tatar or Russian villages. The major reason for their dissatisfaction was, as a rule, that the entire administrative, economic, social, and cultural infrastructure was accumulated in Russian or in Tatar villages. This was how the struggle with the “non-promising villages” led to the protests in the ethnic villages.





Яңа торак район. Әлмәт

Новый жилой район. Альметьевск

The new residential district. Almetyevsk

## Социаль үсеш

«Җепшеклек» чоры эре социаль реформалар чоры була. Мәҗбүри дәүләт займнары, урта һәм югары уку йортларында белем алу өчен түләүнең барлык төрләре гамәлдән чыгарыла. Эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне 7 сәгатьлек эш көненә күчерү тәмамлана, бәйрәм алды һәм ял алды көннәрендә ул 2 сәгатькә кыскартыла. 1956 елда эшчеләр һәм хезмәткәрләр өчен – дәүләт пенсияләре, 1964 елда күмәк хуҗалык әгъзалары өчен пенсияләр һәм пособиеләр билгеләнә. Аграр сәясәттәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә колхозчыларның керемнәре дә бераз арта.

«Җепшеклек» чорының иң мөһим социаль казанышларының берсе булып торак йортларның («хрущёвкалар») һәм социаль учреждениеләрнең массакүләм төзелеше тора. 1957 елда Татарстанда, илнең үзәге үрнәгенә ияреп, торак йортларның, мәктәп, хастаханә, балалар бакчалары, клубларның һәм башка биналарның бердәй проектлары кабул ителә. 1959 – 1965 елларда Татарстанда 4 млн кв. м торак төзелә, бу, 1951 – 1955 елларга караганда, 2,2 тапкырга күбрәк. Бу чорда күпчелек шәһәр халкы өчен уңайлыклары булмаган

## Социальное развитие

Период «оттепели» стал временем крупных социальных реформ. Были отменены обязательные государственные займы, все виды платы за обучение в средних и высших учебных заведениях. Завершился перевод рабочих и служащих на 7-часовой рабочий день, в предпраздничные и предвыходные дни он был сокращён на 2 часа. В 1956 г. были установлены государственные пенсии для рабочих и служащих, в 1964 г. – пенсии и пособия для членов колхозов. Благодаря изменениям в аграрной политике несколько увеличились и доходы колхозников.

Одним из наиболее значимых социальных достижений периода «оттепели» стало массовое строительство жилья («хрущёвок») и социальных учреждений. В 1957 г. в Татарстане, вслед за центром, были приняты единые типовые проекты жилых домов, школ, больниц, детских садов, клубов и других зданий. В 1959 – 1965 гг. в Татарстане было построено 4 млн кв. м жилья, в 2,2 раза больше, чем в 1951 – 1955 гг. В этот период для многих горожан переезд из неблагоустроенных коммуналок, общежитий и бараков в отдельные благоустроенные квартиры стал счастливой реальностью.

## Social Development

The period of the “Thaw” became the time of large-scale social reforms. The mandatory government loans were abolished, just line all kinds of payments for education at secondary schools and institutions of higher education. The transfer of workers and employees for 7 hour working day was completed; the working days that fell on the days before holidays and before week-ends were made shorter by 2 hours. In 1956, state pensions were introduced for workers and employees. In 1964, pensions and subsidies were introduced for members of collective farms. The changes in the agrarian policy helped to somewhat increase the incomes of collective farmers.

The mass residential construction (the building of the so-called Khrushchev’s residential houses) and of social buildings became one of the most important social achievements of the period of the “Thaw”. In 1957, Tatarstan, following the example of the central authorities, adopted the uniform standard designs of residential houses, schools, hospitals, kindergartens, clubs, and other buildings. In 1959 – 1965, Tatarstan built over 4 million square metres, which was 2.2 times more than



Әлмәт. Маяковский урамына тәүге мәртәбә асфальт җәю. 1950 еллар

Альметьевск. Первый асфальт на ул. Маяковского. 1950-е

Almetyevsk. The first asphalt on the Mayakovsky Street. 1950s

коммуналь фатир, тулай торак һәм бараклардан аерым фатирларга күчү бәхетле чынбарлыкка әйләнә. Җиһазлар, радиоалгычлар, телевизорлар, суыткычлар, кер юу машиналары һәм башка катлаулы хуҗалык-көнкүреш әйберләре җитештерү халыкның арта барган ихтыяҗларын канәгатьләндерергә җитмәсә дә, халыкка көнкүреш һәм мәдәни-көнкүреш әйберләре сату бу елларда 2 – 3 тапкырга арта. Ул вакытта коммунистик көнкүрешнең аерым бер элементы буларак каралган җәмәгать туклануы системасы киң үсеш ала.



Шәһәрнең үзәк мәйданы. Әлмәт, 1950 еллар

Центральная городская площадь. Альметьевск, 1950-е

The city central square. Almetyevsk, 1950s



Мәдәният йорты. Бөгелмә шәһәре, 1958

Дом культуры. Бугульма, 1958

Recreation centre. Bugulma, 1958



Әлмәттә стадион төзелеше

Строительство стадиона в Альметьевске

Construction of a stadium in Almetyevsk

Несмотря на то, что производство мебели, радиоприёмников, телевизоров, холодильников, стиральных машин и других сложных коммунально-бытовых изделий не поспевало за возросшими потребностями населения, продажа предметов бытового и культурно-бытового назначения в эти годы увеличилась в 2 – 3 раза.

Широкое развитие получила система общественного питания, в то время рассматривавшаяся как особый элемент коммунистического быта. Причём важной социальной задачей считалось максимальное освобождение женщин от домашнего труда, чтобы они имели большую возможность участвовать в общественной жизни. С этой целью строились кафе, пельменные, блинные, кулинарии, внедрялись новые формы бытового обслуживания. На предприятиях общественного питания в Казани, Альметьевске, Бугульме, Зеленодольске и других городах получили распространение самообслуживание клиентов, отпуск блюд на дом по сниженным ценам, продажа полуфабрикатов и кулинарных изделий. В этот период появились первые

in 1951 – 1955. That period became the happy time for many families and town dwellers, who moved from their multifamily units, residential hotels, and barracks without modern conveniences to separate flats will all necessary amenities.

Despite the fact that the production of furniture, radio receivers, TV-sets, refrigerators, washing machines, and other complex household appliances could not catch up with the growing needs of the population, the sales of goods of household and cultural purposes grew 2 – 3 times those years.

Rapidly developing at that period was the system of public catering, which was considered as a special element of the Communist way of living. The liberation of women from house labour was considered to be an important social goal aimed at providing them with more spare time to take part in the social life. Built for this purpose were cafes, snack-bars, pancake houses, cookeries; the new forms of внедрялись новые формы public services were being introduced. Public catering establishments in Kazan, Almetyevsk, Bugulma, Zelenodolsk, and other towns were broadly introducing self-service of clients, dispatch of dishes to houses at reduced prices, and sales of semi-finished food and culinary products. The first



Көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты бинасы. Әлмәт

Здание комбината бытового обслуживания. Альметьевск

The building of a service centre. Almetyevsk



Милли ашлар кафесы. Әлмәт, 1960

Кафе национальных блюд. Альметьевск, 1960

National cuisine cafe. Almetyevsk, 1960



Казанда Бауман урамындагы «Ёлочка» кафесы, 1967

Здание кафе «Ёлочка» на ул. Баумана в Казани. 1967

The building of “Yolochka” Café on Bauman Street in Kazan. 1967



Көндәлек тормышта телевизорлар пәйда була

В быт входит телевизор

TV-set entering everyday life

Өстәвенә, иҗтимагый тормышта катнашырга зур мөмкинлекләре булсын өчен, хатын-кызларны өй хезмәтеннән максималь азат итү мөһим социаль бурыч булып санала. Шул максат белән кафелар, пилмән, коймак, кулинария ризыклары пешерү йортлары төзелә, көнкүреш хезмәте күрсәтүнең яңа формалары кертелә. Казан, Әлмәт, Бөгелмә, Яшел Үзән һәм башка шәһәрләрнең җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатып алучыларга үз-үзләренә хезмәт күрсәтү, түбән бәяләрдән өйгә ризык җибәрү, ярымфабрикатлар һәм кулинария ризыклары сату киң тарала. Бу чорда хатын-кызлар өчен беренче салоннар, ателье һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүнең комплекслы комбинатлары барлыкка килә. «Җепшеклек» чорының казанышларыннан сәламәтлек саклау һәм халык мәгарифенең матди җирлеген ныгытуны, сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре санын арттыруны күрсәтергә мөмкин. 1958 – 1964 елларда Татарстанда 2 800 урынга хастаханәләр, 1 меңнән артык кибет, ашханә һәм кафе, 206 мең укучыга исәпләнгән 1 меңнән артык мәктәп сафка бастырыла.

женские салоны, ателье и комплексные комбинаты бытового обслуживания. Несомненными достижениями периода «оттепели» были укрепление материальной базы здравоохранения и системы народного образования, увеличение числа предприятий торговли, общественного питания, бытового обслуживания. В 1958 – 1964 гг. в Татарстане вошли в строй больницы на 2800 койко-мест, свыше 1 тыс. магазинов, столовых и кафе, более 1 тыс. школ на 206 тыс. ученических мест.

women's salons, dress-making and tailoring establishments, and integrated service centres were opened in that period. Among the obvious achievements of the period of the "Thaw" was the improvement of the material base of the public health system and the system of public education, increase in number of retail facilities, public catering establishments, of service centres. In 1958 – 1964, put into operation in Tatarstan were hospitals for 2 800 beds, over one thousand shops, canteens, and cafes, over one thousand schools for 206 000 pupils.



24 нче мәктәп укучылары хезмәт дәресендә

Ученики школы № 24 на уроке труда

Pupils of School No 24 during the shop class



Авылның социаль үсешендә дә кечкенә булса да уңай үзгәрешләр күзәтелә. Мәктәпләр һәм клублар төзелеше дә җанлана: бу максатларда хуҗалыкларга махсус кредитлар бирелә башлый. Җидееллык эчендә республикада 90 меңгә якын колхозчы гаиләсе өй туе үткәрә. Авылларда фельдшер пунктлары, балалар бакчалары, махсуслаштырылган кибетләр һәм социаль инфраструктураның башка объектлары төзелә башлый. Әмма авылның да, шәһәрнең дә социаль өлкәсендәге үзгәрешләре Татарстанның икътисади модернизациясе темпларына туры килми.

Небольшие положительные сдвиги происходили и в социальном развитии села. Оживилось строительство школ и клубов: для этих целей хозяйствам стали выделять специальные кредиты. За годы семилетки новоселье справили около 90 тыс. семей колхозников республики. В деревнях начали строить фельдшерские пункты, детские сады, специализированные магазины и другие объекты социальной инфраструктуры. Однако изменения в социальной сфере как села, так и города не соответствовали темпам экономической модернизации Татарстана.

Small, though positive changes were taking place in the social development of village. The construction of schools and clubs was intensified in the rural areas: special loans were offered for these purposes to rural enterprises. Some 90 000 families of the republic's collective farmers moved to new dwellings over the years of the seven-year plan. Built in villages were feldsher's stations, kindergartens, specialised stores, and other social infrastructure facilities. However, the changes in the social sphere both in villages and in towns did not correspond to the pace of economic modernisation of Tatarstan.



Октябрь районының Яңа Әлмәт авылында урта мәктәп төзелеше

Строительство средней школы в селе Ново-Альметьево Октябрьского района

Construction of a secondary school in the village of Novo-Almetyevo of the Oktyabrsky District



Баулы районының Кәрәкәшле авылы Мәдәният йорты

Дом культуры села Каркашли Бавлинского района

Karkashli of the Bavlinsky District



Балалар бакчасы. Береле җәнлек совхозы

Детский сад. Бирюлинский зверосовхоз

Kindergarten. Biryuli State Fur Farm

## Мәдәни үсеш үзенчәлекләре

«Җепшеклек» чорының рухи мохите Сталин заманнары атмосферасыннан шактый аерыла. Демократия башлангычлары татар җәмәгатьчелегендә милли сәясәттәге үзгәрешләргә өмет уята. Бу чорда галимнәр һәм иҗат әһелләре үз халкы традицияләрен торгызу, аның мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү өчен актив чыгыш ясый башлыйлар. Иң радикаль таләпләрне татарларның мәдәни яңарышын Татарстанга союздаш республика статусы бирү белән бәйләп караган милли зыялылар яңгырата (Г. Кашшаф, Н. Фәттах һ. б.).

Татарстанның интеллектуаль-иҗади җәмәгатьчелеген татар теле язмышы да борчый, чөнки 1950 елда аның кулланылыш өлкәсе бик тиз тарая. Республика шәһәрләрендә халык санының тиз арта баруы шәһәрдәге татарлар арасында интернационалистик һәм этнонигилистик карашларны көчәйтә. Рус теленең роле көчәю белән бергә, шәһәрләрдә милли мәктәпләрнең абруе кинәт кими башлый. 1958 елда Казан шәһәрендә татар укучыларының 80 проценты рус гомуми белем бирү йортларында белем ала, чөнки шәһәрдә 2 татар һәм 17 катнаш шәһәр мәктәбе генә эшли. 1950 еллар ахырына милли мәктәпнең дәрәҗәсе Татарстанның башка шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә дә бик тиз түбәнәя башлый, нәтиҗәдә татар мәктәпләрендә белем алучы балалар саны берничә мәртәбәгә кими.

Татар теле, татар мәктәбе белән бәйле вазгыять республиканың кайбер дәүләт һәм партия эшлеклеләрендә дә борчу уята. Аларның хәлне үзгәртергә омтылуы 1957 елда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре итеп куелган С. Д. Игнатьев тарафыннан хуплана. 1958 елның маенда КПСС өлкә комитетының чираттан тыш пленумы була, аның карарларында рус телен һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын кискен арттыруны тәэмин итү, татар мәктәпләренең матди-техник, укыту-методик базасын ныгыту, укытучылар составын яхшырту күздә тотыла. Шулай ук абитуриентлар теләге буенча югары уку йортларына һәм техникумнарга кабул итү имтиханнарын татар телендә оештыру күздә тотыла. Татар телен камилләштерү буенча терминологик комиссия эше яңартыла, 1958 елда мәдәният хезмәткәрләренең 1 нче корылтае һәм башка чаралар үтә. Алар милли мәктәпне саклап калу һәм үстерүгә яңа этәргеч бирәләр, татар теле һәм әдәбияты, мәдәният һәм сәнгать үсешенең яңа юнәлешләрен билгелиләр.

Әмма тиздән милли мәктәпкә карата башка мөнәсәбәт туа. 1960 елның гыйнварында КПСС Үзәк Комитеты күрсәтмәсе буенча Татарстан өлкә комитеты пленумы, бернинди фикер алышмыйча, элеккеге карарын гамәлдән чыгара. Шул ук елда

## Особенности культурного развития

Духовная атмосфера периода «оттепели» существенно отличалась от атмосферы сталинских времён. Либеральные посылы демократизации пробудили у татарской общественности надежду на изменения в национальной политике. В этот период учёные и творческие деятели начали активно выступать за возрождение традиций своего народа, полноценное развитие его культуры и искусства. Наиболее радикальные требования исходили от отдельных представителей национальной интеллигенции, которые связывали культурное возрождение татар с предоставлением Татарстану статуса союзной республики (Г. Кашшаф, Н. Фаттах и др.).

Интеллектуально-творческую общественность Татарстана тревожила и судьба татарского языка, поскольку в 1950-е гг. сфера его применения стремительно сужалась. Быстрый рост городского населения в республике усиливали интернационалистские и этнонигилистические настроения среди татар-горожан. Вместе с усилением роли русского языка стал резко снижаться авторитет национальных школ в городах. В 1958 г. в Казани 80 % школьников-татар обучались в русских общеобразовательных учебных заведениях, поскольку в городе функционировали только 2 татарские и 17 смешанных городских школ. К концу 1950-х гг. значение национальной школы стало быстро понижаться и в других городах и районных центрах Татарстана, в результате количество детей, обучающихся в татарских школах, сократилось в несколько раз.

Ситуация с татарским языком, татарской школой вызывала обеспокоенность и у ряда государственных и партийных деятелей республики. Их стремление изменить ситуацию было поддержано первым секретарём Татарского обкома КПСС С. Д. Игнатьевым, возглавившим его в 1957 г. В мае 1958 г. состоялся внеочередной пленум обкома КПСС, в решениях которого предусматривались обеспечение резкого повышения качества преподавания русского языка и литературы, укрепление материально-технической, учебно-методической базы татарских школ, улучшение состава преподавателей. Намечалась также, по желанию абитуриентов, организация приёмных экзаменов в вузы и техникумы на татарском языке. Возобновила работу терминологическая комиссия по совершенствованию татарского языка, в 1958 г. прошёл 1-й съезд работников культуры и другие мероприятия, давшие новый импульс для сохранения и совершенствования национальной школы и определившие новые векторы развития татарского языка и литературы, культуры и искусства.

## Peculiarities of Cultural Development

The spiritual atmosphere of the period of the “Thaw” was significantly different form that of the Stalin’s period. The liberal calls for democratisation induced with the Tatar society the hope for changes in the ethnic policy. Scientists and creative personalities began to actively advocate for revival of traditions of their people, for full development of their culture and art. The most radical demands came from certain representatives of the Tatar national intelligentsia, who connected the cultural revival of the Tatars with the provision of Tatarstan with the status of a Union Republic (G. Kashshaf, N Fattakh, and so on).

The intellectual and creative community of Tatarstan was also concerned about the fate of the Tatar language, since the range of its application was shrinking in the 1950s. The rapid growth of the urban population in the republic was intensifying the internationalist and ethno-nihilistic spirit among the urban Tatars. While the role of the Russian language was growing, the authority of the ethnic schools began to rapidly lose its weight in towns. In 1958, 80 per cent of the Tatar schoolchildren in Kazan were taught in Russian general education schools, since there were only 2 Tatar and 17 mixed city schools in the city. By the end of the 1950s, the significance of the ethnic school began to decrease rapidly in the other towns and district centres of Tatarstan as well. As a result, the number of children at the Tatar schools reduced several times.

The situation with the Tatar language and the Tatar school also raised concerns with a number of the government and Party leaders of the republic. Their aspiration to change the situation was supported by S. D. Ignatyev, the First Secretary of the Tatar Regional Committee of the CPSU, who was appointed to this post in 1957. An extraordinary plenary session of the Regional Committee of the CPSU was organised in May 1958; its decisions envisioned the drastic improvement of quality of teaching the Russian language and literature, enhancement of material, technical, and academic base of the Tatar schools, improvement of quality of teachers. Considering the wishes of the school leavers, it was supposed to organise the possibility to pass admission exams in the Tatar language at institutions of higher education and at vocational schools. He resumed the work of the terminological commission for the further perfection of the Tatar language; in 1958, the First Congress of Cultural Workers was held, as well as other vents that gave a new impetus to the preservation and further development of the ethnic school and determined the new trends in the development of the Tatar language, literature, culture, and art.



Г. Кашшаф, әдәби тәнкыйтьче, әдәбият белгече

Г. Кашшаф, литературный критик, литературовед

G. Kashshaf, literary critic, historian of literature



Н. Фәттах, язучы

Н. Фаттах, писатель

N. Fattakh, writer



Арча районының К. Маркс исем. колхозының бию коллективы. Аның составында – марилар, руслар, татарлар

Танцевальный коллектив колхоза им. К. Маркса Арского района. В составе марийцы, русские, татары

Dancing group of the Collective Farm n.a. K. Marx in the Arsky District. The group unites the Mari, Russians, and the Tatars


ДЕКАДА ТАТАРСКОГО ИСКУССТВА и ЛИТЕРАТУРЫ

Татар сәнгате һәм әдәбияты үнкөнлегенең программасы. 1957, май – июнь

Программа Декады татарского искусства и литературы. Май – июнь 1957

The programme of the Decade of the Tatar art and literature. May – June 1957

The opening, in January 1987, of the new building of the Tatar Academic Theatre n. a. G. Kamal became a notable event in the cultural life of Tatarstan and the Tatar people. A considerable influence on the development of the theatrical art in Tatarstan was extended by activity of stage director M. Salimzhanov. It was under his leadership that the Tatar Academic Theatre became one of the leading theatre companies of the USSR. The performances that he staged, “Blue Shawl”, “Extinct Stars” by K. Tinchurin, “Almandar from Aldermysh” by T. Minnullin, became notable events of the All-Russia’s scale. The works created by the Tatar musical professionals and masters of theatrical art became property of all peoples of Russia and foreign countries, were awarded by numerous awards at the Tatarstan’s, All-Russian, and international competitions.

1987 елның гыйнварында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасын ачу Татарстан һәм татар халкының мәдәни тормышында мөһим вакыйга була. Татарстанда театр сәнгатен үстерүгә режиссёр М. Сәлимҗанов эшчәнлеге зур йогынты ясый, аның җитәкчелегендә Татар дәүләт Академия театры СССРның алдынгы театр коллективлары рәтенә баса. К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакльләре гомумроссия күләмендә танылу ала. Татар музыка эшлеклеләре һәм сәхнә сәнгате осталары әсәрләре, Россия һәм чит илләрдә танылып, республика, бөтенроссия һәм халыкара конкурсларда бүләкләргә лаек була.

Н. Әюпов, драма актёры

Н. Аюпов, драматический актёр

N. Ayupov, drama actor





Г. Кайбицкая, актриса, җырчы

Г. Кайбицкая, актриса, певица

G. Kaibitskaya, actress, singer



Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры бинасы

Здание Татарского государственного Академического театра им. Г. Камала

The building of the G. Kamal Tatar State Academic Theatre



«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән күренеш, 1976. Әлмәндәр – Ш. Биктимеров, Илсур – А. Ишмуратова, Әҗәл – Р. Шәрафиев

Сцена из спектакля «Старик из деревни Альдермеш», 1976. Альмандар – Ш. Биктемиров, Ильсур – А. Ишмуратова, Смерть – Р. Шарафеев

A scene from performance “An Old Man from Village of Aldermesh”, 1976. S. Biktemirov as Almandar, A. Ishmuratova as Ilsur, R. Sharafeyev as Death



М. Сәлимҗанов, драма актёры, режиссёр, педагог, ТР ФА академигы

М. Салимжанов, драматический актёр, режиссёр, педагог, академик АН РТ


M. Salimzhanov, drama actor, stage director, pedagogue, Academician of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan

# ТАТАРСТАН ҮЗГӘРТЕП КОРУ ҺӘМ ХӘБӘРДАРЛЫК ЧОРЫНДА (1985 – 1991)

# ТАТАРСТАН В ПЕРИОД ПЕРЕСТРОЙКИ И ГЛАСНОСТИ (1985 – 1991)

# TATARSTAN DURING THE YEARS OF PERESTROIKA AND GLASNOST (1985 – 1991)





ДЕКЛАРАЦИЯ
О ГОСУДАРСТВЕННОМ СУВЕРЕНИТЕТЕ ТАТАРСКОЙ СОВЕТСКОЙ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОЙ РЕСПУБЛИКИ

Верховный Совет Татарской Автономной Советской Социалистической Республики,

- сознавая историческую ответственность за судьбу многонационального народа республики;

- свидетельствуя уважение к суверенным правам всех народов, населяющих Российскую Федерацию и Союз Советских Социалистических Республик;

- отмечая несоответствие статуса автономной республики интересам дальнейшего политического, экономического, социального и духовного развития ее многонационального народа;

## Иҗтимагый-сәяси тормышны либеральләштерү омтылышлары

1980 еллар уртасына Советлар Союзында хакимиятнең сәяси кризисы критик ноктасына җитә. 1985 елның апрель аенда М. С. Горбачёв үзенең илне кризистан чыгару программасын игълан итә, аны үзгәртеп кору программасы дип атый. Халык канәгатьсезлегенең төп сәбәбе икътисад өлкәсендә, ә зыялыларның канәгатьсезлеге башкача фикер йөртүне тыюда дигән уйлардан чыгып, үзгәртеп коруның төп шигарьләре формалаштырыла: радикаль икътисади реформа, хәбәрдарлык, иҗтимагый тормышны демократияләштерү, фикерләр төрлелегенә юл кую.

1970 – 1980 еллар чигендә совет җәмгыяте тормышындагы торгынлык күренешләре, милли мөнәсәбәтләр өлкәсендәге җитди үзгәртүләр турында рәсми дәрәҗәдә белдерелә. Озак тынлыктан соң сталинизмның җинаятьчел роле хакында моңарчы булмаганча ачыктан-ачык әйтелә. Реабилитацияләү эшләре яңадан торгызыла, һәм ул бик зур масштаблар да үткәрелә. Эре сәяси процессларга караган материалларны өйрәнү аларның барысы да башбаштаклык һәм тупас ялган нәтиҗәсе булганын күрсәтә. «Милләтчел тайпылыш», «солтангалиевче контрреволюцион оешмалар» эшләренә шундый ук бәя бирелә.

## Попытки либерализации общественно-политической жизни


К середине 1980-х гг. политический кризис власти в Советском Союзе достиг критической точки. В апреле 1985 г. М. С. Горбачёв объявил свою программу вывода страны из кризиса, назвав её перестройкой. Исходя из соображений, что главная причина недовольства народа лежит в области экономики, а недовольство интеллигенции вызвано подавлением инакомыслия, были сформулированы основополагающие лозунги перестройки: радикальная экономическая реформа, гласность, демократизация общественной жизни, плюрализм мнений.

На официальном уровне было заявлено о застойных явлениях в жизни советского общества на рубеже 1970 – 1980-х гг., серьёзных деформациях в сфере национальных отношений. С небывалой откровенностью после долгого молчания было сказано о преступной роли сталинизма. Практически был возобновлён и приобрёл огромные масштабы реабилитационный процесс. Изучение материалов по крупным политическим процессам показало, что все они явились следствием произвола и грубой фальсификации. Такая оценка была дана делам по «национал-уклонизму», «султангалиевской контрреволюционной организации».

## Attempts of Liberalisation of Social and Political Life

By mid-1980s, the political crisis of power in the Soviet Union achieved its critical point. In April of 1985 M. S. Gorbachev declared his programme of bringing the country out of crisis and called it Perestroika (restructuring). Based on the idea that the main reason for discontent of the people was in the economic field and that the dissatisfaction of the intelligentsia was caused by oppression of dissidence, the main slogans of Perestroika were formulated: radical economic reform, Glasnost (publicity), democratisation of the public life, and freedom of speech.

It was officially declared of the stagnation in life of the Soviet society that took place at the turn of the 1970s and 1980s and of serious deformations in the field of national relations. With the unprecedented frankness, after the long silence, it was said about the criminal role of Stalinism. Restored on a massive scale was the rehabilitation process. The study of materials on the large-scale political processes showed that they all were the consequence of despotism and clumsy forgery. Such was the estimate that was given to cases related to “national deviations” and “Sultan-Galiev’s counterrevolutionary organisation”.



Г. С. Яфаевның ТАССРга союздаш республика хокукын бирү мәсьәләсен карау тәкъдиме язылган хат. 1978 елның 28 октябре

Письмо Г. С. Яфаева с предложением рассмотреть вопрос о предоставлении ТАССР прав Союзной республики. 28 октября 1978

A letter by G. S. Yafayev with the proposal to consider the issue of granting the TASSR with the status of a Union Republic. 28 October 1978

## Татарстан җәмгыяте суверенитет юлында

Үзгәртеп коруның төп идеяләрен уңай кабул итеп, Татарстанның зыялы җәмәгатьчелеге социализмны модернизацияләүнең чираттагы омтылышы белән канәгать булмый. Үзгәртеп коруга демократияләштерүнең һәм илнең сәяси корылышын яңартуның иҗтимагый-сәяси процессы буларак карап, ул милли яңарыш турындагы тезисны алга сөрә. М. С. Горбачёвның сәяси системаны үзгәртеп кору кирәклеге турында 1988 елның июнендәге белдерүеннән соң озак та үтми, бер төркем татар зыялылары милли оешма – Татар иҗтимагый үзәген төзү инициативасы белән чыга (1989 елның февралендә оеша). Татар халкының милли яңарышы идеяләре барлыкка килгәннән соң аларны халыкка ачыктан-ачык аңлатуга күчү процессы күпкә иртәрәк – Хрущёв «җепшеклеге» заманында ук башланган иде. Хәбәрдарлык, фикерләр төрлелеге һәм күппартиялелек игълан ителү белән, Татарстанда М. Г. Мөлеков җитәкчелегендәге шактый көчле милли-демократик хәрәкәт туды. Аның программасын тәшкил иткән төп бурычлары арасында түбәндәге идеяләр бар иде: татар автономиясенең союздаш республика статусы алуы, икътисади мөстәкыйльлеккә ирешү, чит илләр белән бәйланышларны киңәйтү, республикада татар теленә дәүләт теле статусын бирү.

Башта бу идеяләр Татарстанның күпмилләтле җәмгыятендәге киң катлаулар арасында яклау тапмый, алар өчен, аеруча рус телле җәмәгатьчелек өчен, мөстәкыйль Татар дәүләте булдыру идеясе гайре табигый булып күренә һәм алар тарафыннан Татарстанның СССРдан бүленеп чыгу рәвешендә кабул ителә. Бераздан күпчелек татарстанлылар (татарлар, руслар, чувашлар һ. б.), Татарстанның икътисади мөстәкыйльлегенә ирешү формасы буларак, СССР составында союздаш республика статусын алу идеясенә аңлап карый башлый. Моны ул вакытта ТАССР Министрлар Советы Рәисе булып эшләгән М. Ш. Шәймиев тә яшерми. Күп дистә еллар буе яшәп килгән «идарәче һәм буйсынучы» рәвешендәге иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләрдән тигез хокуклы партнёрлык мөнәсәбәтләренә күчү аның өчен чын мәгънәсендә мантыйкка ярашлы була. Татарстандагы милли яңарыш демократик көчләре һәм дәүләт хакимияте структуралары арасында диалог урнаша башлау шушының белән бәйле.

Татарстанның хакимият структураларындагы фикер юнәлеше үзгәрүдә кадрлар алмашу әһәмиятле роль уйный. 1989 елның февраленнән М. Ш. Шәймиев җитәкләгән КПССның Татарстан өлкә комитетына яшь интеллектуаллар килә. Алар үзгәртеп кору елларында үзләренең актив гражданлык позициясе белән танылa һәм араларында номенклатурадан килүчеләр булмый. Партия һәм иҗтимагый структуралар эшчәнлегендә ачыклык барлыкка килә. Чираттагы

## Татарстанское общество на пути к суверенитету

Восприняв основные идеи перестройки положительно, татарстанская интеллектуальная общественность не удовлетворилась очередной попыткой модернизации социализма. Рассматривая перестройку как общественно-политический процесс демократизации и модернизации политического строя страны, она выдвинула тезис о национальном возрождении. Вскоре после заявления М. С. Горбачёва в июне 1988 г. о необходимости перестройки политической системы группа татарской интеллигенции выступила с инициативой создания своей национальной организации – Татарского общественного центра (образован в феврале 1989 г.). Сам процесс перехода от формирования идей татарского национального возрождения к их легальному разъяснению в массах произошёл гораздо раньше – ещё во времена хрущёвской оттепели. С объявлением гласности, плюрализма мнений и многопартийности в Татарстане сформировалось достаточно сильное национально-демократическое движение во главе с М. А. Мулюковым, среди программных задач которого были следующие идеи: обретение татарской автономией статуса союзной республики, достижение экономической самостоятельности, расширение связей с зарубежными странами, придание татарскому языку в республике статуса государственного.

В начале эти идеи не нашли поддержки среди широких слоёв татарстанского многонационального общества, для которых, особенно для русскоязычной общественности, была непривычной идея создания самостоятельного Татарского государства и воспринималась она как отделение Татарстана от СССР. Вскоре большинство татарстанцев (татар, русских, чувашей и др.) стало относиться с пониманием к идее получения статуса союзной республики в составе СССР как форме достижения экономической самостоятельности Татарстана. Не скрывал этого и М. Ш. Шаймиев, работавший тогда Председателем Совета Министров ТАССР. Для него был вполне логичным переход от существовавших долгие десятилетия общественно-политических отношений «господства и подчинения» к равноправным партнёрским отношениям. С этим связано начало установления диалога в Татарстане между демократическими силами национального возрождения и структурами государственной власти.

Значимую роль в изменении умонастроения в правящих структурах Татарстана сыграли кадровые перестановки. В Татарский обком КПСС, возглавляемый с февраля 1989 г. М. Ш. Шаймиевым, пришли молодые интеллектуалы, которые приобрели известность своей активной гражданской позицией в годы перестройки и не имели номенклатурного прошлого. В деятельности партийных и общественных структур появилась большая открытость. На смену заявлениям об очередных успехах, огромных достижениях приходил критический настрой. В среде интеллектуально-творческой общественности Татарстана развернулись бурные дискуссии вокруг ключевых

## The Tatarstan's Society on the Way to Sovereignty

Having favourably accepted the main ideas of Perestroika, the Tatarstan's intellectual society was still dissatisfied with another attempt of modernisation of Socialism. Considering Perestroika as a social and political process of democratisation and modernisation of the political structure of the country, it moved forward the thesis of national (ethnic) revival. Soon after the statement made by M. S. Gorbachev in June 1988 of necessity of the restructuring of the political system, a group of representatives of the Tatar intelligentsia proposed an initiative on the establishment of their own, national organisation – the Tatar Public Centre (established in February 1989). The very process of transferring from the formation of ideas of the Tatar national revival to their legal explanation en masse began much earlier – at the time of the Khrushchev's Thaw. When publicity, freedom of speech, and multiplicity of parties were declared, a quite strong national-democratic movement emerged in Tatarstan headed by M. A. Mulyukov, its main tasks included, inter alia, the following: granting the status of a Union republic to the Tatar autonomy, making it economically independent, expansion of links with foreign countries, granting the status of an official language to the Tatar language.

At first, these ideas were not supported by broad layers of the Tatarstan's multinational population, to whom, especially to the Russian-speaking community, the idea of establishing an independent Tatar state was unusual and was perceived as secession of Tatarstan from the USSR. However, soon the majority of citizens of Tatarstan (the Tatars, Russians, Chuvashes, and so on) began treating the idea of granting the status of a Union republic to Tatarstan within the USSR with greater understanding considering it as a form of gaining the economic independence for Tatarstan. M. S. Shaimiev, who was Chairman of the Council of Ministers of the TASSR, also shared the same views. To him it was quite logical to shift from the social and political relations of "supremacy and subordination" that lasted for many years towards equal relations based on partnership. This started the dialogue in Tatarstan between the democratic forces of national (ethnic) revival and the structures of the state power.

A significant role in the changing of mentality of the ruling circles of Tatarstan was played by personnel replacements. Young intellectuals came to the Tatar Regional Committee of the CPSU, which was headed, from February 1989, by M. S. Shaimiev. They became well known for their social activism during the years of Perestroika and were not connected with the elite of functionaries of the past. The activity of the Party and public structures became more transparent.



Татар иҗтимагый үзәге Идарәсенең Румыния мөфтие Госман Меджеат һәм Польша республикасының мөселман общинасы рәисе Мостафа Мухарский белән очрашуы

Встреча Правления Татарского общественного центра с румынским муфтием Османом Меджеатом и председателем мусульманской общины Польской республики Мустафой Мухарским

A meeting between the Board of the Tatar Public Centre and Romanian mufti Osman Negeat and Chairman of Muslim community of the Republic of Poland Mustafa Mucharski



уңышлар, зур казанышлар турындагы белдерүләргә алмашка тәнкыйть рухы килеп керә. Татарстанның зыялы-иҗади җәмәгатьчелеге даирәсе төп марксистик-ленинчыл нигезләмәләр тирәсендә, 1917 елгы Октябрь инкыйлабының альтернативалары, социализм төзүнең сталинча калыбы, СССРдагы сәяси репрессияләрнең асылы турында кайнар бәхәсләр алып бара. Барлык тайпылышлар һәм законсызлыклар өчен җаваплылык И. В. Сталинга һәм аның даирәсендәгеләргә генә йөкләнмичә, гомумән, тоталитар режим өстенә төшүе ап-ачык билгеләнә. Моны массакүләм мәгълүмат чаралары һәм киң җәмәгатьчелек күтәреп ала. Иң кискен мәкаләләре белән «Вечерняя Казань», «Комсомолец Татарии» газеталары, «Татарстан» журналы аерылып тора.

1980 еллар ахырындагы демократик процесслар СССРны яңача милли дәүләт буларак төзү

марксистско-ленинских положений, об альтернативах Октябрьской революции 1917 г., сталинской модели построения социализма, природе политических репрессий в СССР. Становилось очевидным, что ответственность за все деформации и беззакония лежит не только на И. В. Сталине и его окружении, но тоталитарном режиме вообще. Это было подхвачено средствами массовой информации и широкой общественностью республики. Наиболее острыми публикациями отличались газеты «Вечерняя Казань», «Комсомолец Татарии», журнал «Татарстан».

Процессы демократизации в конце 1980-х гг. вплотную подвели к проблеме нового национально-государственного устройства СССР. Для ТАССР, как и для многих других автономных республик, центральным являлся вопрос о повышении её политико-правового статуса. В сентябре 1989 г. состоялся

The statements about regular successes and great achievements were substituted by critical vision. Broad discussions were taking place among the intellectual and creative public of Tatarstan about the key Marxist and Leninist issues, about the alternatives for the October Revolution of 1917, the Stalin's model of building Socialism, about the nature of political repressions in the USSR. It was obvious that responsible for all deformations and unlawful acts was not only Stalin and his circle inner, but also the totalitarian regime in general. This idea was supported by mass media and broad layers of population of the republic. The sharpest articles were published by such newspapers as "Vechernyaya Kazan" (The Evening Kazan) and "Komsomolets Tatarii" ("The Young Communist of Tatatria"), and "Tatarstan" magazine.



мәсьәләсенә китереп җиткерә. Башка күп кенә автономияле республикалар кебек үк, ТАССР өчен дә аның сәяси-хокукый статусын күтәрү көнүзәк мәсьәлә була. 1989 елның сентябрь аенда КПСС Үзәк Комитетының милли проблемаларга багышланган пленумы уза, анда ТАССР вәкилләре республиканың кимсетелгән хәле турында сөйли. Шундый ук дәгъвалар башка автономияләрдән килгән катнашучылар тарафыннан да әйтелә. Ләкин бу позиция ул чакта яклау тапмый. Автономияле республикаларның кайберләрен генә булса да союздаш итеп үзгәртеп кору турындагы гамәли карарлар кире кагыла.

Татарстанның хокукларын киңәйтү турындагы мәсьәлә 1989 елның ахырында КПССның Татарстан өлкә комитеты пленумында күтәрелә. Нәтиҗәдә милли күтәрелеш яклылар өчен республика матбугатына, радио һәм телевидениегә үтеп керү мөмкинлеге ачыла.

пленум Центрального Комитета КПСС по национальным проблемам, на котором представители ТАССР говорили об ущемлённом положении республики. Такие же претензии были высказаны участниками пленума из ряда других автономий. Однако эта позиция не нашла тогда поддержки. Практические решения о преобразовании хотя бы некоторых автономных республик в союзные были отклонены.

В конце 1989 г. вопрос о расширении прав Татарстана был поднят на пленуме Татарского обкома КПСС. В результате сторонникам национального возрождения был открыт доступ к республиканской печати, радио и телевидению. У них появились собственные органы печати. Стала выходить газета «Республика» под лозунгом «Невозможно гарантировать права человека вне гарантий прав народов», что придало новый импульс работе

The processes of democratisation of the late 1980s pushed the society very close to the problem of the new national state structure of the USSR. For the TASSR, just like for many other autonomous republics, the central issue was the issue of enhancing its political and legal status. In September 1989, the plenary session of the Central Committee of the CPSU dedicated to national issues was held. During the session, the representatives of the TASSR spoke about the impaired status of the republic. The same claims were aired by other participants of the plenary session from among those who represented other autonomies. However, at that time, their views did not gain support. Practical solutions on the transformation of at least some of the autonomous republics into the Union republics were rejected.

Аларның үз матбугат органнары барлыкка килә. «Халыкларның хокукларын гарантияләмичә, кеше хокукларын гарантияләп булмый» дигән шигарь белән «Республика» газетасы чыга башлый. Газета Татарстандагы һәм аннан читтәге, татарлар туплanып яши торган урыннардагы милли-демократик көчләрнең алга таба берләшеп хәрәкәт итүе өчен ныклы нигез булган үзешчән татар иҗтимагый оешмалары эшенә яңа этәргеч бирә. 1989 ел ахырында – 1990 ел башында республика парламентына халык депутатларын сайлауга әзерлек һәм сайлауларны үткәрү чорында алар үзләрен аеруча актив күрсәтә.

Бер үк вакытта Татарстанның хакимият даирәләрендә республиканың дәүләт суверенитетын игълан итү фикерендә торган команда (М. Г. Сабиров, В. Н. Лихачёв һ. б.) оеша, аны М. Ш. Шәймиев җитәкли. 1989 елның 4 ноябрендә ТАССР Югары Советы Татарстан АССР Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында Закон кабул итә, аның нигезендә сайлау системасы демократияләштерелә. Законга сайлауларның альтернативалы һәм сайлау округларының күпмандатлы булуы кертелә. Милли яңарыш яклы демократик хәрәкәтнең һәм дәүләт, сәяси хакимият структураларындагы демократик канатның позицияләрен якынайта торган, халыкта да популяр булган төп шигарь СССР составында Татарстанның мөстәкыйльлеген таләп итү була.

Асылда, милләтчелек белән сугарылмаган мөстәкыйльлек күпмилләтле Татарстан халкын канәгатьләндерә һәм аларда яклау таба. Мөстәкыйльлек таләп итү сепаратизм күренешләреннән азат була, җимерү максатыннан эшләнми, чын Россия демократиясе тарафыннан уңай кабул ителә һәм яклана. Ортодоксаль коммунистлар ул вакытта алга сөргән унитаризм фикере белән мөстәкыйльлек берничек тә үзара яраша алмый. 1990 елның язында ТАССР Югары Советына сайлауларга «СССР һәм Россия составында Татарстанның дәүләт суверенитеты өчен» шигаре белән барган берләшкән демократик көчләрнең «Бердәм социалистик Союз өчен», «Бердәм социалистик Россия өчен» лозунгларын күтәргән унитаризм тарафдарларын ышанычлы җиңүе моны ачык дәлилли.

1990 елның апрелендә 12 нче чакырылыш ТАССР Югары Советының беренче сессиясе уза, аның беренче утырышында Югары Совет Рәисе постына 3 кандидатура чыгарыла: КПССның Татарстан өлкә комитетының 1 нче секретаре М. Ш. Шәймиев, язучы Ф. Ә. Бәйрәмова («Иттифак» партиясе) һәм Казан университеты доценты М. Г. Мөлеков (Татар иҗтимагый үзәге). Тавыш бирү барышында 70 % тан артык тавыш якын киләчәктә Татарстанның

самодеятельных татарских общественных организаций, ставших крепкой основой для дальнейшей консолидации национально-демократических сил в Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар. Наиболее активно они проявили себя в период подготовки и проведения выборов народных депутатов в республиканский парламент в конце 1989 – начале 1990 г.

Одновременно во властной структуре Татарстана сформировалась ориентированная на провозглашение государственного суверенитета Татарстана команда в главе с М. Ш. Шаймиевым (М. Г. Сабиров, В. Н. Лихачёв и др.). 4 ноября 1989 г. Верховный Совет ТАССР принял Закон об изменениях в Конституции Татарской АССР, демократизировавший избирательную систему. В ней предусматривались альтернативность выборов и многомандатность избирательных округов. Главным лозунгом, сблизившим позиции демократического движения за национальное возрождение и демократического крыла в структурах государственной и политической власти, стало популярное в народе требование самостоятельности Татарстана в составе СССР.

В сущности, самостоятельность, не отягощённая национализмом, удовлетворяла многонациональное население Татарстана и поддерживалась им. Требование самостоятельности, свободное от проявлений сепаратизма, не было разрушительным, позитивно воспринималось и поддерживалось истинной российской демократией. Несовместима была самостоятельность с унитаризмом, который отстаивали тогда ортодоксальные коммунисты. Об этом ярко свидетельствовала убедительная победа объединённых демократических сил, шедших на выборы в Верховный Совет ТАССР весной 1990 г. с лозунгом «За государственный суверенитет Татарстана в составе СССР и России», над сторонниками унитаризма с лозунгами «За единый социалистический Союз», «За единую социалистическую Россию».

В апреле 1990 г. состоялась 1-я сессия Верховного Совета ТАССР 12-го созыва, на первом её заседании на пост председателя Верховного Совета были выдвинуты 3 кандидатуры: первый секретарь Татарского обкома КПСС М. Ш. Шаймиев, писательница Ф. А. Байрамова (партия «Иттифак») и доцент Казанского университета М. А. Мулюков (Татарский общественный центр). В ходе голосования свыше 70 % голосов было отдано за кандидатуру М. Ш. Шаймиева, впоследствии ставшего политическим лидером Татарстана и определившего пути суверенизации республики.

Используя противоречия между союзными и российскими властными структурами, руководство Татарстана всё настойчивее добивалось повышения государственного статуса республики. Этот вопрос неоднократно ставился

At the end of 1989 the issue on the extending of rights of Tatarstan was raised at a plenary session of the Tatar Regional Committee of the CPSU. As a result, the advocates of the national revival got access to the republic's press, radio, and television. They established mass media of their own. The newspaper titled "Respublika" began to be published under the slogan "It is impossible to guarantee human rights without guaranteeing the rights of peoples" that gave a new impetus to the work of self-regulated Tatar public organisations, which became a solid basis for further consolidation of national-democratic forces in Tatarstan and beyond its borders, in the regions with the Tatar communities. They most actively showed themselves at the time of preparation and holding of elections of people's deputies to the republic's parliament at the end of 1989 and early 1990.

At the same time, there appeared a group of leaders in the bodies of government in Tatarstan that stood for declaring the state sovereignty of Tatarstan. Such group was headed by M. S. Shaimiev (M. G. Sabirov, V. N. Likhachev, and so on). On 4 November 1989, the Supreme Council of the TASSR adopted the Law on the changes in the Constitution of the Tatar ASSR, which democratised the election system. It envisioned the alternativeness of elections and multi-mandate nature of the election districts. The main slogan that brought closer the positions of the democratic movement for national revival and the democratic wing in the structures of the state and political power became the demand for independence of Tatarstan within the USSR, which was quite popular among people.

In fact, the independence, not overburdened by nationalism, satisfied the multi-national population of Tatarstan and was supported by it. The call for independence, free from manifestations of separatism, was not destructive, was perceived favourably and supported by the true Russian democracy. Independence was incompatible with unitarianism, which was advocated at that time by the orthodox communists. This was evidenced by the convincing victory of the united democratic forces that were heading into election to the Supreme Council of the TASSR in spring of 1990 under the slogan "For state sovereignty of Tatarstan within the USSR and Russia" over the advocates of unitarianism with their slogans "For consolidated Socialist Union" and "For consolidated Socialist Russia". In April 1990, there was held the first session of the Supreme Council of the TASSR of the 12th convocation. Its first meeting proposed 3 nominees to the post of Chairman of the Supreme Council: M. S. Shaimiev, the First Secretary



Б. Н. Ельцин Казанда. 1990, август

Б. Н. Ельцин в Казани. Август 1990

B. N. Yeltsin in Kazan. August 1990

«Вечерняя Казань» газетасы, 1990, 12 июль, №45

Газета «Вечерняя Казань», 1990, 12 июля, № 45

The Vechernyaya Kazan Newspaper, 1990, 12 July, No 45


Вечерняя Казань

КТО «ДЕЛАЕТ ПОГОДУ»

Поезд ушел?


Республике — статус союзной

СПАСТИ РОДНОЙ ЯЗЫК

ПАРТИЙНЫЕ ИДЕОЛОГИ – ДЕТЯМ!

сәяси лидерына әйләнәчәк һәм республиканың суверенлык юлларын билгеләячәк М. Ш. Шәймиев кандидатурасы өчен бирелә.

Союз һәм Россия хакимият структуралары арасындагы каршылыклардан файдаланып, Татарстан җитәкчелеге республиканың дәүләт статусын күтәрүгә тагын да ныграк басым ясый. Бу мәсьәлә берничә тапкыр Мәскәүдәге төрле хакимият структураларында көн тәртибенә куела һәм иң югары постын Б. Н. Ельцин билгәгән Россия җитәкчелегендә билгеле дәрәҗәдә хуплау таба. Ул, РСФСР Югары Советы Рәисе буларак, үзенең КПСС Үзәк Комитеты генераль секретаре М. С. Горбачёвка һәм аның даирәсендәгеләргә каршы сәяси көрәшендә Татарстанны кулланырга, РСФСР халык депутатлары корылтаенда Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәннән соң (1990 елның 12 июне) какшаган позициясен ныгытырга тырыша. 1990 елның 5 августында Татарстанга визиты вакытында Б. Н. Ельцин республиканың барлык массакүләм мәгълүмат чаралары аша таралган гыйбарәсен әйтә: «Суверенитетны никадәр йота аласыз, шулкадәр алыгыз». Шул ук вакытта ул татарстанлыларны өметләндерә дә: «Татарстан АССР үзе өчен нинди генә бәйсезлекне сайласа да, без хуплаячакбыз... Минем әйтәсем килә: әгәр үзегез белән үзегез идарә итәргә телисез икән, моңа керешегез». Мондый хуплау сүзләре Татарстан сәяси җитәкчелегенең һәм демократик көчләрнең рухын күтәреп кенә калмый, консерватив «союз» оппозициясенә айнытып җибәрерлек тәэсир ясый. Өстәвенә, 1990 елның 9 августында – Коми АССР, 29 августта Карелия АССР үзләренең дәүләт суверенлыгы турында декларацияләр игълан итә.



И. Р. Таһиров, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре докторы, ТР ФА академигы

И. Р. Тагиров, историк, общественный деятель, доктор исторических наук, академик АН РТ

I. R. Tagirov, historian, public figure, Doctor of Historical Sciences, Academician of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan

им в различных властных структурах в Москве и нашёл определённую поддержку в российском руководстве, возглавляемом Б. Н. Ельциным. Он, будучи председателем Верховного Совета РСФСР, попытался использовать Татарстан в своей политической борьбе против генерального секретаря ЦК КПСС М. С. Горбачёва и его ближайшего окружения, укрепить своё пошатнувшееся положение после принятия на съезде народных депутатов РСФСР Декларации о государственном суверенитете Российской Советской Федеративной Социалистической Республики (12 июня 1990 г.). Во время визита в Татарстан 5 августа 1990 г. Б. Н. Ельцин произнёс облетевшую все республиканские средства массовой информации фразу: «Берите суверенитета столько, сколько вы его сможете проглотить». При этом он обнадёжил татарстанцев: «Мы будем приветствовать любую независимость, какую Татарская АССР изберёт для себя... Я хочу сказать: если хотите управлять собой сами, то приступайте». Эти слова поддержки не только приподняли дух политического руководства Татарстана и демократических сил, но и оказали отрезвляющее действие на консервативную «союзную» оппозицию. К тому же 9 августа 1990 г. декларацию о своём государственном суверенитете провозгласила Коми АССР, 29 августа – Карельская АССР.

of the Tatar Regional Committee of the CPSU, F. A. Bairamova, a writer (representing the Ittifaq Party), and M. A. Mulyukov, an associate professor of Kazan University (from the Tatar Public Centre). Over 70 % of votes during the elections were given to M. S. Shaimiev. Later, it was he who became the political leader of Tatarstan and determined the ways of ensuring sovereignty of the republic.

Using the contradictions between the Union and Russian power structures, the leadership of Tatarstan took more and more persistent measures to enhance the state status of the republic. This issue was raised again and again at different levels of state power in Moscow and found a certain support with the Russian leadership that was headed by B. N. Yeltsin. Being the Chairman of the Supreme Council of the RSFSR, he was trying to use Tatarstan in his political struggle against Secretary General of the Central Committee of the CPSU Mikhail Gorbachev and his inner circle, thus consolidating his shattered positions after the adoption by the Congress of People's Deputies of the Declaration of State Sovereignty of the Russian Soviet Federative Socialist Republic (12 June 1990). During his visit to Tatarstan on 5 August 1990, B. N. Yeltsin said the phrase that was cited by all mass media of the republic: "Take as much sovereignty as you can swallow". Having said that, he also encouraged the citizens of Tatarstan: "We will encourage any independence, which the Tatar ASSR will choose for itself... I want to say: if you want to administer yourselves independently, then do it". These words not only lifted the spirits of the political leadership of Tatarstan and the democratic forces, but also disillusioned the conservative "pro-Union" opposition. Besides, on 9 August 1990, the Declaration of State Sovereignty was adopted by the Komi ASSR, and – on 29 August – by the Karelian ASSR.

## Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турындагы декларация

1990 елның 30 августында Татарстанның ХХ гасырның икенче яртысындагы тарихында иң истәлекле вакыйга була. Бу көнне ТАССР Югары Советы сессиясендә Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында декларация кабул ителә. 242 депутатның 241е риза булып тавыш бирә, бер кеше тыелып кала. Югары Совет утырышы барган бина янындагы Ирек мәйданына җыелган халык шатлык-куаныч белдерә.

Декларация кабул итү ТАССРның ТССРга – Татарстан Республикасына үзгәрүен белдерә. Декларация: «Татарстан ССР территориясендәге җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора», – дип раслый, шулай ук анда «татар һәм рус телләренең дәүләт теле сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү» гарантияләнә. «Автономияле республика статусының аның күпмилләтле халкының киләчәктә сәяси, экономик, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен» тану һәм «демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып, татар милләтенең, республикада яшәүче бөтен халыкның үзбилгеләнүгә булган аерылгысыз хокукын тормышка ашыру» теләге декларациянең төп пунктлары булып тора. Шуның белән бергә, декларация Татарстан Республикасының субъектлылыгын билгеләми. Башкача әйткәндә, анда Татарстан союздаш республика булачакмы, әллә сүз Россия Федерациясе кысаларында суверен хокукларны билгеләү турында гына барамы дигән мөһим сорауга анык җавап юк. Әлеге компромисс республикадагы иҗтимагый-сәяси хәлне тотрыклыландыру мөмкинлеге биреп кенә калмый, Татарстанның күзгә күренеп икътисади һәм мәдәни җәһәттән күтәрелүенә, мөһим социаль мәсьәләләрне хәл итүгә дә уңай тәэсир ясый.


Декларация кабул итү Татарстан АССРның сәяси һәм икътисади статусы мәсьәләләрендә карашларның үзгәрүе өчен этәргеч мизгел була, чөнки ул республикадагы күпмилләтле халыкның иҗтимагый һәм этник аңында тирән үзгәрешләр китереп чыгара. 30 август Татарстан Республикасының дәүләт бәйрәменә әйләнә, ул ел саен тантаналы чаралар, халыкның бергәләп урамнарда ял итүе, күңел ачуы һәм бәйрәм салюты белән билгеләп үтелә.


## Декларация о государственном суверенитете Республики Татарстан

30 августа 1990 г. произошло одно из самых знаменательных событий в истории Татарстана второй половины ХХ в. В этот день на сессии Верховного Совета ТАССР была принята Декларация о государственном суверенитете республики. Из 242 депутатов за неё проголосовал 241 человек при одном воздержавшемся. Народ, собравшийся на площади Свободы у здания, где заседал Верховный Совет, ликовал.

Принятие декларации означало преобразование ТАССР в ТССР – Республику Татарстан. Декларация провозгласила: «Земля, её недра, природные богатства и другие ресурсы на территории Татарской ССР являются исключительной собственностью её народа», а также гарантировала «равноправное сохранение и развитие татарского и русского языков в качестве государственных». Главными пунктами декларации были признание несоответствия «статуса автономной республики интересам дальнейшего политического, экономического, социального и духовного развития её многонационального народа» и желание реализовать «неотъемлемое право татарской нации, всего народа на самоопределение, стремясь создать демократическое правовое государство». Вместе с тем декларация не определяла субъектность Республики Татарстан. Иными словами, в ней не было чёткого ответа на важный вопрос: станет ли Татарстан союзной республикой, или речь идёт только об обозначении суверенных прав в рамках Российской Федерации? Этот компромисс позволил стабилизировать не только общественно-политическую обстановку в республике, но и способствовал её заметному экономическому и культурному подъёму, решению насущных социальных задач.

Принятие декларации стало исходным моментом для мировоззренческой трансформации в вопросах политического и экономического статуса Татарской АССР, поскольку оно произвело глубокие перемены в общественном и этническом сознании многонационального народа республики. 30 августа стало государственным праздником Республики Татарстан, который ежегодно отмечается торжественными мероприятиями, массовыми народными гуляниями и праздничным салютом.





ТССРның Дәүләт суверенитеты турындагы декларация. Казан, 1990

Декларация о государственном суверенитете ТССР. Казань, 1990

Declaration of State Sovereignty of the TSSR. Kazan, 1990

## Declaration of State Sovereignty of the Republic of Tatarstan

On 30 August 1990, one of the most significant events took place in the history of Tatarstan of the second half of the 20th century. On that day, the session of the Supreme Council of the TASSR adopted a Declaration of State Sovereignty of the Republic. Of 242 deputies 241 voted in its favour with only one abstainer. The people who gathered on the Freedom Square near the building of the Supreme Council were in triumph.

The adoption of the Declaration meant the transformation of the TASSR into the TSSR – the Republic of Tatarstan. The Declaration stated that "earth, its entrails, natural and other resources in the territory of the Tatar SSR are the exclusive property of its people", and guaranteed "equal preservation and development of the Tatar and Russian languages as official languages". The main provisions of the Declaration related to the recognition of incompliance of the "status of autonomous republic with the interests of further political, economic, social, and spiritual development of its multi-national people" and the aspiration to implement the "inseparable right of the Tatar nation, of all people for self-determination, wishing to establish a democratic law-abided state". At the same time, the Declaration did not specify the subjectivity of the Republic of Tatarstan. In other words, it did not give the exact answer to the important question: whether the Republic of Tatarstan would become a Union Republic, or whether its sovereign rights within the Russian Federation were meant. That compromise made it possible to stabilise not only the social and political situation in the republic, but also contributed to its notable economic and cultural growth and to the resolution of the urgent social issues.

The adoption of the Declaration became the starting point for the world-view transformation in what referred to issues of political and economic status of the Tatar ASSR, because it induced the deep changes in the social and ethnic self-consciousness of the multi-national people of the republic. The day of 30 August became the public holiday of the Republic of Tatarstan, which is celebrated annually with official events, public festivals, and festive fireworks.

ТССР Дәүләт суверенитеты декларациясен кабул иткән Татарстан АССР Югары Советының 12 нче чакырылыш депутатлары. Казан, 1990, апрель

Депутаты Верховного Совета Татарской АССР 12-го созыва, принявшие Декларацию о государственном суверенитете ТССР. Казань,1990, апрель

Deputies of the Supreme Council of the Tatar ASSR of the 12th convocation who adopted the Declaration of State Sovereignty of the TSSR. Kazan, 1990, April



## Социаль-икътисади үсешне тизләтү программалары

Үзгәртеп коруның башлануы КПСС Үзәк Комитетының 1985 елгы апрель пленумыннан соң була, ул илнең социаль-икътисади үсешен тизләтү курсын игълан итә. Тизләнешкә фәнни-техник алгарыш, машина төзелешен яңадан җиһазландыру һәм кеше факторын активлаштыру хисабына ирешү планлаштырыла. Боларның барысын да бөтен җирдә хезмәт һәм технология дисциплинасын ныгытуга, кадрларның җаваплылыгын арттыруга корылган Андропов курсын дәвам итү юлы белән тормышка ашыру ниятләнә. «Тизләнеш» концепциясе ниндидер радикаль яңалык түгел, ә традицион совет тәҗрибәсе арсеналындагы алымнарны яңача куллану була.

Башлангыч чорында бары тик совет җәмгыятен камилләштерү һәм социализмның «кайбер аерым тайпылышларын» туры юлга бастыру гына күздә тотыла. Моның белән бергә, машина төзелешенә халык хуҗалыгын төзекләндерүнең «төп буыны» роле йөкләнә. Аерым станоклар җитештерүдән китеп, җитештерү комплексларына, сәнәгать роботларына күчү халык хуҗалыгы өчен яңа сыйфаттагы машиналар ясау мөмкинлеге һәм икътисадның интенсивлашуына, фәнни-техник прогресска тизләнеш бирергә тиеш була. Моңарчы яшәп килгән социаль-икътисади системаның аерым җитешсезлекләрен Горбачёв җитәкчелеге тагы берничә эре административ кампания белән төзәтергә тырыша: халык хуҗалыгы үсешен тизләтү, сәнәгать җитештерүен автоматлаштыру һәм компьютерлаштыру, дәүләт кабул итүен кертү, алкогольгә каршы кампания, «хезмәттән тыш керемнәр белән көрәш» һәм коррупциягә каршы көрәш. Соңрак икътисадта ирекле товар-акча мөнәсәбәтләре һәм кооперативлар формасындагы шәхси эшкуарлык законлаштырыла, чит ил компанияләре белән уртак предприятиеләр актив оеша башлый. 1990 – 1991 елларда шәхси милек легальләштерелә, фонд һәм валюта базарлары барлыкка килә, кооперация көнбатыш тибындагы бизнес формасын ала башлый.

Үзгәртеп коруның социаль-икътисади үсешне тизләтүне күздә тоткан Горбачёв программасы Татарстанда уңай кабул ителә. Җирле җитәкчелек (Г. И. Усманов, М. Ш. Шәймиев, Ш. А. Мостаев һ. б.) үзгәртеп кору программасы күрсәтмәләрен республика шартларында тормышка ашыруны үзенең төп бурычы итеп саный. ТАССР Югары Советы, Үзәктән төшерелгән контроль саннарга таянып, 1986 – 1990 елларга республиканың икътисади һәм социаль үсешенең бишьеллык планын кабул итә. Хуҗалыкны һәм социаль өлкәне үстерүнең структурасы һәм төп юнәлешләре үзгәреш кичерми. Моңа кадәр тулаем сәнәгать продукциясенең 45 % ын җитештергән оборона комплексы предприятиеләре

## Программы ускорения социально-экономического развития

Начало перестройке было положено апрельским пленумом ЦК КПСС 1985 г., провозгласившим курс на ускорение социально-экономического развития страны. Ускорения планировалось достичь за счёт научно-технического прогресса, перевооружения машиностроения и активизации человеческого фактора. Всё это намечалось осуществить путём продолжения андроповского курса на повсеместное укрепление трудовой и технологической дисциплины, повышения ответственности кадров. Концепция «ускорения» не была чем-то радикально новым, а представляла собой новое сочетание приёмов из арсенала традиционного советского опыта.

На первых порах предусматривались лишь совершенствование советского общества и выправление «отдельных деформаций» социализма. При этом машиностроению была отведена роль «ключевого звена» реконструкции народного хозяйства. Переход от производства отдельных станков к производственным комплексам, промышленным роботам должен был подвести новый класс машин под народное хозяйство и придать ускорение интенсификации экономики и научно-техническому прогрессу. Отдельные недостатки существовавшей социально-экономической системы горбачёвское руководство пыталось исправить несколькими крупными кампаниями административного характера: ускорение развития народного хозяйства, автоматизация и компьютеризация промышленного производства, введение государственной приёмки, антиалкогольная кампания, «борьба с нетрудовыми доходами» и демонстрация борьбы с коррупцией. Позднее в экономике узаконивают свободные товарно-денежные отношения и частное предпринимательство в форме кооперативов, начинают активно создаваться совместные предприятия с зарубежными компаниями. В 1990 – 1991 гг. легализуется частная собственность, образуются фондовый и валютный рынки, кооперация начинает принимать форму бизнеса западного типа.

Горбачёвская программа ускорения социально-экономического развития перестройки была воспринята в Татарстане положительно. Местный правящий истеблишмент (Г. И. Усманов, М. Ш. Шаймиев, Ш. А. Мустаев и др.) основной своей задачей считали реализацию в условиях республики предписаний перестроечной программы. Верховный Совет ТАССР принял пятилетний план экономического и социального развития республики на 1986 – 1990 гг. исходя из контрольных цифр, спущенных Центром. Структура и основные направления развития хозяйства и социальной сферы не менялись. Предполагалось, что предприятия оборонного комплекса,

## Programmes of Acceleration of Social and Economic Development

The start of Perestroika was given by the April plenary session of the Central Committee of the CPSU in 1985, which declared the course for acceleration of the social and economic development of the country. It was anticipated that the acceleration would be achieved by means of scientific and technical progress, re-equipment of mechanical engineering, and more intensive use of the human factor. All that was supposed to be implemented by continuing the Andropov's course for the total tightening of labour and technological discipline and the strengthening of responsibility of personnel. The concept of "acceleration" was not something radically new, but was a combination of methods from the palette of traditional Soviet experience.

Initially it was expected that the Soviet society would just undergo certain perfection and that "separate deformations" of Socialism would be corrected. In that respect, mechanical engineering was to play the role of a "key element" of reconstruction of the national economy. The transfer from manufacture of individual machine tools towards the manufacture of production complexes and industrial robots was intended to introduce the new class of machines to the national economy and give an impetus to the accelerated intensification of the economy and scientific and technical progress. The Gorbachev's leadership attempted to correct certain drawbacks of the existing social and economic system through several large-scale campaigns of administrative nature: acceleration of development of the national economy, automation and computerisation of industrial sector, introduction of the state inspection, an anti-drinking campaign, "struggle against unearned incomes", and showing the struggle against corruption. Later, legalised in the economy were free commodity/money relations and private entrepreneurship in the form of cooperatives; joint ventures with foreign companies began to be actively established. In 1990 – 1991, private property was legalised; stock and money markets were formed; and cooperation began turning into business of western type.

The Gorbachev's programme of acceleration of the economic development of Perestroika was favourably welcomed in Tatarstan. The local ruling establishment (G. I. Usmanov, M. S. Shaimiev, S. A. Mustayev, and so on) considered their main task to be the implementation of the instructions of the Perestroika programme under conditions of the republic. The Supreme Council of the TASSR adopted a five-year plan for economic and social development of the republic for the period from 1986 to 1990 based on the control figures set by the Centre. The structure and the main guidelines for the development of the economy and social sphere remained unchanged. It was supposed that the enterprises of the military complex, which produced 45% of the gross industrial output, would increase



аны 1,4 тапкырга арттырачак дип күздә тотыла. «Татнефть» берләшмәсенә бишьеллык дәвамында 193 млн тонна нефть табарга, нефть химиясе предприятиеләренә җитештерүне 28,5 % ка арттырырга кирәк дигән бурыч куела. Алабугада трактор заводы һәм Кама Аланында атом электростанциясе төзү планлаштырыла.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә гомумсоюз һәм Россия фондларына ит, сөт, йомырка, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш продукциясе тапшыру буенча ныклы йөкләмә кертү (1987 елдан) ниятләнә. Сәнәгать предприятиеләренең ярдәмче хуҗалыклары, халыкның шәхси хуҗалыклары, күмәк бакчачылык һәм яшелчәчелек продукциясе хисабына тулыландырып, йөкләмәне үтәгәннән калганның барысын да, республика ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җибәрергә планлаштырыла.

Мәскәүдәге югары трибуналардан яңгыраган гадәттән тыш кискен тәнкыйть Татарстан җитәкчеләренең чыгышларына да тон бирә, алар хуҗалык механизмындагы җитешсезлекләр, фәнни-техник прогресс, хезмәт дисциплинасын яхшырту ярдәмендә эшләрнең торышын төптән төзәтү турында ачыктан-ачык сөйли башлый. Кайбер очракларда республикадагы эшләрнең торышы гомумсоюз күрсәткечләре белән чагыштырганда начаррак булганын танылар. Мәсәлән, КПССның Татарстан өлкә комитеты 1917 елгы Октябрь инкыйлабының 70 еллыгына багышлап 1987 елның 7 ноябрендә үткәргән тантаналы утырышында Татарстан Республикасы тормышыннан күп кенә тискәре фактлар китерелә. КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов үзенең докладында, аерым алганда, болай дип билгеләп үтә: «Озак вакытлар дәвамында даими рәвештә республиканың күп предприятиеләрендә фән һәм техниканың өр-яңа казанышларын кертү буенча планнар үтәлми, ә һәр дүртенче предприятие техник яктан яңадан җиһазлау мәсьәләләре

производившие 45 % валовой промышленной продукции, увеличат её в 1,4 раза. Объединению «Татнефть» предстояло за пятилетие добыть 193 млн т нефти, предприятиям нефтехимии – увеличить производство на 28,5 %. Планировалось строительство тракторного завода в Елабуге и атомной электростанции в Камских Полянах.

В области сельского хозяйства предполагалось установить твёрдые задания по сдаче в общесоюзный и российский фонды мяса, молока, яиц, картофеля, плодоовощной продукции (с 1987 г.). Для удовлетворения местных республиканских нужд планировалось направить все остатки, дополнив их за счёт продукции подсобных хозяйств промышленных предприятий, личных подсобных хозяйств населения, коллективного садоводства и огородничества.

Необычно острая критика, зазвучавшая с высоких трибун в Москве, задала тон и выступлениям татарстанских руководителей, которые громогласно заговорили о неполадках в хозяйственном механизме, о необходимости существенно исправить положение дел с помощью научно-технического прогресса, улучшения дисциплины труда. Признавалось, что в ряде случаев положение дел в республике было хуже по сравнению с общесоюзными показателями. Так, на торжественном заседании Татарского обкома КПСС 7 ноября 1987 г., посвящённом 70-летию Октябрьской революции 1917 г., приводилось много негативных фактов из жизни Татарской республики. В своём докладе первый секретарь Татарского обкома КПСС Г. И. Усманов, в частности, отметил: «На протяжении длительного времени на многих предприятиях республики систематически не выполняются планы по внедрению новейших достижений науки и техники, а каждое четвёртое предприятие вообще не занимается вопросами своего технического переоснащения. Это особенно относится к отраслям лёгкой, пищевой

production 1.4-fold. “Tatneft” Association was supposed to extract 193 million tonnes of oil over five years, and enterprises of petrochemical sector were to increase their production by 28.5%. It was also planned to build a tractor plant in Yelabuga and a nuclear power station in Kamskiye Polyany.

In the field of agriculture, it was supposed to establish the fixed tasks for delivery to the All-Union and Russian stocks of meat, milk, eggs, potato, and fruit and vegetables (from 1987). To meet the local needs of the republic, it was planned to allocate for that purpose all the surpluses and supplement them with the products produced by auxiliary farms of industrial enterprises, personal small holdings of the population, and by entities engaged in collective gardening and farming.

The unusually sharp criticism that could be heard coming from the bully pulpits in Moscow set the tone for speeches of the Tatarstan’s leaders, who began speaking freely about the problems in the economic mechanism, about the necessity to drastically correct the state of affairs with the help of scientific and technical progress and the tightening of labour discipline. It was admitted that in certain cases the state of affairs in the republic was much worse compared to the All-Union indices. For example, the official session of the Tatar Regional Committee of the CPSU that was held on 7 November 1987, which was dedicated to the 70th anniversary of the October Revolution of 1917, informed of numerous negative facts from life of the Tatar Republic. In his speech, G. I. Usmanov, the First Secretary of the Tatar Regional Committee of the CPSU, noted the following: “For a long time many enterprises of the republic have not been fulfilling the plans for introduction of the latest achievements of science and technology; every fourth enterprise has not been involved at all in solving the



белән бөтенләй шөгыльләнми. Бу бигрәк тә җиңел, азык-төлек сәнәгате, төзелеш материаллары җитештерү тармакларына, ягъни халыкның тормыш хәле яхшыру шуларның эшчәнлегенә шактый бәйле булган тармакларга карый».

Татарстанның социаль-икътисади үсешендә тизләнешне тәэмин итәргә тиешле «Машина төзелешендә фәнни-техник алгарышны тизләтү», «Интенсификация-90», «Төзелеш», «Хезмәт», «Сыйфат», «Энергия», «Агрокомплекс» максатчан комплексы программалары көткән нәтиҗәләрне бирми. 1987 елда һәр дүртенче предприятие – табыш алу буенча планны, һәр бишенчесе – продукция китереп тору, һәр алтынчысы – үзкыйммәтне киметү буенча, һәр җиденчесе хезмәт җитештерүчәнлеге буенча планнарын үтәми. Өстәвенә, намуслы хезмәткә реаль стимуллар булмау хезмәт дисциплинасының начарлануына, урлашуларның күбәюенә, караклыкка һәм ришвәтчелеккә китерә. 1986 – 1987 елларда республика предприятиеләрендә җитәкче-хуҗалыкчы кадрларны урыннарыннан алу дулкыны уза: 86 директор һәм баш инженер алмаштырыла.

Әмма арттырып җибәрүләр дә башлана: «хезмәттән тыш керемнәр» белән көрәш халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына һөҗүм итүгә әйләнә. Алкогольгә каршы кампания суррогат шәраблар таралуга, самогон кайнатуның һәм техник этил спирты кулланунын күбәюенә китерә. Шунысы да бар: бу чорда шикәр сату 22 % ка арта, бу исә шикәр һәм кондитер эшләнмәләр дефицитын тудыра, халыкка шикәр комын талон белән бүлү кертелә. Бу кампанияләр республикада күләгәдәге икътисадның базарда toткан позициясен көчәйтә.

Предприятиеләрдә дәүләт кабул итүен кертү Татарстан икътисады алдында торган бурычларны административ алымнар белән чишүнең соңгы омтылышларыннан берсе була. Бәйсез контролёрларны берләштергән бу яңа хезмәт пред-

промышленности, производству строительных материалов, то есть к тем отраслям, от деятельности которых во многом зависит рост народного благосостояния».

Целевые комплексные программы «Ускорение научно-технического прогресса в машиностроении», «Интенсификация-90», «Строительство», «Труд», «Качество», «Энергия», «Агрокомплекс», призванные обеспечить ускорение социально-экономического развития Татарстана, не дали должного эффекта. В 1987 г. каждое четвёртое предприятие не выполняло план по прибыли, каждое пятое – по поставкам продукции, каждое шестое – по себестоимости, каждое седьмое – по производительности труда. К тому же отсутствие реальных стимулов к добросовестному труду способствовало ослаблению трудовой дисциплины, росту хищений, воровства и взяточничества. В 1986 – 1987 гг. на предприятиях республики прокатилась волна кадровых смещений среди руководителей-хозяйственников: было заменено 86 директоров и главных инженеров.

Однако начались и перегибы: борьба с «нетрудовыми доходами» вылилась в наступление на личные подсобные хозяйства населения. Антиалкогольная кампания привела к распространению винных суррогатов, росту самогоноварения и употребления технического этилового спирта. Характерно, что продажа сахара в этот период выросла на 22 %, что привело к дефициту сахара и кондитерских изделий, введению талонного распределения сахарного песка населению. Эти кампании усилили рыночные позиции теневой экономики в республике.

Одной из последних попыток решения стоявших перед экономикой Татарстана задач административными методами было введение госприёмки на предприятиях. Эта новая служба, состоявшая из независимых

issues related to their technological updating. This especially relates to such sectors as the light, food, and building materials sectors, i.e. to the sectors that to a great degree are responsible for the growth of the people’s well-being.

The targeted integrated programmes, such as “Acceleration of Scientific and Technical Progress in Mechanical Engineering”, “Intensification-90”, “Construction”, “Labour”, “Quality”, “Energy’, “Agro-complex”, which were intended to ensure the acceleration of the social and economic development of Tatarstan, did not bring the desired effect. In 1987, every fourth enterprise was unable to fulfil the plan for income, every fifth – for supplies of products, every sixth – for self-cost of products, every seventh – for labour efficiency. Besides, the absence of the real incentives for dedicated work contributed to the weakening of the labour discipline, growth of stealing, thefts, and bribery. In 1986 – 1987, the enterprises of the republic faced the wave of personnel displacements of the economic managers: substituted were 86 directors and chief engineers.

However, the extremities have begun: struggle against the “unearned incomes” turned into struggle against personal small holdings of the population. The anti-drinking campaign led to the origination of a broad practice of production of wine surrogates, growth of bootlegging, and drinking of industrial ethyl spirit. Noteworthy is that the sales of sugar at that period grew by 22 %, which led to shortage of sugar and confectionary products, to the introduction of the coupon-based distribution of granulated sugar among the population. These campaigns consolidated the market positions of the shadow economy in the republic.

One of the last attempts to solve the problems of the republic’s economy on the basis of administrative approach was the introduction of the state inspection at

приятие җитәкчелеге тарафыннан продукция сыйфатын яхшыртуны тәэмин итәргә тиеш дип уйланыла. Чынлыкта исә реаль икътисади рычаглар министрлыклар кулында кала һәм дәүләт кабул итүе бюрократик идарә структурасын катлауландыра гына. Республика предприятиеләре коллективлары, беренчеләрдән булып, ил җитәкчелегенә дәүләт кабул итүен бетерү таләбе белән мөрәҗәгать итә. 1990 елда ул бетерелә.

Команда-административ идарә итү алымнарының уңай нәтиҗә бирмәгәнлеге ачык күренә, шуңа күрә 1987 – 1990 елларда төп басым идарә итүнең икътисади алымнарына, предприятиеләренең мөстәкыйль хуҗалык итүен киңәйтүгә, коллективларның һәм аерым кешеләрнең үз хезмәте өчен җаваплылыгын арттыруга ясала. «Дәүләт предприятиесе (берләшмәсе) турында» (1987 ел), «СССРда кооперация турында» (1988 ел) кебек яңа законнар да моңа булышлык итә. Шушы вакыттан Татарстанда арендалы кооперативлар, интенсив хезмәт коллективлары, шулай ук авылларда гаилә подряды актив оеша башлый. Беренче уртак предприятиеләр барлыкка килә. Икътисади эшчәнлекнең Татарстанда киң үсеш алган яңа формаларыннан берсе аренда подряды була. Бу – предприятиеләр эчендәге аренда коллективлары хезмәтен оештыру һәм аның өчен түләү формасы. 1990 елда аренда подрядында 67 сәнәгать предприятиесе эшли, сәнәгать продукциясенең гомуми күләмендә аларның чагыштырма өлеше 6,1 %ны тәшкил итә. Товар җитештерүне оештыруда тагын бер яңа форма – вак товар җитештерү-һөнәрчелек кооперациясе барлыкка килә. Беренчел ихтыяҗга караган һәм җитештерү-техник билгеләнештәге товарлар чыгару белән эшчеләренең гомуми саны 21,6 мең кешегә җиткән 643 кооператив шөгыльләнә.

1980 еллар ахырыннан Татарстанда җитештерүне гомуми кыскарту башлана. Хезмәт хакының үсеш темплары хезмәт җитештерүчәнлеге үсешеннән 2 тапкырга артып китә. Кулланучылар базарында авыр хәл туа. Кибет киштәләреннән беренчел ихтыяҗ товарлары бер-бер артлы юкка чыга. Республикадагы катлаулы социаль-икътисади хәлне союзкүләм министрлыклар һәм ведомстволар диктаты да тирәнәйтә. Үзенең җитештерү һәм фәнни-техник потенциалы буенча Татарстан кайбер союздаш республикалардан өстен тора һәм РСФСРның икътисади яктан зур үсеш алган төбәкләре исәбенә керә. Әмма бу халык тормышында аз чагылыш таба. ТАССР, башка автономияләр кебек үк, мөстәкыйль бюджет сәясәтен үткәрү мөмкинлекләренә ия булмый, аның икътисад структурасы гомумсоюз базарына яраклаштырылган була. Хәрби сәнәгать комплексы, машина төзелеше, нефть чыгару, нефть химиясе, химия предприятиеләре өстенлекле үсеш ала. Җитештерелә торган продукциянең җиңел һәм азык-төлек сәнәгате тармаклардагы предприятиеләр өлешенә бары тик 20 %ы гына туры килә. Массакүләм куллану товарлары җитештерү гомумсоюз дәрәҗәсеннән – 15 %ка, шул исәптән җиңел сәнәгать товарларыныкы 31 %ка түбәнрәк була.

от руководства предприятий контролёров, должна была обеспечить улучшение качества продукции. В действительности же реальные экономические рычаги оставались в руках министерств, и госприёмка лишь усложнила бюрократическо-управленческую структуру. Коллективы предприятий республики одними из первых обратились к руководству страны с требованием отменить госприёмку. В 1990 г. она была отменена.

Становилось очевидным, что командно-административные рычаги не давали положительного эффекта, поэтому в 1987 – 1990 гг. главная ставка была сделана на экономические методы управления, расширение хозяйственной самостоятельности предприятий, повышение ответственности коллективов и отдельных людей за свой труд. Этому способствовали и новые законы «О государственном предприятии (объединении)» (1987 г.), «О кооперации в СССР» (1988 г.). С этого времени в Татарстане стали активно создаваться арендные кооперативы, коллективы интенсивного труда, а также семейные подряды на селе. Появились первые совместные предприятия. Одной из первых новых форм экономической деятельности, получившей широкое развитие в Татарстане, был арендный подряд. Это форма организации и оплаты труда работников арендных коллективов внутри предприятий. В 1990 г. на арендном подряде работали 67 промышленных предприятий, их удельный вес в общем объёме промышленной продукции составил 6,1 %. Другой новой формой организации товарного производства была мелкотоварная производственно-промысловая кооперация. Выпуском товаров первой необходимости и производственно-технического назначения занимались 643 кооператива, с общим числом работающих в них 21,6 тыс. человек.

С конца 1980-х гг. в Татарстане началось общее сокращение производства. Темпы роста заработной платы в 2 раза превысили рост производительности труда. Тяжёлое положение сложилось на потребительском рынке. Один за другим с прилавков магазинов исчезли товары первой необходимости. Социально-экономическую ситуацию в республике усугублял и диктат союзных министерств и ведомств. По своему производственному и научно-техническому потенциалу ТАССР превосходила ряд союзных республик и входила в число наиболее экономически развитых регионов РСФСР. Но это мало сказывалось на реальной жизни людей. Татарская республика, как и другие автономии, не имела возможности проводить самостоятельную бюджетную политику, структура её экономики была ориентирована на общесоюзный рынок. Преимущественное развитие получили предприятия военно-промышленного комплекса, машиностроения, нефтедобычи, нефтехимии, химии. На долю предприятий отраслей лёгкой и пищевой промышленности приходилось лишь 20 % выпускаемой продукции. Производство товаров массового спроса было на 15 % ниже общесоюзного уровня, в том числе товаров лёгкой промышленности – на 31 %.

enterprises. That new service, which consisted of controllers that were independent from the top management of enterprises, was to ensure the improvement of quality of products. In reality, the actual economic controls remained in the hands of the ministries, and the state inspection just made the bureaucratic/administrative structure more complicated. The people who were working at enterprises were among the first to demand from the leadership of the country to abolish the state inspection. It was abolished in 1990.

It was becoming evident that the command and control system did not produce positive results. For that reason, in 1987 – 1990, it was decided to rely on the economic methods of management, expansion of economic independence of enterprises, greater responsibility of personnel of enterprises and individual workers for their labour. That was also supported by the new laws: “On State Enterprise (Association)” (1987) and “On Cooperation in the USSR” (1988). Starting from that time Tatarstan was experiencing the rapid creation of the leasing cooperatives, collectives of intensive labour, and family-based agricultural enterprises. The first joint ventures were being established. One of the first new forms of economic activity that became very popular in Tatarstan was the leasing system. It was the form of the leased labour organisation and payment within enterprises. In 1990, the leasing system was used by 67 industrial enterprises, their contribution to the industrial output totalling 6.1 %. Another form of organising the commodity production was the small-batch industrial-handicraft cooperation. Engaged in production of essential products of industrial and technical purpose were 643 cooperatives with the total number of employees being 21 600.

Starting from the end of the 1980s, Tatarstan was facing the general reduction of production. The pace of growth of wages was 2 times higher than the labour efficiency. The situation on the consumer market was hard. Essential products were disappearing from shelves of stores one after another. The social and economic situation in the republic was aggravated by dictate of the Union ministries and agencies. In terms of its industrial, scientific, and technical potential, the TASSR was ahead of a number of Union Republics and was among the best economically developed regions of the RSFSR. However, this affected but little the actual lives of people. The Tatar Republic, just like other autonomies, did not have the possibility to pursue its independent budgetary policy; the structure of its economy was oriented at the All-Union market. Priority was given to the development of enterprises of the military-industrial complex, mechanical engineering, oil production, petrochemical and chemical industries. Enterprises of the light and food industries accounted for just 20 % of output. Production of consumer goods was by 15% less compared to the All-Union level, including the production of goods of light industry – by 31 %.





## Үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык шартларында социаль-мәдәни тормыш

Үзгәртеп кору чорында совет халкына икътисадны «кискен рәвештә» социаль якка бору, социаль гаделлек принцибының эзлекле рәвештә һәр җирдә саклануына хезмәт иткән бердәй социаль сәясәт үткәрү вәгъдә ителгән иде. Ил җитәкчелеге күпмилләтле дәүләтнең имин, яхшы яшәешен кайгыртуны үзенең төп максаты дип белдерә, тормыш шартларын яхшыртуның 6 бурычы билгеләнә, алар арасында аеруча мөһимнәре икәү – азык-төлек һәм торак белән тәэмин итү. Азык-төлек тәэминаты өстенлекле эчке сәяси бурычлардан санала, һәм ул 1990 елга хәл ителергә тиеш була. Тораклы итү бурычын («һәр гаиләгә уңайлыклары булган аерым фатир») хәл итү 2000 елга кичектерелә. Әмма социаль өлкә җитәрлек күләмдә финансланмый, шуңа күрә ул программаларның үтәлмәячәге алдан ук билгеле була.

Горбачёв үткәргән социаль реформалар чоры өчен алкогольгә каршы кампания аеруча гыйбрәтле күренеш булып тора. 1985 елның май аенда эчкечелеккә һәм алкоголизмга каршы көрәш турындагы мәсьәләнең куелуы яңа җитәкчелекнең тирән социаль-икътисади тамырлары булган һәм совет җәмгыятенең әхлакый хәленә гаять тискәре йогынты ясаган катлаулы проблеманы хәл итәргә алыну ниятләренең җитдилеген дәлилли. Әмма күрелгән чараларның ашыгычлыгы һәм ахырынача уйланылмаган булуы, соңрак М. С. Горбачёв үзе язганча, «алкогольгә каршы кампаниянең тискәре нәтиҗәләре аның уңай якларыннан күпкә артуына» китерә. Самогон кайнатуның үсеш алуы, җинаятьчелекнең артуы һәм кешеләрнең усаллануы белән беррәттән, алкогольгә

## Социально-культурная жизнь в условиях перестройки и гласности

В перестроечный период советскому народу было обещано «круто повернуть» экономику к социальной сфере, проводить целостную социальную политику, основная суть которой сводилась к последовательному и повсеместному утверждению принципа социальной справедливости. Руководство страны заявило, что забота о благосостоянии многонационального государства станет его главной целью, были определены 6 задач повышения благосостояния, среди которых особо выделялись две – продовольственная и жилищная. Продовольственная считалась приоритетной внутриполитической задачей, и её решение должно было осуществиться к 1990 г. Решение жилищной («каждой семье благоустроенную отдельную квартиру») отодвигалось на 2000 г. Однако социальная область оставалась без достаточного финансирования, а потому её программы заранее были обречены на невыполнение.

Чрезвычайно показательным для горбачёвского этапа социальных реформ является проведение антиалкогольной кампании. Постановка вопроса о борьбе против пьянства и алкоголизма в мае 1985 г. свидетельствовала о серьёзности намерений нового руководства взяться за решение сложнейшей проблемы, имевшей глубокие социально-экономические корни и оказывавшей крайне негативное влияние на нравственное состояние советского общества. Однако торопливость и непродуманность предпринятых мер привели к тому, что, как позднее писал М. С. Горбачёв, «негативные последствия антиалкогольной кампании намного превзошли её плюсы». Помимо развития самогоноварения, роста преступности и озлобленности людей, массированная антиалкогольная кампания привела к резкому сокращению бюджетных поступлений, стала одним из источников финансовой разбалансированности.

## Social and Cultural Life Under Conditions of Perestroika and Glasnost

During the Perestroika period, the Soviet people were promised that a "U-turn" shall be made in the economy towards the social sphere, that an integrated social policy shall be pursued, the main goal of which would be the consistent and comprehensive establishment of the principle of social justice. The leadership of the country stated that caring for well-being of the multi-national country shall become its ultimate goal. Six tasks were determined, aimed at the solution of the task of improvement of well-fare, among which noteworthy were the food and the housing ones. The priority was given to the food issue, which was considered to be the main domestic political task. It was supposed that this task shall be solved by the year 1990. The solution of the housing issue ("every family should have a separate comfortable flat with all modern amenities" was postponed until year 2000. However, the social sphere remained to be significantly underfinanced, for which reason the programmes were doomed to failure from the very beginning.

Very indicative of the Gorbachev's stage of social reforms was the holding of the anti-drinking campaign. Raising the question of starting struggle against drinking and alcoholism in May 1985 testified to the seriousness of intention of the new leadership to tackle the most complicated problem that had deep social and economic roots and which had extremely negative influence on the moral state of the Soviet society. However, the hurry and inefficient arrangement of measures taken in this respect have resulted, as M.S. Gorbachev later wrote about it, in that "the negative consequences of the anti-drinking campaign have overcome by






«Сөембикә» журналына язылу кампаниясе. 1994

Подписная кампания журнала «Сююмбике». 1994

Subscription campaign of "Syuyumbike" magazine. 1994

Только к началу 1988 г. бюджет страны недополучил 37 млрд рублей. Руководство страны было вынуждено отступить, и уже в 1989 г. доходы от продажи алкоголя превысили уровень 1984 г. В ходе реализации этой кампании серьёзные негативные деформации испытала и социальная жизнь людей: население пристрастилось к чрезмерному употреблению винно-водочной продукции, которая стала важной формой взаиморасчётов за проделанную работу или услугу, особенно в сельской местности.

Социально-культурная жизнь во второй половине 1980-х гг. ознаменовалась не столько попытками обновления социальной сферы жизнедеятельности населения Татарстана, сколько активизацией гражданского и духовного раскрепощения. Гласность и изменения в общественном сознании создали благоприятную атмосферу

far its pluses". Apart from the development of bootlegging, growth of criminality and exacerbation of people, the large-scale anti-drinking campaign led to drastic reduction of budgetary incomes, became one of the sources of financial misbalance. In the early 1988, the budget of the country did not receive 37 billion roubles. The leadership of the country had to step back and, as early as already in 1989 the incomes from the sales of alcohol exceeded the level of 1984. In the course of implementation of that campaign, serious negative deformations were recorded in the social life of people: the population took to excessive drinking of wine and vodka products, which became an important form of settlements for the work done or service rendered, especially in the rural areas.

The social and cultural life in the second half of the 1980s was marked by intensification of civic and spiritual liberation rather than by attempts of renovation of the social sphere related to daily living activity of the population of Tatarstan. Glasnost and changes in public conscience created favourable atmosphere for broad and sharp discussion of problems of national-cultural development.

каршы көчле кампания бюджет керемнәренең кисәк кимүенә китерә, шулай ук финанслар балансы бозылуның бер сәбәбе була. 1988 елның башына гына да ил бюджеты 37 млрд сум акча алып җиткерми. Ил җитәкчелеге чигенергә мәҗбүр була, һәм инде 1989 елда алкоголь сатудан кергән керемнәр 1984 ел дәрәҗәсен узып китә. Әлеге кампанияне гамәлгә ашыру барышында халыкның социаль хәле дә җитди тискәре үзгәрешләр кичерә: халык аракы-шәраб продукциясен чамадан тыш күп куллануга һәвәсләнә, чөнки алкогольле эчемлек, бигрәк тә авыл җирендә, башкарылган эшкә яки күрсәтелгән хезмәткә үзара исәп-хисап ясауның мөһим формасына әйләнә.


1980 елларның икенче яртысындагы социаль-мәдәни тормышка Татарстан халкының социаль хәлен яңартырга тырышу гына түгел, гражданлык азатлыгы һәм рухи иркенлеккә омтылуның активлашуы да хас. Хәбәрдарлык һәм иҗтимагый үзаң үзгәрү мил-





Татар әлифбасы авторлары Р. Вәлитова һәм С. Вагыйзов

Авторы татарского букваря Р. Валитова и С. Вагизов

R. Valitova and S. Vagizov – autors of Tatar ABCbook






















ли-мәдәни үсеш мәсьәләләре буенча киң һәм үткен фикер алышу өчен уңайлы шартлар тудыра. Гражданлык позицияләре ныгый барган саен, җәмәгатьчелек татар теленең әһәмияте кимү, милли мәктәпләрнең мескен хәле, массакүләм мәгълүмат чараларының һәм татар китабы нәшер итүнең чикләнгән мөмкинлекләре турында тирән борчылуын белдерә башлый. Республика газеталарында, радио һәм телевидениедә татар теленә кызыксыну тудыру бурычын үтәрдәй һәм теләүчеләргә аны өйрәнә башларга ярдәм итәрдәй даими сәхифәләр һәм тапшырулар барлыкка килә. Шушы максатларда татарча-русча һәм русча-татарча сөйләүлекләр, сүзлекләр нәшер ителә.

Татар халкы тарихы да яңача бәяләнә. Күренекле татар фикер ияләре Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Г. Баруди, Һ. Атласи, С. һәм Ә. Максудиларга, Г. Исхакыйга һ. б. багышланган мәкаләләр дөнья күрә. Г. Исхакыйның тормышына һәм эшчәнлегенә, аның XX гасыр башында татарларның милли азатлык хәрәкәтендә, татар халкының рухи мәдәниятендә тоткан урынына җәмәгатьчелекнең аерым игътибары җәлеп ителә. Милли тарих мәсьәләләре буенча актив бәхәсләр алып барыла. «Татар халкы тарихы», «Руслар һәм татарлар» кебек капиталь хезмәтләр язу кирәклеге турында тәкъдимнәр ясала. ГУЛАГ системасы турында коточкыч дөреслекне җәмәгатьчелек И. Сәлахов, А. Гыйләҗев, Г. Тавлин, Е. Гинзбург һ. б. әсәрләреннән белә.

Үз халкының мәдәниятен тирәнтенрәк белергә омтылуы, халыкның иң яхшы гореф-гадәтләрен торгызу теләге төрле милли-мәдәни оешмалар (Мәрҗани исемендәге клуб, «Мәгариф» иҗтимагый комитеты, «Туган як» җәмгыяте һ. б.) төзелүдә чагыла. Шуның белән бергә, Татарстан җирлегендә яшәгән һәр халыкка үз мәдәни-агарту җәмгыятьләрен төзү мөмкинлеге туа. Алар удмурт, чуваш, яһүд, башкорт, мари, мордваларда һ. б. барлыкка да килә. 1990 елга Татарстандагы формаль булмаган берләшмәләрнең гомуми саны 4 меңнән артып китә.

«Мирас» республика комиссиясенең эшчәнлеге татар халкының рухи мирасын өйрәнү һәм торгызу бурычларына буйсындырыла. Аның программаларын тормышка ашыру кысаларында 1989 – 1990 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Татар совет энциклопедиясе һәм ТАССРның Тарих һәм мәдәният һәйкәлләре җыелмасы бүлекләре булдырыла.

для широкого и острого обсуждения проблем национально-культурного развития. По мере укрепления своих гражданских позиций общественность всё с большей тревогой стала заявлять о снижении роли татарского языка, плачевном состоянии национальной школы, ограниченных возможностях средств массовой информации и татарского книгопечатания. В республиканских газетах, на радио и телевидении появились постоянные рубрики и передачи, которые ставили задачу вызвать интерес к татарскому языку и помогали желающим начать его изучение. В этих целях были изданы татарско-русские и русско-татарские разговорники, словари.

Переосмыслению подверглась и история татарского народа. Увидели свет статьи, посвящённые видным татарским мыслителям Ш. Марджани, Р. Фахретдину, Г. Баруди, Х. Атласову, С. и А. Максуди, Г. Исхаки и др. Особое внимание общественности было привлечено к жизни и деятельности Г. Исхаки, его роли в национально-освободительном движении татар начала XX в., в духовной культуре татарского народа. Активно дискутировались проблемы национальной истории. Были высказаны предложения о необходимости создания таких капитальных трудов, как «История татарского народа», «Русские и татары». Страшную правду о системе ГУЛАГа общественность узнала из произведений его узников – И. Салахова, А. Гилязова, Г. Тавлина, Е. Гинзбург и др.

Стремление глубже узнать культуру своего народа, желание возродить лучшие народные традиции проявились в создании различных этнокультурных организаций (клуб им. Марджани, общественный комитет «Магариф», общество «Туган як» и др.). Вместе с тем у каждого народа, проживавшего на территории Татарстана, была возможность создать свои культурно-просветительские общества, и они появились у удмуртов, чувашей, евреев, башкир, мари, мордвы и др. К 1990 г. общее число неформальных объединений в Татарстане превысило 4 тыс.

Задачам изучения и возрождения духовного наследия татарского народа была подчинена деятельность республиканской комиссии «Мирас». В рамках реализации её программ в 1989 – 1990 гг. при Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова были созданы отделы Татарской Советской Энциклопедии и Свода памятников истории и культуры ТАССР.

While consolidating their civic positions, the society began stating, with the growing concern, the diminishing role of the Tatar language, the poor state of national (ethnic) school, limited capabilities of mass media and the Tatar book-printing. The republic's newspapers, radio, and television were introducing permanent columns and programmes that were aimed at raising interest in the Tatar language and helped those who wished to study it. In this connection, published were Tatar-Russian and Russian-Tatar phrase-books and dictionaries.

Rethought was also the history of the Tatar people. Published were articles dedicated to notable Tatar thinkers: S. Marjani, R. Fakhretdin, G. Barudi, K. Atlasov, S. and A. Maksudi, G. Ishaki, and so on. Special attention of the society was drawn to life and activity of G. Ishaki, his role in the national liberation movement of the Tatars of the early 20th century, in the spiritual culture of the Tatar people. Heated discussions were held related to problems of the national history. Proposals were aired on the necessity of creation of such comprehensive works as "History of the Tatar People", "The Russians and the Tatars". People learned the horrible truth about the system of GULAG from the works created by its victims: I. Salakhov, A. Gilyazov, G. Tavlin, Y. Ginzburg, and so on.

The aspiration to better learn the culture of their people, the wish to restore the folk traditions manifested themselves in the creation of different ethno-cultural organisations (The Marjani Club, "Magarif" Public Committee, "Tugan Yak" Society, etc.). At the same time, every people that lived in the territory of Tatarstan had the possibility to create their own cultural-enlightenment societies, and such indeed were established by the Udmurts, Chuvashes, Jews, Bashkirs, Mari, Mordovians, and so on. By 1990, the total number of informal associations in Tatarstan exceeded 4 000.

The activity of "Miras" republic's commission was dedicated to the study and revival of the spiritual heritage of the Tatar people. Within the framework of implementation of its programmes, established in 1989 – 1990 under the Institute of Language, Literature, and History n.a. G. Ibragimov were the departments of the Tatar Soviet Encyclopaedia and the Code of Monuments of History and Culture of the TASSR.





Сөембикә манарасына ярымай беркетү

Поднятие полумесяца на башню Сююмбике

Erecting a crescent onto Syuyumbike Tower

Сөембикә манарасы төзекләндерү вакытында

Башня Сююмбике во время реставрации

Syuyumbike Tower during restoration








Татарстан һәм Башкортостан АЭС төзелешенә каршы протест маршы. 1989

Марш протеста против строительства Татарской и Башкирской АЭС. 1989

March of protest against the construction of the Tatar and Bashkir nuclear power plant. 1989

Казан университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты ачылу, 1991 елда ТАССР Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясен булдыру, Сөембикә манарасы очына ислам символы булган ярымайны күтәрү – болар татар халкының мәдәни тормышында мөһим вакыйгалар була. Халыкның тарихи аңына Татарстандагы торак пунктларның үз атамалары кайтарыла: мисал өчен, 1982 елда исеме Брежнев дип үзгәртелгән шәһәр – Яр Чаллы (1988), бераз соңрак Куйбышев шәһәре Болгар шәһәре дип атала башлый.

Үзгәртеп кору елларында «яшелләр»нең экологик хәрәкәте аеруча зур активлык күрсәтә, ул Казан янында биохимия заводы, Кама Аланында Татар атом электростанциясе төзелүгә каршы ярсу чыгышлар ясый. Алар протест митинглары, мохит өчен куркыныч объектлар төзүне туктату таләпләре язылган мөрәҗәгатьләргә имзалар җыюны оештыра, җирле газета һәм журналларда экологик темаларга күпсанлы мәкаләләр дөнья күрә. Хакимият җәмәгатьчелек фикеренә колак сала: әлеге объектларны төзү туктатыла.

Важными событиями в культурной жизни татарского народа стали открытие в Казанском университете факультета татарской филологии, истории и восточных языков, учреждение в 1991 г. Премии Союза писателей ТАССР им. Г. Исхаки, водружение на шпиль башни Сююмбике символа ислама – полумесяца. В историческое сознание народов возвращались исконные названия населённых пунктов Татарстана: Набережные Челны (1988 г.), переименованный в 1982 г. в Брежнев, несколько позднее Куйбышев получил название Болгар.

В годы перестройки наибольшую активность проявляло экологическое движение «зелёных», энергично выступавшее против строительства биохимического завода вблизи Казани, Татарской атомной электростанции в Камских Полянах. Они организовывали митинги протеста, сбор подписей под воззваниями с требованиями прекратить сооружение опасных для окружающей среды объектов, появились многочисленные публикации на экологические темы в местных газетах и журналах. Власти уступили общественности: строительство этих объектов было заморожено.

The important events in the cultural life of the Tatar people included the opening at Kazan University of Department of Tatar Philology, History, and Oriental Languages, the establishment in 1991 of the Award of the Union of Writers of the TASSR n. a. G. Ishaki, the placement of a crescent, the symbol of Islam, on the top of the Syuyumbike Tower. Returning to the historical consciousness of the peoples were the original names of settlements of Tatarstan: Naberezhnye Chelny (1988), which was renamed in 1982 into Brezhnev; Bolgar, which regained its original name a bit later. At the Soviet period, the town of Bolgar was named Kuibyshev.

During the years of Perestroika, very active was the ecological movement of "The Greens", who stood for prohibition of construction of the bio-chemical plant near Kazan and of the Tatar nuclear power plant in Kamskiye Polyany. They were organising the meetings of protest, collection of signatures in favour of demands to stop the construction of facilities that were hazardous for environment; numerous articles on ecological topics were published in local newspapers and magazines. The authorities agreed to the public demands, and the construction of such facilities was suspended.

# ЯҢА ГАСЫР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮСЕШ ЮЛЫНДА

## РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НА ПУТИ СОЗИДАНИЯ В НОВОМ ВЕКЕ

## THE REPUBLIC OF TATARSTAN ON THE WAY OF CREATION IN THE NEW CENTURY







Бүгенге көндә Татарстан Россия Федерациясенең иң тотрыклы үсә торган субъектлары рәтенә керә, соңгы 20 ел дәвамында сәнәгать, авыл хуҗалыгы, торак төзелеше, транспорт коммуникацияләрен үстерү, шулай ук инвестицияләрне җәлеп итү һәм житештерүгә инновацияләр кертү буенча алдынгы урыннарның берсен алып тора. Татарстан – көчле фәнни потенциалы булган регион, аның башкаласы Казан – Россия Федерациясенең иң эре мәгариф һәм мәдәни-спорт үзәкләренең берсе. Республика халыкара мөнәсәбәтләрдә актив катнаша, абруйлы чит ил оешмалары эгидасы астында зур иҗтимагый-сәяси форумнар, мәдәни һәм спорт чаралары уздыра. Ул Россия Федерациясе төбәкләрендә уңайлы мохит формалаштыру проектын гамәлгә ашыру буенча рейтинг лидеры булып тора. Татарстан Республикасы гомуммроссия федератив төзелешенә зур өлеш кертә. «Советлардан соңгы үсеш чорында Татарстан моделе иң уңышлыларның берсе булып чыкты, – дип саный Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнеханов, – хәзерге көндә республика ирешкән бөтен нәрсә – төрле милләт вәкилләренең тырыш хезмәте нәтиҗәсе ул. Татарстанның уңышы турыдан-туры безнең уртак Ватаныбыз – Россиянең уңышы булуын без барыбыз да аңлыйбыз».

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында халык саны буенча 8 нче урында – 3 898 700 кеше (2019 ел). Халыкның тыгызлыгы – 1 кв. километрга 57,46 кеше. Шәһәр халкы – 76,7 % (2018 ел). Республика 43 муниципаль районга бүленгән (Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алабуга, Алексеевск, Апас, Арча, Әгерҗе, Әлки, Әлмәт, Әтнә, Балтач, Балык Бистәсе, Баулы, Биектау, Бөгелмә, Буа, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш,

Современный Татарстан относится к числу наиболее устойчиво развивающихся субъектов Российской Федерации, на протяжении последних 20 лет занимает одно из ведущих мест по развитию промышленности, сельского хозяйства, жилищного строительства, транспортных коммуникаций, а также по привлечению инвестиций и внедрению инноваций в производство. Татарстан – регион с мощным научным потенциалом, его столица Казань – один из крупнейших образовательных и культурно-спортивных центров Российской Федерации. Республика является активным участником международных отношений, под эгидой авторитетных зарубежных организаций в ней проводятся крупные общественно-политические и научные форумы, культурные и спортивные мероприятия. Она является лидером рейтинга по реализации проекта формирования комфортной среды в регионах Российской Федерации. Республика Татарстан внесла значительный вклад в общероссийское федеративное строительство. «Татарстанская модель развития за период постсоветского развития стала одной из самых успешных. Всё, что сегодня достигнуто республикой, – считает Президент Республики Татарстан Р. Н. Минниханов, – это результат кропотливого труда многих поколений – представителей самых разных национальностей. Мы едины в понимании того, что успешность Татарстана напрямую означает успешность нашей общей Родины – России».

Республика Татарстан среди субъектов Российской Федерации по численности населения – 3 898 700 человек (2019 г.) – занимает 8-е место. Плотность населения – 57,46 человека на кв. км. Городское население – 76,7 % (2018 г.). Территориально республика разделена на 43 муниципальных района (Агрызский, Азнакаевский, Аксубаевский, Актанышский, Алексеевский, Алькеевский, Альметьевский, Апастовский, Арский, Атнинский, Бавлинский, Балтасинский, Бугульминский, Буинский, Верхнеуслонский, Высокогорский,

The modern Tatarstan is one of the most sustainably developing regions of the Russian Federation. For the last 20 years it has been among the leaders in terms of development of industry, agriculture, residential building, transport communications, as well as in the attraction of investment and introduction of innovations in the production sector. Tatarstan is the region with the powerful scientific potential, and its capital – the city of Kazan – is one of the largest educational, cultural, and sports centres of the Russian Federation. The republic is an active participant of international relations; held in it under the aegis of reputable foreign organisations are large-scale social, political, and scientific forums, cultural, and sports events. It is the leader in the ranking of Russian regions in the implementation of the project on the formation of a comfortable environment. The Republic of Tatarstan made a strong contribution to the All-Russian federative building. “The Tatarstan’s model of development in the period of the post-Soviet development has become one of the most successful. Everything, which has been achieved today by the republic, – as President of the Republic of Tatarstan R. N. Minnikhanov puts it – is the result of a painstaking labour of many generations – representatives of different nationalities (ethnic groups). We are united in the understanding of the fact that success of Tatarstan means directly the success of our common Motherland – Russia”.

The Republic of Tatarstan ranks 8th in terms of the population among regions of the Russian Federation with its 3 898 700 citizens (2019). The density of population is 57.46 per square kilometre. Urban population makes up 76.7 % (2018). Territorially, the republic is divided into 43 municipal districts (Agryzsky, Aznakayevsky, Aksubayevsky, Aktanyshsky, Alexeyevsky, Alkeyevsky, Almetyevsky, Apastovsky, Arsky, Atnynsky, Bavlinsky, Baltasinsky, Bugulminsky, Buinsky, Verkhneuslonsky, Vysokogorsky, Drozhzhanovsky, Yelabuzhsky, Zainsky, Zelenodolsky, Kaibitsky, Kamsko-Ustyinsky, Kukmorsky, Laishevsky,

## РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН. АДМИНИСТРАТИВНАЯ КАРТА







Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Нурлат, Питрәч, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Теләче, Тукай, Түбән Кама, Чирмешән, Чистай, Чүпрәле, Югары Ослан, Ютазы, Яңа Чишмә, Яшел Үзән); 24 шәһәр, шуларның 14 е – республика әһәмиятендәге шәһәрләр (Азнакай, Алабуга, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Буа, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Түбән Кама, Чистай, Яшел Үзән), шул исәптән 2 шәһәр округы (Казан һәм Чаллы) һәм 10 район әһәмиятендәге шәһәр (Арча, Әгерҗе,

Дрожжановский, Елабужский, Заинский, Зеленодольский, Кайбицкий, Камско-Устьинский, Кукморский, Лаишевский, Лениногорский, Мамадышский, Менделеевский, Мензелинский, Муслюмовский, Нижнекамский, Новошешминский, Нурлатский, Пестречинский, Рыбно-Слободский, Сабинский, Сармановский, Спасский, Тетюшский, Тукаевский, Тюлячинский, Черемшанский, Чистопольский, Ютазинский); 24 города, из них 14 – республиканского значения (Азнакаево, Альметьевск, Бавлы, Бугульма, Буинск, Елабуга, Заинск, Зеленодольск, Лениногорск, Нижнекамск, Нурлат, Чистополь), в том числе 2 городских округа (Казань и Набереж-

Leninogorsky, Mamadyshsky, Mendeleyevsky, Menzelinsky, Muslyumovsky, Nizhnekamsky, Novosheshminsky, Nurlatsky, Pestrechinsky, Rybno-Slobodsky, Sabinsky, Sarmanovsky, Spassky, Tetyushsky, Tukayevsky, Tyulyachinsky, Cheremshansky, Chistopolsky, and Yutazinsky); 24 towns, of which 14 are of the republic's subordination (Aznakayevo, Almetyevsk, Bavly, Bugulma, Buinsk, Yelabuga, Zainsk, Zelenodolsk, Leninogorsk, Nizhnekamsk, Nurlat, and Chistopol), including 2 city districts (Kazan and Naberezhnye Chelny) and 10 – of the district subordination (Agryz, Arsk,

Болгар, Иннополис, Кукмара, Лаеш, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Тәтеш); 17 шәһәр тибындагы бистә (Аксубай, Актүбә, Алексеевск, Апас, Байлар Сабасы, Балтач, Балык Бистәсе, Васильево, Җәлил, Кама Аланы, Кама Тамагы, Карабаш, Карамалы Тау, Куйбышев исемендәге Затон, Тенеш, Түбән Мактама, Урыссу); 872 авыл җирлеге, 3 077 авыл торак пункты, шуларның 1 703 е – татар, 614 е – рус, 197 се – чуваш, 55 е – удмурт, 29 ы – мари, 19 ы мордва торак пункты.

ные Челны) и 10 – районного значения (Агрыз, Арск, Болгар, Иннополис, Кукмор, Лаишево, Мамадыш, Менделеевск, Мензелинск, Тетюши); 17 посёлков городского типа (Аксубаево, Актюбинский, Алексеевское, Апастово, Балтаси, Богатые Сабы, Васильево, Джалиль, Камские Поляны, Камское Устье, Карабаш, Куйбышевский Затон, Нижние Вязовые, Нижняя Мактама, Рыбная Слобода, Тенишево, Уруссу); 872 сельских поселения, 3 077 сельских населённых пунктов, из них 1 703 – татарские, 614 – русские, 197 – чувашские, 55 – удмуртские, 29 – марийские, 19 – мордовские.

Bolgar, Innopolis, Kukmor, Laishevo, Mamadysh, Mendeleyevsk, Menzelinsk, and Tetyushi); 17 urban-type settlements (Aksubayevo, Aktyubinsky, Alexeyevskoye, Apastovo, Baltasi, Bogatiye Saby, Vasilyevo, Jalil, Kamskiye Polyany, Kamskoye Ustye, Karabash, Kuibyshevsky Zaton, Nizhniye Vyazoviye, Nizhnyaya Maktama, Rybnaya Sloboda, Tenishevo, and Urussu); 872 rural settlements, 3 077 rural-type settlements, of which 1 703 are the Tatar ones, 614 – Russian, 197 – Chuvash, 55 – Udmurt, 29 – Mari, and 19 – Mordovian ones.






Дәүләт символлары, муниципаль символлар татар халкының милли дәүләтчелеге тарихының иң мөһим өлеше һәм гасырлардан килгән традицияләрнең ачык чагылышы булып тора. Татарстан АССР оешрылганнан бирле үткән йөз эчендә республикада шактый үзгәрешләр була, алар дәүләт символикасында да чагылыш таба.

Республиканың рәсми дәүләт эмблемасы – Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан 1992 елның 7 февралендә расланган **Татарстан Республикасы Дәүләт гербы.** Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кояш җирлегендә алгы уң аягын бераз күтәргән, янында түгәрәк калкан булган канатлы барс сурәтеннән гыйбарәт. Кояш түгәрәгә татар милли бизәге төшерелгән һәм аскы өлешенә «Татарстан» дип язылган кайма белән уратып алынган.

1991 елның 29 ноябрендә ТССР Югары Советы раслаган **Татарстан Республикасы Дәүләт флагы** дәүләт хакимиятенең рәсми суверенлыкны гәүдәләндергән символы булып тора. Ул яшел, ак һәм кызыл төстәге горизонталь буйлардан торган турыпочмаклы тукымадан гыйбарәт.

Государственные и муниципальные символы являются важнейшей составляющей истории национальной государственности татарского народа и зримым воплощением традиций, дошедших до нас из глубины веков. За прошедшее с момента образования Татарской АССР столетие в республике произошли значительные изменения, что нашло отражение в государственной символике.

Официальной государственной эмблемой республики является **Государственный герб Республики Татарстан,** утверждённый Верховным Советом Республики Татарстан 7 февраля 1992 г. На гербе изображён крылатый барс с круглым щитом на боку, с приподнятой правой передней лапой на фоне диска солнца, помещённого в обрамление из татарского народного орнамента, в основании диска надпись «Татарстан».

The capital industrial construction and residential construction became one of the biggest achievements of Tatarstan in the 1990 – 2000s. Successfully implemented in 1996 – 2004 was the republic's programme of liquidation of dilapidated housing in Tatarstan, which helped move over 40 000 families living in Kazan and in other towns of the republic to new flats with all modern conveniences. Starting from mid-2000s, the republic has been implementing a national project titled "Affordable and Comfortable Housing to Citizens of Russia" that includes measures encouraging residential construction in regions of the Russian Federation, aimed at construction of housing for young families and other categories of citizens that have rights for benefits, as well as such that are aimed at upgrading of the communal infrastructure. All in all, 4 074 citizens moved to new flats under the programme of residential construction for veterans of the Great Patriotic War and families equaled with them. Under the programme of major repairs, carried out in Tatarstan over the period from 2008 to 2012 were the works at more than 13 400 residential houses with the total area of over 11.4



2008 – 2012 елларда капиталь ремонт программасы нигезендә Татарстанда 11,4 млн кв. метрдагы 13,4 мең йортка 31,2 млрд сумлык эш башкарыла. 2011 елда 50 дән артык мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе төзү һәм төзекләндерү юлы белән балаларны бакчаларда урыннар белән тәэмин итү буенча «Бәләкәч – Малыш» республика программасы тормышка ашырыла.

работы более чем в 13,4 тыс. домов площадью свыше 11,4 млн кв. м на сумму свыше 31,2 млрд рублей. В 2011 г. реализована республиканская программа «Бэлэкэч – Малыш» по обеспечению детей местами в детских садах посредством строительства и реконструкции свыше 50 дошкольных учреждений.

million square metres and to the total amount of 31.2 billion roubles. In 2011, the republic's programme titled "Belekech-Baby" was implemented for provision of children with places in kindergartens, which was done through construction and reconstruction of more than 50 pre-school institutions.






XXI гасыр башында авыл хуҗалыгы элеккечә Татарстан икътисадының төп тармакларының берсе булып кала, республика халкын, өлешчә Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә яшәүче – азык-төлек белән, сәнәгатьне чимал белән тәэмин итүдә төп роль уйный. Аның нигезен үсемлекчелек, башлыча, игенчелек тәшкил итә; шулай ук бәрәңге игү, яшелчәчелек, чөгендер үстерү, терлек азыгы җитештерү үсеш ала. Татарстан терлекчелегенең нигезен ит-сөт терлекчелеге, кошчылык, дуңгызчылык тәшкил итә. Ат үрчетү, сарык үрчетү, умартачылык, җәнлек үрчетү, балык тоту үсеш ала. Татарстан икътисадының аграр секторында күпукладлы хуҗалык итү ысулы формалаша, анда, холдинглар һәм төрле инвесторлар белән беррәттән, крестьян (фермер) хуҗалыклары, гаилә фермалары һәм авыл халкының шәхси ярдәмче хуҗалыклары да сизелерлек роль уйный.

В начале XXI в. сельское хозяйство по-прежнему остаётся одной из основных отраслей экономики Татарстана, играет главную роль в обеспечении населения республики, отчасти и других регионов Российской Федерации, продовольствием, промышленности – сырьём. Его основу составляет растениеводство, главным образом зерновое хозяйство; развиты также картофелеводство, овощеводство, свекловодство, кормопроизводство. Основу животноводства Татарстана составляют мясомолочное скотоводство, птицеводство, свиноводство. Развито коневодство, овцеводство, пчеловодство, звероводство, рыбоводство. В аграрном секторе экономики Татарстана сформировалась многоукладная форма хозяйствования, в котором, наряду с холдингами и различными инвесторами, значительную роль играют крестьянские (фермерские) хозяйства, семейные фермы и личные подсобные хозяйства сельского населения.

At the beginning of the 21st century agriculture was still one of the main industries of the economy of Tatarstan and is still playing the main role in provision of the republic's population, as well as, partially, the citizens of the other regions of the Russian Federation, with foodstuffs, and of the country's industrial sector – with raw materials. Its backbone is formed by plant-growing, mainly grain-growing. Well-developed are also potato, vegetable, and beetroot farming, and fodder production. The basis of cattle-breeding in Tatarstan is formed by meat-and-dairy cattle, poultry-, and pig-farming. Quite well-developed are also horse-, sheep-, animal, and fish-breeding sectors, and beekeeping. A mixed type of economic activity has evolved in the agrarian sector of the Tatarstan's economy, in which a significant role is played, along with holdings and different types of investors, by peasant (farmers) households, family-run farms, and personal small-holdings of the rural population.





Базар икътисадын торгызу чорында авыл хуҗалыгына дәүләт ярдәме Татарстан икътисадының мөһим үзенчәлеге булып тора. Республика бюджетыннан аграр җитештерүне үстерүнең барлык төп юнәлешләре финанслана. Чит ил технологияләрен, техникасын, үсемлекләрне, орлыкларны саклау чараларын, нәселле терлекләрне сатып алуга, шулай ук ит комбинатларының, сөт заводларының, шикәр заводларының һәм башка авыл хуҗалыгы эшкәртү предприятиеләренең матди-техник базасын камилләштерүгә шактый акча бүлеп бирелә. Аграр икътисад өлкәсендә чит ил ширкәтләре белән хезмәттәшлек актив үсә башлый. Нәтиҗәдә 1990 елларда Россия агросәнәгать комплексы үсешендә ачык күренгән зыянлы тенденцияләрне Татарстан авыл хуҗалыгында сизелерлек киметү мөмкинлеге туа. 1996 елда республика ашлыкның тулаем җыемы буенча, бөртекле

Важной особенностью экономической политики Татарстана в период становления рыночной экономики явилась государственная поддержка сельского хозяйства. Из республиканского бюджета финансировались все основные направления развития аграрного производства. Значительные валютные средства выделялись на приобретение импортных технологий, техники, средств защиты растений, семян, племенного скота, а также на совершенствование материально-технической базы мясокомбинатов, молокозаводов, сахарных заводов и других сельскохозяйственных перерабатывающих предприятий. В сфере аграрной экономики стало активно развиваться сотрудничество с зарубежными фирмами. В итоге в сельском хозяйстве Татарстана удалось смягчить разрушительные тенденции, отчётливо проявившиеся в 1990-е гг. в развитии агропромышленного комплекса России. В 1996 г. по валовому сбору зерна республика вышла на первое

The state support of agriculture became an important distinctive feature of the economic policy of Tatarstan in the period of formation of the market economy. The republic's budget provided funds for all main lines of development of the agrarian production. Considerable amounts in foreign currencies were allocated for purchase of imported technologies, machinery, plant-protecting agents, seeds, pedigree livestock, as well as for improvement of the material and technical base of meat-processing combines, dairy plants, sugar plants, and other agricultural processing enterprises. Actively developing in the agrarian sector was cooperation with foreign companies. As a result, agriculture of Tatarstan managed to smooth down the destructive tendencies that became quite visible in the 1990s in the development of the agro-industrial complex of Russia. In 1996, the republic ranked first in the Russian Federation in gross grain production (6 million









ашлык җитештерү өчен уңайлы төбәкләрне – Ставрополь краен һәм Ростов өлкәсен узып, Россия Федерациясендә беренче урынга чыга (6 млн тонна). Шуннан соңгы елларда ашлык җыю уртача 4 – 4,5 млн тоннаны тәшкил итә. Җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең бер өлеше Татарстаннан читкә чыгарыла.

Татарстанда Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы продукциясенең 4 проценттан артыгы җитештерелә, ул бу күрсәткеч буенча Россия субъектлары арасында бишенче урында тора. Соңгы дистә еллар нәтиҗәләре буенча Татарстан шикәр чөгендере, бәрәңге, терлекчелек һәм кошчылык продукциясе җитештерү буенча Идел буе федераль округы республикалары һәм өлкәләре арасында иң яхшы күрсәткечләргә ия.

место в Российской Федерации (6 млн т), опередив такие благодатные для зернового производства регионы, как Ставропольский край и Ростовская область. В последующий период ежегодный сбор зерна составлял в среднем 4 – 4,5 млн т. Часть произведённой сельскохозяйственной продукции вывозится за пределы Татарстана.

В Татарстане производится свыше 4 % сельскохозяйственной продукции Российской Федерации, он занимает по этому показателю 5-е место среди российских субъектов. По результатам последнего десятилетия Татарстан имеет лучшие показатели среди республик и областей Приволжского федерального округа по производству сахарной свёклы, картофеля, продукции животноводства и птицеводства.

tonnes), having left behind it such favourably positioned for grain production regions as Stavropol Territory and the Rostov Region. In the subsequent years, the annual grain production totalled, in average, 4 – 4.5 million tonnes. A portion of the produced agricultural products is exported beyond the borders of Tatarstan.

Tatarstan produces over 4 % of agricultural output of the Russian Federation and ranks fifth in this respect among Russian regions. Over the last decade, Tatarstan has the best results among republics and regions of the Volga Federal District in production of sugar beet, potato, cattle and poultry products.









Татарстан Республикасы һәм Кытай Халык Республикасының Хэйлунцзян провинциясе делегацияләре очрашуы. 2019

Встреча делегаций Республики Татарстан и провинции Хэйлунцзян Китайской Народной Республики. 2019

A meeting of delegations of the Republic of Tatarstan and the Province of Heilongjiang of the People's Republic of China. 2019





Индонезия делегациясе Казан вертолёт заводының сәнәгать мәйданчыгында. 2015

Делегация из Индонезии на производственной площадке «Казанского вертолётного завода». 2015

A delegation of Indonesia visiting the production site of the Kazan Helicopter Plant. 2015

Якын һәм ерак чит илләр белән сәүдә-икътисад элемтәләре дә Татарстан Республикасы икътисадын үстерүдә зур роль уйный. 1990 елдан башлап, республика җитәкчелеге дөньяның төрле илләре һәм аларның предприятиеләре һәм оешмалары белән хезмәттәшлек элемтәләре урнаштыру өлкәсендә актив сәясәт алып бара. XXI гасыр башына йөздән артык халыкара шартнамә, килешү һәм беркетмә төзелә. Россия Федерациясенең күп регионнары һәм БДБ илләре (Азәрбайҗан, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Украина һ. б.), 20 дән артык чит ил (Венгрия, Германия, Иран, Канада, Нидерландлар, Польша, Төркия, Япония һ. б.) белән турыдан-туры шартнамә мөнәсәбәтләре корылган. Татарстанның әйдәп баручы экспортёрлары даими рәвештә эре халыкара күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнаша, алар арасында «ЭКСПО» Бөтендөнья күргәзмәсен, ел саен үткәрелә торган Ганновер ярминкәсен, IDEX хәрби техника күргәзмәсен атап үтәргә мөмкин. Читкә чыгарыла торган товарлар арасында нефть, нефть химиясе продуктлары өстенлек итә. Чит илдән машина төзелеше һәм станоклар төзү продукциясе аеруча күп кертелә. 130 чит ил оешмасы Татарстан белән актив сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыра. «Татнефть» Акционерлык җәмгыяте катнашында Сүриядә, Төрекмәнстанда, Украинада, Беларусь Республикасында, «КАМАЗ» Акционерлык җәмгыяте катнашында Вьетнамда, Һиндстанда, Иранда, Пакыстанда, Казахстанда берничә предприятие эшли.



Большую роль в развитии экономики Республики Татарстан играют и торгово-экономические связи со странами ближнего и дальнего зарубежья. С 1990-х гг. руководство республики проводит активную политику в сфере установления партнёрских связей с различными странами мира и их предприятиями и организациями. На начало XXI в. заключено свыше 100 международных договоров, соглашений и протоколов. Прямые договорные отношения установлены со многими регионами Российской Федерации и странами СНГ (Азербайджан, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Туркменистан, Украина и др.), с более чем 20 странами дальнего зарубежья (Венгрия, Германия, Иран, Канада, Нидерланды, Польша, Турция, Япония и др.). Ведущие предприятия-экспортёры Татарстана регулярно участвуют в крупнейших международных выставках и ярмарках, среди которых – Всемирная выставка «ЭКСПО», ежегодная Ганноверская ярмарка, выставка военной техники «IDEX» на Ближнем Востоке. В товарной структуре экспорта преобладают сырая нефть, продукты нефтехимии. В импорте наибольший удельный вес имеет продукция машиностроения и станкостроения. Активную торговую деятельность с Татарстаном осуществляют организации из более чем 130 зарубежных стран. За границей работает ряд предприятий с участием ПАО «Татнефть» – в Сирии, Туркменистане, Украине, Республике Беларусь, у участием ПАО «КАМАЗ» – во Вьетнаме, Индии, Иране, Пакистане, Казахстане.




Беренче Каспий икътисади форумы. 2019

Первый Каспийский экономический форум. 2019

The First Caspian Economic Forum. 2019

A significant role in the development of the economy of the Republic of Tatarstan is played by trade and economic relations with the CIS and other foreign countries. Starting from the 1990a, the leadership of the republic pursues an active policy in the field of establishing partnership relations with different countries of the world and their enterprises and organisations. As at the beginning of the 21st century, Tatarstan concluded over 100 international treaties, agreements, and protocols. Direct contractual relationships were established with many regions of the Russian Federation and CIS countries (Azerbaijan, Byelorussia, Kazakhstan, Kyrgyzstan, Turkmenistan, Ukraine, etc.), with more than 20 foreign countries (Hungary, Germany, Iran, Canada, the Netherlands, Poland, Turkey, Japan, etc.). The leading exporters of Tatarstan take part on regular basis in the largest international exhibitions and fairs, including EXPO World's Fair, annual Hannover Messe, IDEX International Defence Exhibition in the Middle East. The commodity pattern of export is dominated by crude oil and petrochemical products. The largest portion of imports is represented by products of mechanical engineering and machine tool building. The active trade relations with Tatarstan are maintained by organisations from over 130 foreign countries. Working in foreign countries are also a number of enterprises that were established with participation of OJSC Tatneft: in Syria, Turkmenistan, Ukraine, Republic of Belarus and of PJSC KamAZ: in Vietnam, India, Iran, Pakistan, and Kazakhstan.

## Фән, мәгариф һәм мәдәният

Фәнни тикшеренүләрнең күп дистә еллар дәвамында оешкан бердәм совет дәүләт системасы таркалганнан соң, 1990 елларда Татарстанда күп кенә фәнни-тикшеренү институтларының һәм лабораторияләренең эшчәнлеге туктатыла, гамәли һәм фундаменталь тикшеренүләр тематикасы тарая, фәнни хезмәткәрләр саны кыскартыла. Татарстан фәнен үстерү өчен әлеге авыр шартларда республика җитәкчелеге берничә хәлиткеч карар кабул итә. Алар арасында фәнни потенциалны саклауда һәм тикшеренү эшчәнлеген алга таба үстерүдә төп рольне уйнаган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен төзү турында карар (1991 елның октябре) аерым урын алып тора. Республиканың фән үзәген танылган дәүләт эшлеклесе М. Х. Хәсәнов җитәкли. Фәннәр академиясе фундаменталь һәм гамәли фәнни-тикшеренүләр белән шөгыльләнгән төрле фәнни һәм югары уку йортлары үз канаты астына берләштерә. Бер үк вакытта ул аларның фәнни эшчәнлеген финанслауның төрле юлларын һәм сәнәгать, авыл хуҗалыгы сәнәгатен үстерүнең иң мөһим юнәлешләре буенча фәнни тикшеренү эшләрен координацияләүне һәм алар өчен фәнни һәм югары технологик техник чаралар һәм материаллар (матдәләр) ясауны оештыра. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен төзү һәм аның каршында мөстәкыйль фәнни-тикшеренү институтларын булдыру Татарстан суверенлыгының беренче һәм мөһим билгеләреннән берсе була.

Милли тарихны, әдәбиятны, телне, мәдәниятне һәм сәнгатьне комплексы үстерү зарурлыгына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе эшендә фәннең гуманитар тармакларын үстерүгә аерым игътибар бирелә. Бүген академия составына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, А. Х. Халиков исемендәге Археология институты кебек эре гуманитар фәнни-тикшеренү учреждениеләре керә; аның фәнни-методик җитәкчелегендә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты эшли. Татар һәм рус телләрендә 6 томлык «Татар энциклопедиясе», рус һәм инглиз телләрендә 7 томлык «Татар тарихы», татар теленең 4 томлык академик грамматикасы, 8 томлык татар әдәбияты тарихы, 25 томлык татар фольклоры җыентыгы һәм башка фундаменталь басмалар нәшер ителү Татарстанның һәм татар халкының фәнни тормышында зур вакыйга була.

## Наука, образование и культура

С распадом единой советской государственной системы научных исследований, сформировавшейся в течение многих десятилетий, в 1990-е гг. в Татарстане произошло свёртывание работы многих научно-исследовательских институтов и лабораторий, а также тематики прикладных и фундаментальных исследований, сокращение численности научных работников. В этих тяжёлых для развития татарстанской науки условиях руководство республики приняло ряд судьбоносных решений. Среди них особое место занимает решение о создании Академии наук Республики Татарстан (октябрь 1991 г.), которое сыграло определяющую роль в сохранении научного потенциала и дальнейшем развитии исследовательской деятельности. Возглавил центр науки республики известный государственный деятель М. Х. Хасанов. Академия наук объединила различные научные и вузовские исследовательские учреждения, занимавшиеся фундаментальными и прикладными научными изысканиями. Одновременно она организовала различные формы финансирования их научной деятельности и координацию научно-исследовательских работ по важнейшим направлениям развития промышленного и сельскохозяйственного производств и по созданию для них наукоёмких и высокотехнологичных технических средств и материалов (веществ). Создание Академии наук Республики Татарстан и формирование при ней самостоятельных научно-исследовательских институтов стало одним из первых и важных признаков суверенизации Татарстана.

В связи с необходимостью комплексного возрождения национальной истории, литературы, языка, культуры и искусства татарского народа в работе Академии наук Республики Татарстан особое внимание уделялось развитию гуманитарных отраслей науки. Сегодня в составе академии функционируют такие крупные гуманитарные научно-исследовательские учреждения, как Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, Институт татарской энциклопедии и регионоведения, Институт археологии им. А. Х. Халикова; под её научно-методическим руководством работает Институт истории им. Ш. Марджани. Заметным явлением в научной жизни Татарстана и татарского народа начала XXI в. стал выход 6-томной «Татарской энциклопедии» на татарском и русском языках, 7-томной «Истории татар» на русском и английском языках, 4-томной академической грамматики татарского языка, 8-томной истории татарской литературы, 25-томного свода татарского фольклора и других фундаментальных изданий.

## Science, Education, and Culture

Following the collapse of the common Soviet state system of research activity that took many decades to develop, the 1990s saw the drastic curtailment of work of many research and development institutes and laboratories in Tatarstan, the narrowing of subject matters of applied and fundamental research, reduction of the number of scientific workers. Under such hard conditions for the Tatarstan's science, the leadership of the republic made a number of fateful decisions. A special place among them belongs to the decision to establish the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (October 1991), which played a decisive role for the preservation of the scientific potential and further development of the research activity. The Academy was entrusted to M. K. Khasanov, a well-known statesman. It united different scientific and academic research institutions engaged in fundamental and applied research. At the same time, it organised different forms of funding of their research activity and coordinated research and development work carried out in the main lines of development of the industrial and agricultural production, as well as the development for such of science-intensive and high-technology means and materials (substances). The creation of the Academy of sciences of the Republic of Tatarstan and the formation under its umbrella of independent research and development institutes became one of the first and important signs of sovereignisation of Tatarstan.

Considering the necessity to ensure an integrated revival of the national (ethnic) history, literature, language, culture, and art of the Tatar people, the work of the Academy of sciences of the Republic of Tatarstan was focused on the development of humanities as part of science. Today, functioning within the Academy are such large humanitarian research and development institutions as the G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and Art, the Institute of the Tatar Encyclopaedia and Regional Studies, the A. K. Khalikov Institute for Archaeology; working under its scientific and methodical guidance is the S. Marjani Institute of History. The notable events in the scientific life of Tatarstan and the Tatar people of the early 21st century included the publication of the Tatar Encyclopaedia in 6 volumes in the Tatar and Russian languages, of the History of the Tatars in 7 volumes in the Russian and English languages, of the Academic Grammar of the Tatar Language in 4 volumes, of the History of the Tatar Literature in 8 volumes, of the Code of the Tatar Folklore in 25 volumes, and other fundamental works.



М. Х. Хәсәнов, галим,әдәбият белгече, дәүләт эшлеклесе, ТР ФАнең беренче президенты

М. Х. Хасанов, учёный, литературовед, государственный деятель, первый президента АН РТ

M. K. Khasanov, scientist, theorist of literature, statesman, first President of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan





Хәзерге вакытта Татарстанда төрле гамәли һәм фәнни эшчәнлек тармаклары өчен югары квалификацияле белгечләр әзерләү белән шөгыльләнгән югары уку йортлары челтәре эшли. 2019 ел башына Татарстанда 21 филиалы булган 16 дәүләт югары уку йорты һәм дәүләтнеке булмаган 11 югары уку йорты һәм аның 11 филиалы исәпләнә. Яңа югары уку йортлары барлыкка килү һәм искеләрен үзгәртеп кору, аларның коммерцияләшүе университетлар һәм институтларда студентлар санын сизелерлек арттырырга мөмкинлек бирә. Республиканың югары уку йортларында 170 меңнән артык студент белем ала. Татарстан югары уку йортларында Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән, шулай ук якын һәм ерак чит илләрдән килгән студентлар, магистрантлар да бар.

В Татарстане сформировалась развитая сеть вузовских учреждений, занимающихся подготовкой и переподготовкой высококвалифицированных специалистов для различных отраслей практической и научной деятельности. На начало 2019 г. в Татарстане работают 16 государственных вузов с 21 филиалом и 11 негосударственных вузов с 11 филиалами. Появление новых вузов и реорганизация старых, их коммерциализация позволили значительно расширить ареал охвата университетами и институтами студенческой молодёжи, существенно увеличить её численность. В вузовской системе республики обучаются свыше 170 тыс. студентов. В татарстанских вузах получают образование студенты, магистранты и из других регионов Российской Федерации, а также из стран ближнего и дальнего зарубежья.

The present-day Tatarstan has created a well-developed network of institutions of higher education that are engaged in training and re-training of highly skilled specialists for various sectors of practical and scientific activity. As at the beginning of 2019, Tatarstan had 16 state institutions of higher education with 21 branches and 11 private universities with 11 branches. Emergence of the new universities and the reorganisation of the old ones and their commercialisation made it possible to expand considerably the coverage of students with universities and institutes and increase their number. The system of higher education of the republic currently unites over 170 000 students. The institutions of higher education of Tatarstan are also open to students and post-graduate students from other regions of the Russian Federation, CIS and other foreign countries.



















1990 елларның тәэсире гомуми белем бирү мәктәпләре, урта махсус һәм һөнәри-техник училищелар (техникумнар) һәм төрле ведомстволарга караган мәктәпкәчә балалар учреждениеләре системасына да катгый рәвештә кагыла. Мәгариф системасын үзгәртеп кору барышында Татарстанда уку йортларының яңа төрләре: гимназияләр, көллиятләр, лицейлар, махсус мәктәпләр, шулай ук хосусый уку йортлары барлыкка килә. 2018 ел башына республикада 72 урта һөнәри уку йорты (66 мең укучы), 1403 гомуми белем бирү мәктәбе (якынча 375 мең укучы), 1 887 мәктәпкәчә учреждение (194 мең бала) исәпләнә. Татарстан Республикасы яңа мәктәпләр саны буенча Идел буе федераль округында әйдәп баручы булып тора.

1990-е гг. кардинально затронули и систему общеобразовательных школ, средних специальных и профессионально-технических училищ (техникумов) и ведомственных детских дошкольных учреждений. В ходе переформатирования советской системы образования в Татарстане появились новые виды учебных заведений: гимназии, колледжи, лицеи, специализированные школы, а также частные учебные заведения. На начало 2018 г. в республике насчитывалось 72 средних профессиональных учебных заведения (66 тыс. учащихся), 1403 общеобразовательные школы (около 375 тыс. учеников), 1 887 дошкольных учреждений (194 тыс. детей). Республика Татарстан является лидером в Приволжском федеральном округе по количеству новых школ.

The 1990s have radically affected the system of general education schools, secondary specialised colleges and vocational technical colleges, as well as of departmental children's pre-school institutions. In the course of reformation of the Soviet system of education, the new forms of educational institutions have appeared in Tatarstan: gymnasiums, colleges, lyceums, specialised schools, as well as private educational institutions. As at the beginning of 2018, the republic had 72 secondary vocational colleges (66 000 students), 1 403 general education schools (some 375 000 pupils), and 1 887 pre-school institutions (194 000 children). The Republic of Tatarstan is the leader in the Volga Federal District in the number of new schools.














Күпмилләтле Татарстан җәмгыятендә барган идея үзгәрешләре язучылар һәм публицистлар иҗатында да чагыла. Милли әдәбиятта XX–XXI гасырлар чигендә татарларның этник үзаңын торгызуга һәм онытылган рухи кыйммәтләрне кайтаруга юнәлтелгән тенденцияләр көчәюе күзәтелә. Татар прозасы, классик реализм принципларына кире кайтып, совет идеологик кыйммәтләрен яңадан карау, тоталитар системаны бәяләү өчен җаваплылыкны үз өстенә ала (Ф. Садриев, Ф. Сафин, Ф. Бәйрәмова һ. б.). Әдәби миф яки тарихи материал, фантастик һәм мистик күзаллаулар базасында «хаос белән диалог» нәтиҗәсендә барлыкка килгән шартлы-метафорик проза социумның көзгедәге чагылышына әверелә (З. Хәким, М. Кәбиров һ. б.). Прозадагы кебек үк, шигъриятт дә, романтизм белән берррәттән (Р. Вәлиев, М. Галиев һ. б.), постмодернизм ягына авышу бара (Р. Зәйдулла, Р. Аймәт, Л. Гыйбадуллина һ. б.). Драматургиядә авторларның архетиплар, мифология һәм шартлы формалар куллануга тартылуы, дөньяның «фаҗигале» моделен тәэүгә, шулай ук заманның «абсурд» картинасын булдыруга тартылуы күзәтелә (М. Гыйләҗев, И. Зәйни һ. б.). Т. Миңнуллин пьесаларында милләтне торгызу һәм саклау проблемалары кискен яңгырый. Татар әдәбияты әсәрләре Татарстандагы башка халыклар, Россия һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителә.


XX–XXI гасырлар чигендәге Татарстан тормышында күзәтелгән төптән үзгәрешләр вакытлы матбугатның структурасында һәм эчтәлегендә үзгәрешләргә китерә. Беренче тапкыр яшьләр өчен татар һәм рус телләрендә «Идел» әдәби журналы дөнья күрә (1989 елдан). 1990 елларда «Казан» һәм «Мирас» журналлары иҗтимагый тормышта әһәмиятле вакыйга була. Иҗтимагый-сәяси оешмаларның вакытлы басмалары («ТИҮ хәбәрләре», «Азатлык», «Коммунист сүзе»,

Идейные трансформации, произошедшие в многонациональном татарстанском обществе, получили отражение и в творчестве писателей и публицистов. На рубеже XX–XXI вв. в национальной литературе наблюдалось усиление тенденций, направленных на возрождение этнического самосознания татар и возвращение забытых духовных ценностей. Татарская проза взяла на себя ответственность за пересмотр советских идеологических ценностей, за оценку тоталитарной системы, вернувшись к принципам классического реализма (Ф. Садриев, Ф. Сафин, Ф. Байрамова и др.). Условно-метафорическая проза, возникающая в результате «диалога с хаосом» на базе литературного мифа или исторического материала, фантастических и мистических представлений, становится зеркальным отражением социума (З. Хаким, М. Кабиров и др.). Как и в прозе, в поэзии, наряду с романтизмом (Р. Валеев, М. Галиев и др.), происходит сдвиг в сторону постмодернизма (Р. Зайдулла, Р. Аймет, Л. Гибадуллина и др.). В драматургии наблюдается тяготение авторов к использованию архетипов, мифологии и условных форм, созданию «трагической» модели мира, а также «абсурдной» картины современности (М. Гилязов, И. Зайни и др.). В пьесах Т. Миннуллина остро звучат проблемы возрождения и сохранения нации. Произведения татарской литературы активно издаются, переводятся на другие языки народов Татарстана, России и зарубежных стран.

Кардинальные перемены в жизни Татарстана на рубеже XX–XXI вв. привели к изменениям в структуре и содержании периодической печати. Впервые стал издаваться молодёжный литературный журнал на татарском и русском языках «Идель» (с 1989 г.). Заметным явлением в общественной жизни в 1990-е гг. стали журналы «Казань» и «Мирас». Достоянием общественности стали периодические издания

The ideological transformations that occurred in the multi-national society of Tatarstan were also reflected in the art of writers and publicists. At the turn of the 20th and 21st centuries, the national literature showed the strengthening of tendencies aimed at revival of the ethnic self-consciousness of the Tatars and regaining of the forgotten spiritual values. The Tatar prose assumed responsibility for revision of the Soviet ideological values, for assessment of the totalitarian system, having returned to the principles of the classical realism (F. Sadriev, F. Safin, F. Bairamova, and so on). The quasi-metaphorical prose that arose as a result of a “dialogue with chaos” on the basis of a literary myth or historical material, fictional or mystic perceptions becomes a mirror image of the society (Z. Khakim, M. Kabirov, and so on). Just like in prose, the poetry, along with romanticism (R. Valeyev, M. Galiev, and so on), showed the shift towards post-modernism (R. Zaidoullah, R. Aimet, L. Gibadoullina, and so on). In the field of dramaturgy, the authors showed the inclination towards the use of archetypes, mythology, and symbolic forms, towards the creation of a “tragic” model of the world, as well as towards the “absurd” picture of the present times (M. Gilyazov, I. Zaini, and so on). In the plays created by T. Minnullin sounding sharply were the problems of revival and preservation of the nation. The works of the Tatar literature are being actively published and translated into other languages of peoples of Tatarstan, Russia, and foreign countries.

The profound changes in life of Tatarstan at the turn of the 20th and 21st centuries led to changes in the structure and contents of the periodical press. For the first time ever, the literary magazine, “Idel”, intended for young people began to be published in the Tatar and Russian languages (from 1989). The other notable events in the public life of the 1990s included “Kazan” and “Miras” magazines. Opened to everybody were the periodical editions of social and



«Суверенитет» һ. б.) һәм хосусый басмалар җәмәгатьчелектә киң тарала. Эшлекле даирәләр өчен «Время и деньги» газетасы, реклама басмалары чыга башлый. Татарстанда «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Вечерняя Казань», «Казанские ведомости» газеталары алдынгы вакытлы матбугат булып тора. «Татарстан», «Казан утлары», «Казан», «Мәгариф», «Сөембикә», «Идел» кебек журналларның популярлыгы арта. 1990 елларда Татарстанның Әлмәт, Яшел Үзән, Яр Чаллы, Түбән Кама кебек башка шәһәрләрендә дә басмалар даирәсе шактый киңәя. Шәһәр һәм район газеталарының күбесе, эчтәлеген сыйфат ягыннан үзгәртеп, яңа исемнәр астында чыга башлый. 2018 ел башына Татарстанда 800 гә якын массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлә, шул исәптән 186 газета һәм 70 журнал – татар телендә, бишесе – чуваш телендә, берсе – удмурт телендә.

XXI гасыр башында Татарстанның массакүләм коммуникация чаралары да гаять зур үсеш кичерә. 2017 елда 1 193 массакүләм мәгълүмат чарасы, шул исәптән 144 телеканал һәм телепрограмма, 155 радиоканал һәм радиопрограмма, 96 электрон вакытлы басма, 18 мәгълүмат агентлыгы теркәлә. «Татарстан», «ТНВ», «ТНВ–Планета», «Эфир» телеканаллары, «Татар радиосы», «Болгар радиосы», «БИМ-радио» радиокомпанияләре Татарстанда киң таныла. «ТНВ» телерадиокомпаниясе үз программаларын Россиянең Европа өлеше, Урал, Көнбатыш Себер, Ерак Көнчыгыш, БДБ илләре, Көнчыгыш һәм Үзәк Европа, Төньяк Һиндстан, Кытай һәм Япония өчен татар телендә трансляцияли. Татарстанда «Интерфакс», «РИА Новости», «ИТАР-ТАСС», «Прайм», «РБК-Татарстан» мәгълүмат агентлыкларының төбәк вәкилләре, шулай ук кайбер федераль басмаларның редакцияләре эшли.

общественно-политических организаций («Известия ТОЦ», «Независимость», «Слово коммуниста», «Суверенитет» и др.) и частные издания. Начали выходить газета для деловых кругов «Время и деньги», рекламные издания. Ведущими периодическими изданиями в Татарстане являются газеты «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Татарстан яшьляре», «Мэдэни жомга», «Шахри Казан», «Вечерняя Казань», «Казанские ведомости». Значительно выросла популярность таких журналов, как «Татарстан», «Казан утлары», «Казань», «Магариф», «Сююмбике», «Идель». В 1990-е гг. значительно расширился круг изданий и в других городах Татарстана: в Альметьевске, Зеленодольске, Набережных Челнах, Нижнекамске. Многие городские и районные газеты стали выходить под новыми названиями, качественно изменив своё содержание. На начало 2018 г. в Татарстане было зарегистрировано около 800 печатных средств массовой информации, в том числе 186 газет и 70 журналов на татарском языке, 5 газет на чувашском языке, 1 – на удмуртском языке.

В начале XXI в. небывалый рост пережили и средства массовой коммуникации Татарстана. В 2017 г. было зарегистрировано 1 193 средства массовой информации, в том числе 144 телеканала и телепрограммы, 155 радиоканалов и радиопрограмм, 96 электронных периодических изданий, 18 информационных агентств. Ведущими татарстанскими телеканалами являются «Татарстан», «ТНВ», «ТНВ-Планета», «Эфир»; радиокомпаниями – «Татар радиосы», «Болгар радиосы», «БИМ-радио». Телерадиокомпания «ТНВ» осуществляет трансляции своих программ на татарском языке для европейской части России, Урала, Западной Сибири, Дальнего Востока, стран СНГ, Восточной и Центральной Европы, Северной Индии, Китая и Японии. В Татарстане работают региональные представительства информационных агентств «Интерфакс», «РИА Новости», «ИТАР-ТАСС», «Прайм», «РБК-Татарстан», а также редакции ряда федеральных изданий.

political organisations (“News of the Tatar Public Centre”, “Independence”, “The Word of a Communist”, “Sovereignty”, and so on) and private editions. The other popular editions that appeared at that period included “Time and Money”, the newspaper for business circles, and various advertising editions. The leading periodicals in Tatarstan included such newspapers as “Vatanym Tatarstan”, “Republic of Tatarstan”, “Tatarstan Yashlere”, “Medeni Zhomga”, “Shakhri Kazan”, “Evening Kazan”, “Kazan Bulletin”. Much more popular became such magazines as “Tatarstan”, “Kazan Utlary”, “Kazan”, “Magarif”, “Syuyumbike”, “Idel”. In the 1990s, much broader became the range of editions published in the other towns of Tatarstan: in Almetyevsk, Zelenodolsk, Naberezhnye Chelny, Nizhnekamsk. Many city and district newspapers changed their names and improved the quality of their materials. As at the beginning of 2018, Tatarstan had some 800 printed mass media, including 186 newspapers and 70 magazines in the Tatar language, 5 newspapers in the Chuvash language, and 1 – in the Udmurt language.

In the beginning of the 21st century the unprecedented growth was also recorded in mass media of Tatarstan. In 2017, registered were 1 193 mass media, including 144 TV channels and TV programmes, 155 radio-channels and radio programmes, 96 electronic periodicals, and 18 news agencies. The leading TV-channels of Tatarstan include “Tatarstan”, “TNV”, “TNV-Planet”, “Efir”; radio-companies – “Tatar Radiosy”, “Bolgar Radiosy”, “BIM-Radio”. “TNV” TV and Broadcasting Company broadcasts its programmes in the Tatar language for European part of Russia, the Urals, West Siberia, the Far East, CIS countries, Eastern and central Europe, North India, China, and Japan. Working in Tatarstan are the regional representative offices of such news agencies as Interfax, RIA Novosti, ITAR-TASS, Prime, RBK-Tatarstan, as well as editorial offices of a number of federal editions.















1990 – 2010 елларда Татарстанда монументаль һәм шәһәр төзелеше архитектурасы зур үсеш кичерә, шәһәр үзәкләрендә уңайлыклар булдыру һәм төзекләндерү, яңа офислар, банклар, сәүдә йортлары, индивидуаль һәм стандарт проектлар буенча уңайлы торак йортлар төзү әлеге процесска хас үзенчәлекләр булып тора. Иске корылмаларны торгызу һәм яңаларын төзү, чит ил ширкәтләрен иҗтимагый корылмалар төзүгә җәлеп итү, архитектурада милли һәм төбәк үзенчәлекләрен эзләү зур тизлек белән алып барыла.

В 1990 – 2010-е гг. в Татарстане большой взлёт пережила монументальная и градостроительная архитектура, характерными особенностями процесса стали реконструкция и благоустройство городских центров, интенсивное строительство новых офисов, банков, торговых заведений, комфортабельных жилых домов по индивидуальным и типовым проектам. Быстрыми темпами происходили восстановление утраченной функции старых и возведение новых культовых сооружений, привлечение иностранных фирм к строительству общественных сооружений; поиск национального и регионального своеобразия архитектурных решений.

In the period between 1990s and 2010s, the monumental and urban architecture were booming in Tatarstan and reached their peak. The typical features of that process included the reconstruction and further improvement of city centres, intensive building of new offices, banks, retail trade centres, comfortable residential houses designed under individual and standard designs. Rapidly recovering were the once lost functions of the old and the construction of the new religious buildings, many foreign firms were attracted for construction of public buildings; the architects were actively seeking national (ethnic) and regional peculiarities of architectural solutions.











XX – XXI гасырлар чигендә Казанның тышкы күренеше шактый үзгәрә. «Азино-1», «Азино-2», «Суворов», «Магеллан», «Җиденче күк», «Кояшлы шәһәр», «XXI гасыр» һәм башка исемнәрдәге заманча торак комплекслар төзелә. «Пирамида», «Корстон», «Парк Хаус», «Тандем» h.б. иҗтимагый һәм сәүдә-күңел ачу комплекслары, «Баскет-холл», «Татнефть Арена», «Ракета» h. б. күп функцияле спорт корылмалары барлыкка килә. Казанның меңьеллыгына Казансу елгасы аша Миллениум күпере, Казан метрополитенының беренче тармагы, яңа ипподром төзелә.

На рубеже XX – XXI вв. значительно изменился внешний облик Казани. Возникли современные жилые комплексы: «Азино-1», «Азино-2», «Суворовский», «Магеллан», «Седьмое небо», «Солнечный город», «XXI век» и многие другие. Появились уникальные общественные и торгово-развлекательные комплексы: «Пирамида», «Корстон», «Парк Хаус», «Тандем» и др., многофункциональные спортивные сооружения: «Баскет-холл», «Татнефть Арена», «Ракета» и др. К тысячелетию Казани были построены уникальный мост Миллениум через реку Казанка, первая ветка Казанского метрополитена, новый ипподром.

The outlook of Kazan has changed drastically at the turn of the 20th and 21st centuries. The new residential complexes were erected: Azino-1, Azino-2, Suvorovsky, Magellan, The Seventh Heaven, The Sunny City, The 21st Century, and so on. There emerged the unique public and commercial/entertainment complexes: The Pyramid, Korston, Park House, Tandem, and so on, multi-functional sports complexes: Basket-Hall, Tatneft-Arena, Raketa, and so on. Timed for the millennium anniversary of Kazan were the opening of Millenium, the unique bridge across the River Kazanka, the first line of the Kazan underground, and the new hippodrome.















Казанның иң зур туристлык һәм иҗтимагый үзәге булып Кремль тора, аның төп объектлары реставрацияләнә, өлешчә тәзекләндерелә. Шәһәрнең төп истәлекле урыннарының берсе булган Кол Шәриф мәчете торгызыла. Меңьеллык алдыннан Кремльдә Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музее, «Эрмитаж–Казан» үзәге (Эрмитаж филиалы), Туп сарае, Татарстан тарихы музее, Ислам мәдәнияте музее, Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы төзелә. Казан Кремле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы ядкярләре реестрына кертелә.

Крупнейшим туристическим и общественным центром Казани стал Кремль, основные объекты которого подверглись реставрации, отчасти и реконструкции. Была воссоздана мечеть Кул Шариф, которая является одной из главных достопримечательностей города. Накануне 1000-летия в Кремле были созданы Музей истории государственности татарского народа и Республики Татарстан, центр «Эрмитаж-Казань» (филиал Эрмитажа), Пушечный двор, Музей естественной истории Татарстана, Музей исламской культуры, Музей-мемориал Великой Отечественной войны. Казанский Кремль был включён в реестр памятников Всемирного наследия ЮНЕСКО.

The Kremlin became the largest tourist attraction and a public centre of Kazan, the main structures of which underwent restoration and, partially, reconstruction. Reconstructed was the Kul Sharif Mosque, which became one of the main sightseeing of the city. Established in the Kremlin close to the date of celebrating the 1000th anniversary were the Museum of History of Statehood of the Tatar People and the Republic of Tatarstan, Hermitage-Kazan Centre (a branch of the State Hermitage), the Cannon Yard, the Museum of Natural History of Tatarstan, the Museum of Islamic Culture, and the Memorial Museum of the Great Patriotic War. The Kazan Kremlin was included on the UNESCO World Heritage List.

















1980 – 1990 еллар ахырындагы иҗтимагый-сәяси тормышта булган тирән үзгәрешләр Татарстанда музей эшенең торышына уңай йогынты ясый. «Казан» милли-мәдәни үзәген ачу республиканың мәдәни тормышында мөһим вакыйга була. 1990 – 2010 елларда Татарстандагы шәһәрләр һәм авылларда яңа оешкан туган якны өйрәнү һәм мемориаль музейлар челтәре барлыкка килә. Алар арасында әйдәп баручы рольне Татарстан Республикасы Милли музее һәм Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать музее уйный. Бу елларда Татарстан Республикасының Милли музее җитди үзгәрешләр кичерә: капиталь ремонттан соң аның бинасы яңа төс ала. Экспозиция материаллары да шактый зур үзгәрешләр кичерә. Казанда музейның үзәкләштерелгән базасында Муса Җәлил музей-фатиры, Габдулла Тукай әдәби музее, Салих Сәйдәшев музее, Е. А. Боратынский музее һәм башка музейлар эшли башлый. 2019 ел башына Татарстанда 152 музей учреждениесе, шул исәптән 59 – тарих-туган якны өйрәнү, 12 – мемориаль, 5 сәнгать музее исәпләнә. Республика музейлары фәнни-тикшеренү, мәдәни-агарту, җыю-туплау һәм реставрация эшләре белән шөгыльләнә. Аларда Горький, Каменев, Сәйдәшев, Тукай, Шаляпин укулары, М. Җәлилне искә алу көне һәм башка чаралар үткәрелә. Илнең зур музейлары белән берлектә экспозиция-күргәзмә эшләре алып барыла.

2014 елда Халыкара төрки мәдәният оешмасы (ТЮРКСОЙ) әгъзалары булган илләрнең мәдәният министрлары Даими советы карары белән Казан төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителә.

Глубокие перемены в общественно-политической жизни конца 1980-х – 1990-х гг. положительно сказались на положении музейного дела в Татарстане. Важным событием в культурной жизни республики стало открытие Национально-культурного центра «Казань», Иски-Казанского историко-культурного и природного музея-заповедника. В 1990 – 2010-е гг. в Татарстане была создана обширная сеть новых краеведческих и мемориальных музеев в городах и селах. Среди них ведущую роль играют Национальный музей Республики Татарстан и Государственный музей изобразительного искусства Республики Татарстан. В эти годы Национальный музей Республики Татарстан испытал существенные изменения: его здание после капитального ремонта приобрело новый облик. Значительную перестройку претерпели и его экспозиционные материалы. На централизованной базе музея в Казани начали работать Музей-квартира Мусы Джалиля, Литературный музей Габдуллы Тукая, Музей Салиха Сайдашева, Музей Е. А. Боратынского и др. На начало 2019 г. в Татарстане насчитывалось 152 музейных учреждения, в том числе 59 историко-краеведческих, 12 мемориальных, 5 художественных. Музеи республики занимаются научно-исследовательской, просветительской, собирательской и реставрационной работой. В них проводятся Горьковские, Каменевские, Сайдашевские, Тукаевские, Шаляпинские чтения, День памяти М. Джалиля и другие мероприятия. Совместно с крупными музеями страны осуществляются экспозиционно-выставочные проекты.

В 2014 г. решением Постоянного Совета Министров культуры стран-членов Международной организации тюркской культуры (ТЮРКСОЙ) Казань была объявлена культурной столицей тюркского мира.

